Безнең МИРАС

08
август 2014

ФӘННИ-ПОПУЛЯР, ӘДӘБИ-НӘФИС ЖУРНАЛ

ТАРИХИ, МӘДӘНИ, ДИНИ МИРАС, ТӨПЛЕ ФАРАЗ, ӘДӘБИЯТ ҖӘҮҺӘРЛӘРЕ

КАЗАНЬ
КУЛЬТУРНАЯ СТОЛИЦА
ТЮРКСКОГО МИРА
ТӨРКИ ДӨНЬЯНЫҢ
МӘДӘНИ БАШКАЛАСЫ
2014

Татарстан Республикасы Президенты Рөстәм Миннеханов белән ТӨРКСОЙ халыкара төрки мәдәният оешмасының Генераль секретаре Дүсен Касеинов. Казан, 2014 елның 25 апреле.

М.Бадыйкшин фотолары

Кардәшлеккә чикләр юк,
Кардәшлектә читләр юк!

Каләм! Кальбеңдә ни сер бар — гаян ит,
Килеп кичмешләр әхвален бәян ит.
Дәрдмәнд

Безнең МИРАС 12 +
08(31)
август 2014

Журнал «ТАТМЕДИА» ААҖ
тарафыннан гамәлгә куелды.
2012 елның май аеннан чыга.

98

46 «ТАМЫРЛАРДАН БЕЗНЕ ТАНЫРЛАР...»
Айгөл Әхмәтгалиева

78 КУТАДГУ БИЛИК (КОТАЙТКЫЧ БЕЛЕМ)
Йосыф Баласагуни

ЭЧТӘЛЕК

БАШ МӨХӘРРИР МӨНБӘРЕ

3 **Җәлилчеләрне уйлап**

КАЗАН — ТӨРКИ ДӨНЬЯНЫҢ 2014 ЕЛДА МӘДӘНИ БАШКАЛАСЫ

4 **Кардәш әдипләр хезмәттәшлеге.** *Рафис Корбан*
6 **Айшә ханым.** *Усеин Болатуков*
13 **Исемдә дә, җисемдә дә исән без!** *Фирдәвес Гарипова*
19 **Ерактагы якын кардәшләр.** *Лирон Хәмидуллин*
22 **Җәйрәннәр.** *Әбдиморат Атаҗанов*
28 **Үзбәк театры үсешенә татарлар йогынтысы.** *Шөһрәт Ризаев*
30 **Галиҗәнап Шигырь сүз ала...**
32 **Дуслык күперен ныгытканда.** *Рәшит Минһаҗ*

ТАРИХИ МИРАС

34 **Яңа төрек дәүләте уңчылары.** *Йосыф Акчура*
38 **«Ватанпәрвәрлек нөмаишләре».** *Ленар Гобәйдуллин*

ХӘТЕР САГЫНДА

46 **«Тамырлардан безне танырлар...»** *Айгөл Әхмәтгалиева*
58 **Сүз һәм сурәт.** *Разил Вәлиев*

ҖИҢҮ — 70!

60 **Җәлилчеләр иҗаты**
63 **«Кайту» тарихы: ФСБ архивыннан бер документ.** *Алексей Литвин, Рәис Төхфәтуллин*
69 **Кем ул — Абдулла Баттал?!** *Фәрит Баттал*
76 **Хатлар яздым утырып...**

ӘДӘБИ МИРАС

78 **Кутадгу билик (Котайткыч белем).** *Йосыф Баласагуни*
82 **Гаяз Исхакыйның «Солдат» романы.** *Мәсгуд Гайнетдин*
87 **Солдат.** *Гаяз Исхакый*

Баш мөхәррир
Лемон Лерон улы ЛЕРОНОВ (Ләбиб ЛЕРОН)
(843) 222-09-83 (17-91)

Баш мөхәррир урынбасары-җаваплы сәркатип
Марат Закир
(843) 222-09-83 (17-93)

Киңәшче идарә
Разил Вәлиев
(ТР Дәүләт Советының мәдәният, фән, мәгариф һәм милли мәсьәләләр Комитеты рәисе)
Илдар Гыйльметдинов
(Татар федераль милли-мәдәни автономиясе Советы рәисе)
Ирек Миннәхмәтов
(Матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр буенча Республика агентлыгы җитәкчесе)
Рөстәм Мөхәммәдиев
(«Татнефть» ААҖ генераль директоры урынбасары, «Рухият» фонды рәисе)
Айрат Сибагатуллин
(ТР мәдәният министры)
Энгель Фәттахов
(ТР премьер-министры урынбасары – ТР фән һәм мәгариф министры)
Фәрит Шаһиәхмәтов
(«ТАТМЕДИА» ААҖ генераль директоры)

Редколлегия
Ислам Әхмәтҗанов
Марсель Әхмәтҗанов
Рәдиф Җамалетдинов
Фәнзилә Җәүһәрова
Ринат Закиров
Данил Ибраһимов
Зиннур Мансуров
Ким Миңнуллин
Гөлчәчәк Нәҗипова
Сөмбел Таишева
Рафаил Хәкимов

Бүлек мөхәррирләре
Ленар Гобәйдуллин
Ләйсән Данилова
(843) 222-09-83 (17-90)

Дизайнер һәм биткә салучы
Диләрә Нәүрүзова
(843) 222-09-83 (17-92)

Корректор
Дания Фәйзуллина
(843) 222-09-83 (17-90)

Техник хезмәткәр
Данил Салихов
(843) 222-09-83 (17-91)

Редакция һәм нәшрият адресы:
420066, Казан шәһәре,
Декабристлар урамы,
2 нче йорт
Электрон почта:
yanamiras@mail.ru

90 **Тукай энциклопедиясе.** *Зөфәр Рәмиев*
91 **Яңа китап**
92 **Карәхмәтнең соңгы көннәре.** *Рөстәм Акъегет*

БЕР БӘЙЛӘМ БЕРКЕТМӘ

94 **Авыл өстендә йолдызлар**

СӘНГАТИ МИРАС

98 **Җыры калды.** *Марс Макаров*
102 **«Тыңлар идем тавышыңны...»** *Хәбир Ибраһим*

ТЕЛ КҮРКЕ – СҮЗ

106 **Миллият сүзлеге.** *Адлер Тимергалин*

100 ЕЛ ЭЛЕК

110 **«Кояш» газетасында «Казан хәбәрләре»: 1914 елның август ае.** *Ленар Гобәйдуллин*

ШАЯН МИРАС

114 **«Тынгысыз каләм» битләреннән...**
118 **«Шура» журналыннан – мәзәкләр.** *Рәйсә Шәрәфиева*

119 **Мирасворд**
120 **«Безнең мирас» елъязмасы. Август**

Заказ №А-2026. **Тираж** – 1541 данә. Формат 70 Х 108 1/16
Басарга кул куелды: 1.08.2014
Журнал айга бер тапкыр чыга. Бәясе ирекле

Журнал 2012 елның 17 апрелендә Федераль элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендә күзәтчелек хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсендә ПИ №ФС77-57844 нче таныклык белән теркәлде.

Мәкалә авторларының фикере редакция фикере белән туры килмәскә дә мөмкин. Редакциягә килгән язмалар рецензияләнми һәм кире кайтарылмый. Материаллар бары тик электрон вариантта гына кабул ителә. Журналга кергән язмаларны редакция рөхсәтеннән башка күчереп бастыру тыела.
Типография гаебе белән киткән хаталар өчен редакция җавап бирми. Бу хакта техник контроль бүлегенә 519-44-61 телефоны белән хәбәр итә аласыз.

Бу санда Татарстан Министрлар кабинеты, Татарстан Язучылар берлеге, «Мәдәни җомга» газетасы архивларыннан, Л.Гобәйдуллин һәм авторларның фоторәсемнәре файдаланылды.

«ТАТМЕДИА» ачык акционерлык җәмгыятенең «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексында басылды. Адресы: 420066, Казан шәһәре, Декабристлар урамы, 2 нче йорт

«Наше наследие»
Ежемесячный научно-популярный, литературно-художественный журнал
(на татарском языке)

Тышлыкның 1 нче битендә – «Идел Болгарстанында ислам динен кабул итү». 2005 ел. Киндер, майлы буяу. *Б.Гыйльванов рәсеме*

ҖӘЛИЛЧЕЛӘРНЕ УЙЛАП

Соңгы җырым палач балтасына
Башны куйган килеш языла.
Муса Җәлил
Гильотинмы кисәр газиз башны...
Абдулла Алиш
Ирек өчен көрәш давылында
Янә бер хат язам үзеңә...
Гайнан Кормаш
Ахры инде, үләрмен дә, илем,
Күрми синең азат булганың...
Әхмәт Симай
Бар кайгымны онтып, мин дә элек
Кочагында йөздем Иделнең...
Абдулла Баттал

Еллар башка, чорлар бүтән,
Ә заман — шул ук заман:
Дөньяларда сугыш бара,
Кырылыш бара һаман.

Анда — орыш, монда — вәхшәт,
Һич тынгы юк халыкка:
Ничә ел ул, йодрык төйнәп,
Каршы бара танкка?!

Җәлилчеләр башын салган
Кемнәр бәхете өчен?
Кемнәр көрәш алып бара
Патша тәхете өчен?

Кемнәр ул бәләкәй халык,
Кемнәр ул өстен кавем?
Кем өчен дип башын сала
Бу халык-мескенкәем?

Дөньяларда орыш бара,
Ә максат кайда да бер:
Кемгә — тәхет, кемгә — бәхет...
Тик бәхет кайлардадыр?

...Чорлар башка, еллар бүтән,
Ә заман — шул ук заман:
Баш очында үткен балта
Эленеп тора һаман!



КАРДӘШ ӘДИПЛӘР ХЕЗМӘТТӘШЛЕГЕ

Рафис Корбан,
Татарстан Язучылар берлеге идарәсе рәисе

Т атарстан Язучылар берлеге төрки телле республикаларның язучылары белән бик күптәннән дустанә мөнәсәбәтләрдә яши.

Төркиядә төрки республикаларның үзара хезмәттәшлеген оештыру өчен төзелгән ТӨРКСОЙ оешмасы барлыкка килгәч, төрки халыклар әдәбиятлары арасында иҗади хезмәттәшлек аеруча активлаша башлады. ТӨРКСОЙ ел саен төрки дәүләтләрнең һәм Россиядәге төрки республикаларның язучыларын төрле әдәби форумнарга җыя. Кызыклы очрашулар, үзара аралашулар эзсез калмый. Татар язучыларының әсәрләре төрек теленә тәрҗемә ителә, китаплары басылып чыга башлады. Фатих Кутлу, татар әдипләренең әсәрләрен төрекчәгә тәрҗемә итеп, 2013 елда шуларны Төркиянең Искешәһәр каласындагы Бәңгү нәшриятында аерым китаплар итеп бастырып чыгарды. Бер ел эчендә татар язучыларының төрек телендә биш китабы дөнья күрде. Фатих Кутлу татар әдипләренең әсәрләрен тәрҗемәләү эшен быел да дәвам иттерә.

2014 елның февраль башында Төркиянең Искешәһәр һәм Испарта калаларында төрки дөнья әдәби журналлары редакторларының VI конгрессы булып узды. Анда сүз, башлыча, төрки халыклар мәдәнияте һәм мәгърифәте үсешендә тирән эз калдырган күренекле галим, журналист, җәмәгать эшлеклесе Исмәгыйль Гаспралының вафатына 100 ел тулу уңаеннан, «Төрки дөнья әдәбияты — И.Гаспралы идеяләре яктылыгында» дигән баш астында барды. Мөхәррирләр арасында үзара аралашу

Башкортстан Язучылар берлеге идарәсе рәисе Риф Тойгын (1946-2014) чыгыш ясый. Казан, 2013 ел

вакытында Казахстан, Кыргызстан, Үзбәкстан, Азәрбайҗан, Төрекмәнстанда, һәм әлбәттә инде, Төркиядә чыга торган әдәби журналлар бер-берсенә үзара әсәрләр алмашу турында килеште.

Татарстан һәм Башкортстан Язучылар берлекләре арасында да иҗади хезмәттәшлек соңгы елларда активлашып китте. 2013 елның башында Башкортстанның Эстәрлебаш районында ике язучылар берлегенең уртак түгәрәк өстәл киңәшмәсе үткәрелде.

2013 елның 7-8 ноябрендә Казанда Башкортстан һәм Татарстан яшь язучылары иҗаты турында сөйләшүгә багышланган семинар булып узды. Семинарда һәрьяктан да бишәр яшь язучының иҗатлары тикшерелде. Яшьләргә өлкәннәр тарафыннан файдалы киңәшләр бирелде. Шундый ук семинар быел Башкортстан ягында булыр дип көтелә.

2013 елда Татарстан Язучылар берлеге казах әдәбияты классигы Магҗан Җомабаевның тууына 120 ел тулу уңаеннан аның татар теленә шигырьләр Мөдәррис Әгъләмов, Рәдиф Гаташ һәм Флёра Тарханова тәрҗемәсендә «Җан сүзе» дип аталган шигырьләр җыентыгын бастырып чыгарды. Казахстанның Астана шәһәрендә Татар-башкорт халыклар дуслыгы җәмгыяте әлеге китапны тәкъдим итү кичәсен үткәрде. Язучылар берлеге чыгарган шундый икенче китап кыргыз-татар әдибе Чыңгыз Айтматовның тууына 85 ел тулуга багышлап нәшер ителде. Ул китапта татар укучыларына әдипнең татар теленә тәрҗемә ителгән повестьлары туплап бирелде.

Чувашстанның халык шагыйре Юрий Семендер татар шагыйрьләренең шигырьләрен чуваш теленә тәрҗемә иткән. Татарстан Язучылар берлеге 123 татар шагыйренең чувашчага тәрҗемә ителгән шигырьләрен туплап, «Татар шигърияте таҗы» дип исемләнгән китап чыгарды. Язучыларның Тукай исемендәге клубында Татарстандагы чуваш милли-мәдәни җәмгыяте әгъзалары һәм Чувашстаннан килгән кунаклар катнашында әлеге китапны тәкъдим итү кичәсен үткәрде. Шундый ук кичә Чабаксар үзәк китапханәсендә үтте. Язучылар берлеге татар шагыйрьләренең чуваш телендәге күмәк җыентыгын әлеге кичәләрдә катнашучыларга, Чабаксар үзәк милли китапханәсенә бүләк итеп бирде.

Татарстан язучылары ел саен Төмәндә себер-татар шагыйре Булат Сөләймановның туган көненә багышлап үткәрелә торган «Булат Сөләйманов укулары»нда чыгыш ясый.

Язучы-галим Хатыйп Миңнегулов Казахстанда әдәбият галимнәре даирәсендә үткәрелә торган фәнни-гамәли форумнарда һәрдаим катнашып тора. ■

АЙШӘ ХАНЫМ

Усеин Болатуков

(Өч пәрдәлек пьеса)

ИКЕНЧЕ ПӘРДӘ

Бер зур бүлмә. Тирә-якта — сәкеләр. Каршы як стенада сәгать эленеп тора. Өйнең бер почмагында — шкаф. Шкаф янындагы өстәлдә бизәкле стакан, касә, чынаяк кебек вак-төяк савыт-саба.

Әсма ханым (*каршы як топчан өстенә утырып бала күлмәге тегә, һәм, аягы белән бишек тирбәткән килешкә, «Ай, нәни» җырын төрек көенә җырлый).*

Һайя-һайя, һай, нәни!
Тизрәк үсә күр, бәби.
Аллаһым бирсен сиңа
Бары гомер һәм саулык.
Һайя-һайя, һай, нәни!
Югалмасын бу бәби.
Барырсың син базарга,
Китәрсең син еракка.
Сине каршыларга, углым,
Чыгармын мин шулчакта.

Һайя-һайя, һай, нәни!
Зур үсәрсең син, бәби!
Морза углы син, морза,
Йокла углым, син Риза!
Үсеп буйга җитәрсең,
Дастан сөйләп китәрсең.
Һайя-һайя, һай, нәни,
Оста телле бул, бәби.

Атаң — эшлекле морза,
Игътибар итмә татарга.
Сине юлда күргәндә,
Торсын татар аягүрә.
Һайя-һайя, һай, нәни!
Татарны сөймә, бәби!

Хәнифә ханым (*капкадан килеп керә).* Вай, ахирәт! Бик яхшы җырлыйсың икән!

Әсма ханым (*сискәнеп).* Аллаһ! Куркыттыгыз! Шулай эшлиләрмени? Уф, йөрәгем сикерә. (*Куллары белән күкрәген тота.)* Һаман туктамый. Уф!..

Хәнифә ханым. Вай, ана-а-м, миннән куркам дигән була?

Әсма ханым. Юк, Хәнифә ханым! Сезнең гадәтегез, саф кешене сөйләп йөрисез… Мин белмиммени, валлаһи…

Хәнифә ханым. Аллаһ, Аллаһ, ахирәт! Мин бервакытта да беркем турында да сөйләп йөрмим. Гөнаһлы була күрмәгез.

Әсма ханым. Ярар, мин шаяртып кына әйттем. Тәүбә. Мин аңламаганмын. Мин сезне белмиммени, сүземә колак салмагыз. Утырыгыз, Хәнифә ханым, утыр.

Хәнифә ханым. Аллаһ, Аллаһ,

Дәвамы. Башы журналның 7 нче санында.

ахирәт, мин белмиммени сезнең шаяртканыгызны? (Сүзен борып.) Сезне азрак куркыттым, ахры?

Әсма ханым. Юк, юк. Утырыгыз. Бала-чага ни хәлдә? Ни хәлләрдә йөрисез? Берәр хәбәр-хәтәр юкмы?

Хәнифә ханым. Миндәме? Аның коесы миндә, ахирәт, миндә. *(Йодрыгы белән күкрәгенә суга.)*

Әсма ханым. Йә, ниләр бар, сөйләгезче.

Хәнифә ханым *(әкрен генә)*. Ислам морза, хуҗа, өйдәме?

Әсма ханым. Юк, өйдә берәү дә юк. *(Көлемсерәп.)* Куркасызмы? Ул булса да, килде-китте сүзгә колак салмас.

Хәнифә ханым. Берәр эштән хәбәрегез бармы?

Әсма ханым *(әкрен генә)*. Ю-ю-ю-к! Ә, нәрсә-ә-ә?

Хәнифә ханым. Ишетмәдегезмени? Хатиҗә ханымга кияү килде, ди.

Әсма ханым *(гаҗәпләнеп)*. Ә кем, ди?

Хәнифә ханым *(куанып)*. Әфәнделәрдән, әфәнделәрдән. Татарда-а-а-н! Морза эзләделәр, эзләделәр, сайладылар, сайладылар, уннан берне дә тапмадылар. Бер морза да әйләнеп карамады.

Әсма ханым *(гаҗәпләнеп)*. Чынлап әйтәсезме, һ-а-а-й?! Татарга, әфәндегә?! *(Тавышын күтәреп.)* Юк! Сез мине алдыйсыз, дөресен әйтегезче, Хәнифә ханым?

Хәнифә ханым. Җаным! Нигә ышанмыйсыз? Минем берәр вакыт алдаган булдымы сезне?

Әсма ханым. Мескен Хатиҗә ханым. Ничек яшәр татар белән? Мин, ике дөнья булса да, андый бозык, ялгыш эш эшләмәс идем.

Хәнифә ханым. Ә мин? Берне ал, уннан булсын бусагасы: чибәрлеккә килгәндә, Йосыф галәйһиссәләмнән дә чибәррәк булсын, татар булмагае, хет бер тиеннән җиңелрәк булсын.

Әсма ханым. Юк, Хәнифә ханым, юк... *(Хәнифә ханымның кулларыннан тотып.)* Мин моңа бик борчылам. Без ничек булса да үзебезгә мокыт морза таптык түгелме? Моннан соң инде карарбыз. *(Йодрыкларын бер-берсенә сугып.)*

Хәнифә ханым. «Бер мокыт морза таптык», — дигәнең нәрсәне аңлата? Мокыт түгелләр бит, юкса? Көнебез әфәндегә калмады, дип шөкер ит!

Әсма ханым. Ә сез ул әфәндене күрдегезме?

Хәнифә ханым. Ул да, барысы кебек, ач күз бер мулла. Әйе, шундый. Әфәнде казакларны ярата.

Әсма ханым. Ни өчен, ә?

Хәнифә ханым. Мәчеттә вәгазь укыганда: «Балаларыгызны казакча, ягъни русча укытыгыз!» — дия икән.

Әсма ханым. Ва-а-ай, әнекәем, мин ни ишетәм!? Моның кебек кылтаючан муллалардан кыямәт көне җитәр. *(Бишектәге бала елый башлый.)* Йокла, йокла, һай, нәни, шаян булма син, бәби-и-и. *(Бишекне тирбәтә.)*

Хәнифә ханым *(сәгатенә карап)*. Һа-а-ай! Миңа китәргә кирәк.

Әсма ханым. Нигә ашыгасыз?

Хәнифә ханым. Күп утырдым, ахирәт. *(Саубуллашалар.)*

Әсма ханым *(бишекне тирбәтеп)*. Һай-я, һай-я, һай, нәни. *(Тавышын әкренәйтеп.)* Дөресме икән? Йокла, бәгърем, син, бәби. Ничек яшәрсең? У-һу-һу, бәби-и-и. *(Бала йоклаганын күреп, чыгып китә. Дүрт-биш минуттан соң Әсма ханым кире кереп, өйнең бу ягын, теге ягын җыештыра.)* Һай, әнием, хәзер килсә?! Шайтан алгыры бу марҗаны, кунакка килергә исәп иткән. Юк! Килүе яхшы. Шәһәрдән дә берәр хәбәр-хәтәр ишетермен. Тегесен-монысын белермен. Нәрсә яхшы, нәрсәдән уңдым, ә? *(Туктальп.)* Әнә, килде шикелле. *(Ишеккә таба китә.)*

Мәрьям ханым *(килеп керә)*. Ярый әле мин килдем, юкса, онытып бетерер идегез. Шундый туганлык буламы? *(Күрешәләр.)*

Әсма ханым. Гаеп итмә, сеңлем! Йөз чиркәүле шәһәрдән сине ничек барып табасың? Берәр авылда, бистәдә

торсаң, бәлки, барыр идем, күрешер идек. Һәм дә яшьлек хатирәләрен яңартыр идек. Сезнең хәзер җеп өстендә уйнап йөрер вакытыгыз. Безгә дә килерсез, карарсыз. Яшь кызлар казаклар белән афтамафильдә йөриләрме?

Мәрьям ханым. Аллаһ-аллаһ, апа! «Җеп өстендә уйнау» дигән сүз нәрсә ул? Мин җеп өстендә түгел, юл өстендә дә уйный белмим.

Әсма ханым. Менә, ахрызаман балалары шулдыр: өйдә тормас, уйный да белмәс. Безнең вакытта уйный белмәгән кызны кешегә дә санамыйлар иде... Әйдә, утыр. Миннән яшь булсаң да, шәлеңне алып куяр идем, анысы да юк бит. *(Иңнәреннән тотып утырта.)* Әйт, сеңелкәем, эти-әнинең хәлләре ничек?

Мәрьям ханым. Шөкер. Хуҗа, Ислам морза, мондамы? Исән-иминме? *(Бишекне күреп.)* А-а-а! Саумы, Риза! *(Бишек янына килеп.)* Ни эшләп ятасың? Ни эшлисең? *(Бармаклары белән баланың иреннәрен селкетә.)* Агу, агу. Әле тешләрең чыкмыймы? Карале, кара, көлә. *(Әсма ханымга борылып.)* Һай, апам! Мондый эш буламыни? Баланың кулларын, аякларын тышаулагансыз. *(Балага иелеп.)* Нишләп сине болай мыскыл итәләр? Ах, минем энекәем! *(Баланың битеннән үбеп, урынына килеп утыра.)*

Әсма ханым. Йә, синдә нинди хәбәрләр бар? Бала күргәнең юк, чага күргәнең юк. Балаң булса, бишеккә сал, биләүлә. Үсеп буйга җиткәнче бир катырак йомшак җиренә, белсен ата-анасының кем булганын. Назлар өчен беркөн менәр башыңа: «Мин синнән акыллы, синең бернидән хәбәрең юк», — дияр.

Мәрьям ханым. Аллаһ күрсәтмәсен! Баланың кулларын, аякларын бәйләп кую эшмени? Бала арестант түгел, юкса.

Әсма ханым. Җеп бугазыңа! Теләсә ни эшлә. Син кияү таптыңмы үзеңә? Менә мине нәрсә кызыксындыра. Балаңны ничек тәрбия итәчәгеңдә эшем юк.

Мәрьям ханым. Кияү юк шул, апакаем, ю-ю-юк! Табылмый.

Әсма ханым. Менә сиңа, ә! Синең кебек бай кызны теләсә кем алыр. Аяк астында тоз булыр. Байлык бер якта торсын, синнән башка берәүне дә алмас идем.

Мәрьям ханым. Комплимент әйтәсез инде, апакаем... Аллаһ!..

Әсма ханым. Комплимент түгел, һай, дөресе шул. Сиңа диңгездәге балык кебек кияү килер.

Мәрьям ханым. Кияүләр күп, әмма...

Әсма ханым. «Әмма»сы ни тагын? Ни өчен бармыйсың, сайлыйсыңмы?

Мәрьям ханым. Ничек сайламыйм ди, апакаем? Берсе ахмак, берсе надан, кайсы бай, акыллы, ләкин аксак, йә сукыр.

Әсма ханым. Әмма шундый әйтем бар: «Бай булсаң, бир кулыңны! Фәкыйрь, кисмә юлымны!»

Мәрьям ханым. Бай морзалар күп. Ләкин миңа килешкәне юк.

Әсма ханым. Ни өчен юк? Ни өчен? Әйтче, сеңелкәш. *(Тавышын үзгәртеп.)* Һа-а-й! Туктап торчы, сеңлем, мин хәзер килермен.

Мәрьям ханым. Ни эшләячәксең, ә?

Әсма ханым. Мин онытканмын бит. Тукта, сиңа тиз генә каһвә ясап китерим.

Мәрьям ханым. Ю-ю-юк! Аллаһ ризалыгы өчен, кирәк түгел. Мин монда каһвә эчәргә килмәдем.

Әсма ханым *(тукталып)*. Күрәсең, минем каһвә ошамый. Ни булыр иде бер чокыр каһвә эчкәннән, үләр идеңме? Кеше ихтирам йөзеннән, хәтта, агу эчәр иде, агу!

Мәрьям ханым. Миңа каһвәгез ошамый түгел, аны тартып мәшәкатьләнмәгез, диюем. Каһвәдән бүген башым әйләнә инде. Барган җирдә каһвә эчмәсәм — үпкәләү, эчсәм — газап.

Әсма ханым. Беләм, сеңлем, әйтмә дә инде! Җаның теләсә, ошар, әйттем исә кайттым. Эчмисең икән, синең эш. *(Сүзне икенчегә борып.)* Әйт әле,

күзалмам, ни өчен сиңа килешле морза юк?

Мәрьям ханым. Уйлап кара! Бу бай морзаларны китер күз алдыңа! Берсе ахмак, берсе тол, берсе акылсыз, я сихерче. Соң ничек барыйм мин ахмакка? Ахмакка юләр кыз барсын.

Әсма ханым. Яхшы, ахмакка бармa ди, ә ни өчен толга бармаска?

Мәрьям ханым. Толгамы? Аллаһ сакласын! Теләк ул айның ундүртенә охшаш, теләктә һәм байлыкта Хәлилуллах булсын. Нәфрәтнең киләчәге юк.

Әсма ханым. Айның ундүртенә охшаганмы, егерме бишенәме... Халилуллах булмаса, Бейтуллах булыр, аннан нәрсә?

Мәрьям ханым. Сез мине аңламадыгыз. Никадәр бай, чибәр булсын, ахмак икән, кирәк түгел. Ахмакка юләр кыз барсын, толга тол чыксын. Тик яшь җанны якмасын.

Әсма ханым. Алай булса, син берәүне дә тапмассың. Җайдак яллап көндез ут белән бөтен Кырымны әйләнеп чыксаң да, бер генә кияү дә тапмассың!

Мәрьям ханым. Ут кабызмам, байны да эзләмәм. Наданга һәм толга бармам!

Әсма ханым. Кемгә барачаксың соң? Каян кияү табачаксың?

Мәрьям ханым. Кырымнан булмаса, Казаннан, Кавказдан булсын, тик мине чын йөрәктән сөйсен, яратсын.

Әсма ханым. Җитмәдемени черкасларның алдаганы?

Мәрьям ханым. Кемне алдады черкаслар? Ничек алдадылар?

Әсма ханым. Черкаслар түгелме, Кырымга килеп, минем шулкадәр атым, куй сарыгым бар, дигәне? Алар түгелме безгә килеп: «Мин кенәз улы!» — дигәне?

Мәрьям ханым. Соң шулай түгелме?

Әсма ханым. Әлбәттә, алай түгел. Кавказга барсаң, «Мең атым бар» дигәннең берсен дә тапмассың. Бер калеменнән башка торыр урыны, күктә йолдызы булмас.

Мәрьям ханым. Миңа нигә кирәк аның йорты, йолдызы, ә? Ул тик мин эзләгән кеше булсын, торырга урыны да, йолдызы да табылыр. Яшь яшьне сөяр, малын Аллаһ төяр, дигәннәр. Минем өчен һич кайгырмагыз, апакаем!

Әсма ханым. Чынлап та, миңа нигә кирәк бар халык өчен тырышырга, бер туганым булсын да, әмма эш икен...

Мәрьям ханым *(сәгатенә карап).* Гаеп итмәгез, апаем, миңа китәргә вакыт җиткән инде.

Әсма ханым. Нигә ашыгасың, ә? Әле иртә бит.

Мәрьям ханым. Ю-ю-юк! Мине көтәләрдер. Минем әле барасы җирем күп. *(Саубуллашалар. Әсма ханым аны озата чыга. Бераздан соң Хәсән морза кайтып керә.)*

Хәсән морза *(топчанга утырып).* Әсма, ул нинди ханым, ә?

Әсма ханым. Улмы? Мәрьям ханым. Кодалыеммы үзеңә? Аласыңмы?

Хәсән морза *(башын чайкап).* Җаны ла сөйкемле күренә, әмма миңа бармас.

Әсма ханым. Нигә бармасын? Барыр баруын, әмма кирәгендә баш ярмас, баш! Ләкин кемгә аңлатасың! Синең кебек күзле бүкән аңлармы?

Хәсән морза. Юк, Әсма, минемчә, Мәрьям ханым миңа бармас.

Әсма ханым. Менә яңалык! Кайдан беләсең син аның киләсен-килмәсен?

Хәсән морза. Мин белмим, әмма күңелем шулай сизә.

Әсма ханым. Валлаһи... синең йөрәгең «так» дип тибә. Синең күңелең каян белсен икенче берәүнең йөрәген? Шайтан түгелсең бит, юкса?

Хәсән морза. Минем акылым, Әсма, шулай ди.

Әсма ханым. Мәшаллаһ, агам, акылыңа! Мөфти кызын алсаң, аның дәрәҗәсе бар.

Хәсән морза. Мөфти кызына күз атсаң, дошманың да күп булыр.

Әсма ханым. Дөрес уйлыйсың! Мәрьям: «Мин наданга, толга бармыйм. Фәкыйрь булса да, кулы алтын булсын, башында акыл булсын, мине чын йөрәктән яратсын, сөйсен», — ди.

Хәсән морза. Әйттем бит, миңа килмәс, дип.

Әсма ханым. Мәрьям ни дисә дә, әгәр мин ир булсам, аның йөрәген яулап алыр идем.

Хәсән морза. Синме? Йә, ничек яулар идең?

Әсма ханым. У-у-у-й! Шушы да ирме инде? Әгәр мин ир булсам, дөньяның астын өскә китерер идем. Мәрьям ханым кебек кенә түгел, хур кызлары алыр идем, хур кызлары! Теләгенә каршы үгетләр идем. Үзе килеп керер иде өемә, аңладыңмы? Башыңа җиттеме?

Хәсән морза. Гаҗәп. Син ничек күндерер идең аны?

Әсма ханым. Тыңла. Кыз дигәнең үрмәле гөл кебек. Бер сарылса, синнән һич аерылмас. Электергече, ыргагы бик көчле! Булыр-булмас кешенең кулыннан килмәячәк.

Хәсән морза. Сүз уңаеннан, син ир булсаң, сарылдырыр идеңме Мәрьям ханымны?

Әсма ханым. Әлбәттә, бик теләп. Алыр идем бер машинамы, афтамафильме, бер-ике тапкыр гөрелдәп үтәр идем аның өе яныннан. Аннан бер йомыш табып барыр идем дә: »Мөмкинме сезне бер йөртеп кайтарырга?» — дип, янәшәгә утыртып алып китәр идем. Дүрт-биш көннән тагын барыр идем, бер яхшы бүләк алыр идем. «Сез яхшы, сез чибәр, җаным», — дигән татлы сүзләр әйтер идем. Карыйсың, сарылды да китте. Миннән бер генә дә аерылырмы? Тол түгел, аксак, сукыр булсаң да җайга килер иде. Кемгә аңлатам соң?

Хәсән морза. Юк, алай булмас! Афтанафиль аласым, өенә барасым, бүләк аласым да, шулай кыз күндереп өйләнәсем дә булмас. Башымда бераз җитмәсә дә алай өйләнмәячәкмен! Син миңа башка кыз тапчы.

Әсма ханым *(көлемсерәп)*. Татар кызы булсынмы?

Хәсән морза. Татар кызы? Аллаһ күрсәтмәсен! Морза кызы юкмы?

Әсма ханым. Морза кызлары күп, тик телләре чәчләреннән озын.

Хәсән морза. Башта мине өйләндер дә, соңыннан чәчсез, телсез кыз эзләрсең.

Әсма ханым. Әйт соң, абзыкаем, син нинди кыз телисең, байнымы, йә чибәрнеме?

Хәсән морза. Иң башта бай булсын, чибәр дә булсын, яшь тә булсын. Диндар булсын, биш вакыт намазын кылып, Коръән укысын.

Әсма ханым. Һич белмим, андый кыз табылырмы икән?

Хәсән морза. Нишләп табылмасын, шайтан алганмы дөньядагы кызларны?

Әсма ханым. Шайтан алмады, ләкин алар шайтан котыртуында. Коръән укучы, намаз кылучы кызлар бик аз хәзер.

Хәсән морза. Җирәнгеч эш. Шайтан кеше холкын тәрбияли аламы?

Әсма ханым. Ә фәрештәләрне кем укытты? Шайтан түгелме?

Хәсән морза. Миңа синең шайтаның да, фәрештәң дә нигә кирәк? Син миңа кыз тап!

Әсма ханым. Син утырып тор, мин барып, белешеп киләм. *(Чыгып китә.)*

Хәсән морза *(җебеннән тартып тартмасын ача һәм сигара алып кабыза да, сөйләнә башлый)*. Юк! Рәхәт яшәмим, дип әйтмим. Тәңремә шөкер. Кырык яшемә җиттем, дөньяны да күрдем. Акмәчеткә бардым, Бахчасарайга бардым, бик күп авылларда йөрдем. Намаз кылганымны да күрәләр. Беләм, кем бусагасын атлап керсәм дә, буш кайтмыйм. Мәрьям булмый икән, Сафия булыр, Сафия булмаса, Әминәсе килер. Миңа барысы да бер. Тик миңа ошаган кыз булсын. *(Бераз уйлап торганнан соң, башын калкытып.)* Йә, Раббым! Бу өйләнү яхшы эштер. Моннан да татлы ни бар икән? Өйләнерсең,

бар ягың җыештырылыр, үзең дә курчак кебек йөрерсең. Өйләнгәч, сиңа сөеп дәшәрләр: «Морзам монда, морзам анда», диярләр. Өйләнгәч, уллар, кызлар булыр һәм нindiләре генә әле, пестә чикләвеге кебек түгәрәкләр! Малайлар «әти», дип мыекларымнан тартыр, күзгә бармакларын тидереп уйнар. Кызчыклар булса, шәһәргә барган саен берсе: «Әти, миңа курчак алып кайт», икенчесе: «Миңа шәл алып кайт», дияр. Ә гүзәлләрдән дә гүзәл, түгәрәк, йомшак хатыныма — мамык ястык. Менә гомер, менә кайда кәеф-сафа. Өйләнергә кирәк, кичекмичә. Кичекмичә! *(Уйга кала.)* Аллаһ кем кызын бәхетемә җибәрә икән? Морза кызы икәнен беләм, чөнки Тәңрем, җиргә — күкне язган, суга — туфракны, татарга — татар кызын, безләргә исә — морза кызын. Аллаһ! Кем икән минем язмышым?

Әсма ханым *(килеп керә)*. Әйтиемме?

Хәсән морза *(аптырап)*. Аһ! Аз гына аңымнан язмый калдым.

Әсма ханым. Һа-а-а-й! Беркем янында әйтмә андый сүзләрне.

Хәсән морза. Ә нигә? Ни булыр, Әсма?

Әсма ханым.Ниләр булмас? «Мин акылсыз кешегә бармам», — диярләр. «Мондый ирдән ни көтәргә?» — диярләр.

Хәсән морза. Әйт, сеңелкәш, битемдә сакал-мыек бар түгелме?

Әсма ханым. Бар, соң.

Хәсән морза. Соң, ир икәнмен ләбаса? Акылсыз димә, барсын дисәң! Зур эшкә тотындык бит. Бу мине куркытмый. Акыл дигәннән, акыл — ул карлыгачтыр, очып килер, очып китәр.

Әсма ханым. Бер куркытып кара! Бер дә килмәс.

Хәсән морза. Куркытканым юк. *(Сүзне борып.)* Син миңа кыз таптыңмы, шул кызык миңа?

Әсма ханым. Таптым, ләкин син миңа ышанырсыңмы?

Хәсән морза. Нишләп ышанмыйм? Туган туганга яманлык теләми.

Әсма ханым *(кулларын бутап)*. Пфу-у-у! Хәзерге туганнар яманлык түгел, хәтта үлем дә теләр, талап та бетерер.

Хәсән морза. Ә син?

Әсма ханым. Менә сиңа мә! Мине хәзергәчә кем булганымны белмәдеңме? Мин сиңа кайчан яманлык теләдем? Башкаларга сине мактар өчен җанымны фида кылам.

Хәсән морза. Синең җаның ирeңә фида булсын. Кайда әле ул? Син миңа башта җаный тап. Яшь җаный, яшь! *(Сүзне икенчегә борып.)* Чыннан да, кайда ул Ислам морза?

Әсма ханым. Ул базарга китте.

Хәсән морза. Ә, ни эшли?

Әсма ханым. Чалгы машинасымы, нәрсәдер алачак.

Хәсән морза *(төшенмичә калып)*. Инде печән өсте дә килеп җиттемени?..

Әсма ханым *(бераз күзенә карап торгач)*. Ни булды? Ни дип уйга калдың? Элек үзең булышачак кебек идең?

Хәсән морза. Үзем булыша алмыйм, ә приказчигым булдыксыз егет.

Әсма ханым. Булдыксыз булса, булдыклысын тот, синнән тора ул.

Хәсән морза. Шулай, әмма...

Әсма ханым. Әммасы-мәммәсе нәрсә тагын? Ир була белмисең. Валлаһи, күзле бүкән кебек. Берсе көлеп, «диңгез янды», дисә, «янмас», диячәксеңме? Хезмәтчеләрең: «Бу болай булсын, морза, бу тегеләй булсын», дисә, «Алай булмасын», димәячәксеңме? Мондый хуҗа буламы? Приказчигың җирләреңне сатып китсә: «Ни өчен саттың?» дип сорамаячаксыңмы? Син ялгыш тугансың ир булып.

Хәсән морза. Бер сүзне күпкә сузсаң, гауга чыгар, ди. Син кемне таптың соң?

Әсма ханым. Сиңамы? Бер кыз таптым, әмма дөнья чибәренең чибәре!!! Бер тамчы су кебек, йот та җибәр. Чәчләре дисәң, җир себереп китәр.

Хәсән морза. Ул кадәр озын чәчле кыз кирәк түгел. Бер яктан икенче якка күчкәндә җилкәмә уралыр.

Әсма ханым. Тыңла әле син мине!

Матур чәчле, алсу яңаклы. Әфлисун шикелле.

Хәсән морза. Алай да ярамый.

Әсма ханым. Ә ни өчен?

Хәсән морза. Кунакка барганда яки кунаклар килгәндә, соклансалар? Берәр нишләтсәләр?

Әсма ханым. Курыкма, берәү дә синең хатыныңның яңакларыннан үпмәс. Каян килгән ахмаклык ди ул? *(Сүзне икенчегә күчереп.)* Ә иреннәре дисәң, уймак кебек. Шундый матур, ягымлы, сөйкемле һәм холкы да начар түгел.

Хәсән морза. Юк, миңа туры килә торган түгел бу.

Әсма ханым. Йә, нилектән?

Хәсән морза. Бер аш ашаганда утыр аның белән өч сәгать! Бу эшме? Нигә кирәк ул уймак авызлы кыз?

Әсма ханым. Менә бу бер дурнойлык инде. Син бөтенләй дә белмисең икән кызлар турында!

Хәсән морза. Соң, шулай түгелмени?

Әсма ханым. Күзләре дисәң, зур йодрык кебек.

Хәсән морза *(кулларын бутап).* Кирәк түгел, кылый икән син тапкан кыз. Аллаһ күрсәтмәсен, минем башка бәла китермәкче икәнсең.

Әсма ханым. Менә-ә, кыл изгелек — көт явызлык.

Хәсән морза. Йә, үзе симезме, ябыкмы?

Әсма ханым. Пестә чикләвеге кебек тулы гәүдәле һәм дә йомшак.

Хәсән морза. Ә баймы?

Әсма ханым. Бик бай да түгел, бик ярлы да түгел. Уртача.

Хәсән морза. Аның бераз җире бармы? *(Сүзне икенчегә борып.)* Фәкыйрь түгел, диюең ничек була инде?

Әсма ханым. Әйтәм бит, уртача, дип.

Хәсән морза. Ә миңа килерме?

Әсма ханым. Мин бу эшне башлаган, ахырына кадәр чыгармын. Ул нәрсә дияр?!

Хәсән морза. Бирнәсе бармы, Әсма, бирнәсе?

Әсма ханым. Мин әле үз акылымда. Сиңа бирнәсез кыз димләргә!

Хәсән морза *(төшенмичәрәк торгач).* Гаҗәп, кем икән бу? Кемнең кызы икән? *(Күтәрелә төшеп.)* Мин беләмме ул кызны?

Әсма ханым. Әйтиемме? Юк! Уйлап кара.

Хәсән морза *(озак уйлаганнан соң).* Үзең әйтче! Тилмертмә мине!

Әсма ханым *(көлемсерәп).* Оят, гарьлек! Таба алмый, имеш. Юк, уйла.

Хәсән морза *(тагын уйлаганнан соң).* Һич исемә төшми. Әйтче үзең!

Әсма ханым *(әкрен генә).* Айшә ханым. Карт морзаның кызы. Ошыймы? Ничек, мин тапкан кыз?

Хәсән морза *(куанычыннан сикереп торып).* Бир кулыңны, бирче!

Әсма ханым. Шуннан нәрсә булыр?

Хәсән морза. Бирче үбәм, бирче!

Әсма ханым. Утыр, утырган җиреңдә. Ир кардәше сеңлесенең кулын үбәр? Булмаганны.

Хәсән морза *(урынына барып утырыр).* Мин бит тол ир, миңа килерме?

Әсма ханым. Нигә килмәсен? Биш йөз дисәтинә җирең бар, аксак та түгелсең, сәламәтсең. Нәкъ карт морзалар теләгән адәм. Синнән дә яхшыны тапмаслар.

Хәсән морза. Алай булса, кодалыйк!

Әсма ханым. Кияү шәһәрдән килсен дә, ничек бармасын? Тик син кызуланма! Башта кучереңны яңа киемгә киендер. Фаэтоныңны әзерлә, күр, таза атлар тап.

Хәсән морза. Барысы да булыр. Онытма, сүз бирдең кодаларга барырга. *(Торып саубуллашалар.)*

Әсма ханым *(абыйсын озатып кергәннән соң).* Ни эшләем?! Кызны таптым. Алга, кыю бул, Әсма ханым! *(Йодрыкларын угалый.)*

Пәрдә төшә.

Ахыры киләсе санда ■

ИСЕМДӘ ДӘ, ҖИСЕМДӘ ДӘ ИСӘН БЕЗ!

Татар һәм гагауз топонимиясендә кайбер параллельләр

Фирдәвес Гарипова

Татар топонимиясен нәтиҗәле анализлау өчен төркиләр һәм төрки булмаган халыклар яши торган, яки элек яшәп киткән җирлекләрнең географик атамаларын чагыштырма материал буларак файдалану зарур. Мондый ысул белән эшләү фәнни хезмәтнең нәтиҗәлелеген арттыра, этимологик экскурсларның дөреслегенә нигез була. Шушы җәһәттән чыгып караганда, татар һәм гагауз топонимиясен чагыштырып карау кызыклы мәгълүмат бирә.

Гагаузларның гомуми хисабы – якынча 250 мең. Иң күп өлеше Молдовада (2004 елгы мәгълүмат буенча 147,5 мең), Украинада (2001 елгы мәгълүмат буенча 31,9 мең), Россиядә (2010 елгы мәгълүмат буенча 13,690 мең) яши. Алар тагын Төркия, Греция, Болгария, Румыния, Казахстан төбәкләрендә гомер сөрә.

Гагаузларның Молдованың көньягында *Гагаузия (Гагауз-Ери)* автономияле территориаль берәмлекләре бар. Биредә исә 127,8 мең гагауз яши. Бу җирле халыкның 82% дигән сүз.

Гагауз авыллары төньяктан көньякка таба 100 чакрым чамасы сузылган. Иң төньяктагы гагауз авылы Бавырчы

Ana Sözü

"ANA SÖZÜ" GAZETESİ'nin REDAKSİYE KOLEKTİVİNE

"Bünün gagouz halkın sevincini paylaşıyorum"

Latin grafikasına - BİRLİKTE!

— Молдованың Кэинар районында, иң көньяктагысы — Прут-Днестр елгалары аралыгында, Украинаның Одесса өлкәсендәге Рений районында.

Гагауз теле төрки телләрнең көньяк-көнбатыш ареалындагы угыз төркеменең угыз-болгар төркемчәсенә керә. Гагаузия автономиясендә гагауз, молдова һәм рус телләре рәсми тел санала. «Ana Sözü» исемле милли газета чыга, Acik TV телеканалы эшли. Гагауз халкы христиан динен тота.

Гагауз сүзенең килеп чыгуына карата галимнәр арасында төрле фикер бар. А.фон Габен бер хезмәтендә: *«Безнең эраның 551-552 елларында Үзәк Азиядә барлыкка килгән борынгы төрки империя VII гасыр башларында икегә бүленә... Империянең көнчыгышында табылган зур руник язмаларда монда яшәүче халыкның «күк төркиләр» («голубые тюрки», «кёк тюрк») дип йөртелүе әйтелгән»,* — дип яза. Көньяк (кызыл төс), төньяк (кара төс), көнбатыш (ак төс), көнчыгыш (күк төс) — төсләрнең шундый символик бүленеше фәнни әдәбиятта бар.

Шулай ук В.В.Бартольд хезмәтләрендәге төс символикасына таянып, кайбер галимнәр гагауз этнонимындагы *гок (~ кок)* терминында «о» авазының «а» га күчүен һәм гага компоненты барлыкка килүен исәпкә алып (мәсәлән, хазар — борынгы рус. *хозар*), *гагуз* <*гок огуз* = *күк угыз* (көнчыгыш *угыз*) дип этимология ясый. Гагауз этнонимындагы төс символикасы Бессарабия гагаузларының милли киемнәрендә *зәңгәр (~ күк)* төснең шактый урын алып торуында да чагылыш таба. Гагаузия автономиясе байрагының күп өлеше зәңгәр төстән тора. Гагауз этимологиясе мәсьәләсендә 19 төрле фикер бар һәм алар да игътибарга лаек.

Прут һәм Днестр елгалары арасында төрки халыклар һәм аерым этник төркемнәр, һуннар чорларыннан башлап, күчмә һәм утрак тормышта яшәгән. Шуларның берсе — хәзерге гагаузлар — нигездә Буджак җирләренә төпләнгән. Буджак җирләре — Прут-Днестр елгаларының түбән агымындагы тарихи өлкә. Галимнәр аны төрки-татар *вуджак* 'чит, кырый' сүзе белән бәйләп аңлата. Бу топонимик берәмлек Азәрбайҗан, Төркмәнстан, Румыния, Болгария һәм Төркия топонимиясендә очрый.

Гагаузлар, тарихи әдәбиятта «узи санджак» яисә «узи эйялет», ягъни узлар, угызлар өлкәсе дип йөртелгән Төньяк-Көнчыгыш Болгариядән күчеп, алар Буджакта нигезләнә. Ә бу җирләрдә элек нугайлар яшәгән. Гагаузларның байтагы нугайлар белән урнаша, яки алар яңа авыллар торгыза. Аерым урыннарда молдаваннар белән яши башлыйлар.

Буджактагы гагауз авылларының атамалары төрки, галимнәр фикеренә күрә, нигездә, нугайларга барып тоташа: Аударма, Анадол (1947 елда Долинский дип үзгәртелгән), Баурчи, Гайдар, Жолтай, Дезгинджя, Етулия, Казаклия, Карабалия, Каракорт (1944 елда Жовтневое дип үзгәртелә), Кирәйет-Лунга, Комрат, Конгаз, Кип-

чак, Кубей (1940 елда Червоноармейское дип үзгәртелә), Курчи (1945 елда Виноградовка дип үзгәртелә), Салтык-Хаджи (Александровка дип алыштырыла), Чадыр-Лунга, Чишмәкәй, Чок Мәйдан.

Гагаузларның бер өлеше көнчыгыш роман һәм славян телле халыклар арасында ассимиляцияләнә. Бу бигрәк тә Молдованың төньягында һәм үзәк районнарында була. Мондый күренеш кеше исемнәрендә дә чагылыш таба.

Прут-Днестр елгалары аралыгында, Молдовада төрки атамаларның күбәюе урта гасырлардагы төрки кабилә-кавемнәр, нигездә, бөҗәнәк, угыз, команнарның Төньяк Кара диңгез буйларында күченеп йөрүе һәм шул ук вакытларда аерым урыннарда утраклыкка күчүе белән дә бәйләнешле. Шуны искәртергә кирәк, урта гасыр чыганакларында Днепр һәм Днестр елгалары Идел дип аталып йөртелә. Константин Багрянородный мәгълүматларына караганда, X йөздә бөҗәнәкләр Түбән Днестр һәм Дунай буйларында ныклап урнашкан. Аларның эзләре тарихи чыганакларда һәм румын Добруджасында бөҗәнәк (печенег) топонимы белән сакланып калган: *«Бөҗәнәкләр Днепр һәм Днестрның түбән агымнарында һәм шул тирәдә аккан башка елгалар буйларында урнашкан... Днестрның Болгария ягында, елга кичүе тирәсендә бушап калган шәһәрләр бар; аларның беренчесе — бөҗәнәкләр шәһәре Белым[1]. Бу крепость-шәһәр хәзерге Белгород-Днестровский урынында булган. Икенче шәһәрләре — Тынгаты[2]. Бөҗәнәкләрнең (печенегларның) атамалары — кангар, ләкин бөтенесенеке дә түгел, өч округ халкы гына шулай йөртелә...»*. Азәрбайҗанда әүвәлдән кулланыла торган Гангар топонимы бар. Бу атаманың килеп чыгышы, күп галимнәр фикеренчә, Константин Багрянородный искә алган Кангар этнонимына барып тоташа. Азәрбайҗаннар да — телләре ягыннан төрекмәннәр, төрекләр, кырым татарлары, гагаузлар белән бергә угыз төркеменә керә торган халык. Угыз төркеменә керә торган халыкларда сүз башында һәм сүз ахырыңда яңгырау тартыклар кулланыла. Татарстанның Азнакай районында бер матур тау Чатыр тау исемен алган. Ә Кырымда бу атама Чатыр даг рәвешле кулланыла.

Язма чыганаклар хәбәр итүенә күрә, 1064 елларда Дунайның сул ярында күп санда торклар (угызлар) яшәгән. Бөҗәнәкләр һәм торклар (угызлар) артыннан Карпат-Днестр регионына половецлар — команнар килеп урнаша. XIII йөзләрдә Дунай буйлары Куманиясе Түбән Дунай далаларының Улт елгасына кадәрге өлешен биләп тора. XIV йөзнең беренче яртысында Түбән Дунайның көньягындагы Добруджада куман милли үзәге яшәгән һәм үсеш кичергән. Дунай буе Куманиясенең көньяк-көнчыгыш өлешендә гагауз этник берлеге барлыкка килә. Команнарның Карпат-Днестровье төбәкләрендә яшәгәнлекләрен коман компонентын эченә алган топонимнар һәм румыннар арасында Коман исеме еш очравы күрсәтә. Прут-Днестр елгалары аралыгына 1538 елдан соң төрек администрациясе арадашлыгы белән Көньяк Рус далаларыннан нугайлар һәм азрак санда кырым татарлары күчеп утыра.

Галимнәр фикеренә күрә, Прут-Днестр топонимиясендәге борынгы катлам һуннар, соңрак аварлар һәм борынгы болгарларга мөнәсәбәтле. Бу катламнан соң төрки топонимнарны, гидронимнарны команнар һәм азрак санда угызлар, бөҗәнәкләр калдырган. Кайбер галимнәр бу катламга Днестр елгасының төрки-коман аллонимы Торлыны һәм ойтыз компонентлы атамаларны кертә. Молдованың Таракли

[1] Ошбу атама Урта Идел буйларындагы Балым, Балыматыга тартым.
[2] Анатолий һәм Балкан төркиләренең бөтен шивәләрендә Дунайның хәзерге атамасы Тына дип атала.

районындагы Кирилловка авылы элек Ойтыз атамасы йөрткән.

Днестр-Карпат җирләренең көньяк-көнчыгыш өлешендә икътисади яктан алга киткән Алтын Урданың бер өлкәсе оештырылуы Прут-Днестр аралыгындагы территорияне хуҗалык ягыннан әйбәт үзләштерүдә тирән эз калдыра. Бу вакытлардагы үзгәрешләр топонимия, гидронимия һәм антропонимия өлкәләрендә дә чагылыш таба. Бу чорда барлыкка килгән географик атамалар: Табан, Тугыз, Бахмут, Татар Манысы, Татарлар, Татаран, Тонгүзән, Татарка, Чаукар һ.б.

Бессарабия һәм Буджак җирләре этник яктан бик чуар була. XVII йөздә төрек сәяхәтчесе Әүлия Чиләби Буджак төркиләрен түбәндәге исемнәр белән атый: *«...Әдил нугайлары һәм буджак татарлары», «...Ногай һәм буджак татарлары», «...Нугай һәм яр буе татарлары»*. Әүлия Чиләби хезмәтләреннән күренгәнчә, Буджакта, Днестр һәм Дунай елгаларының түбән агымнарында нугайлардан башка тагын татарлар да яшәгән. Молдова елъязмачылары Мирон Костин (1633-1691) һәм Ион Никулче (1672-1745) нугайларны башка төркиләр – буджак татарларыннан һәм кырым татарларыннан аерып караган. Ион Никулче буджак нугайларын *нохай* дип, бу тирәләрдә нугайлардан күпкә борынгырак чорларда яшәгән буджак татарларын бужежень «буджаклылар» дип атый. Ничек кенә булмасын бу тирәләрдәге төркиләр һәрдаим изү астында яши һәм төрле урыннарга күченергә мәҗбүр ителә. Зур күченешләр XIX йөз башларына туры килә. 1806 елда русларның бер отряды белән җитәкчелек иткән генерал Ришелье нугай татарларына һәм буджак татарларына Россиянең Кырым, Екатеринослав һәм Херсон губерналарына күченеп утырырга фәрман бирә. Төркиләр кайда гына яшәсәләр дә, үз эзләрен топонимнарда, гидронимнарда һәм кеше исемнәрендә калдырган.

Татар һәм гагауз халыклары топонимиясендә кеше исемнәрендә уртаклыклар байтак. Уртаклыклар булмаса, гаҗәп тә булыр иде. Гомумән, төрки халыклар, шул исәптән татар һәм гагаузларның да килеп чыгышы (этногенезы) катлаулы, алар бер компоненттан гына тормаган. Топонимиянең нигез ташы булган терминнардагы уртаклыклар таблицалардан күренә.

Кестрич авылы гагаузлары. XX гасыр башы

Татар һәм гагауз телләрендәге кайбер географик терминнар

№	Татар телендә	Гагауз телендә	Терминның мәгънәсе
1	агач	аач	агач (дерево)
2	арт	аард	арткы өлеш, җилкә
3	баш	баш	баш (елга башы)
4	бил	бел	бил (поясница, хребет), тау сырты
5	борын	бурун	борын
6	ерык	ирик	чокыр, инеш
7	җир	ер	җир
8	кайнар	кайнак (чишмә)	кайнаррак
9	комлык	кумлук	комлык, песчаник
10	көллек	куллук	көллек (пепелище, золище)
11	култык	колтук	култык (залив)
12	күз	гёз	күз
13	күл	гёл	күл
14	мазар	мезар	зират
15	мәхәллә	маала	мәхәллә
16	өек	уук	курган
17	пай	пай	надел (земельный надел)
18	саз	саз	саз (болото)
19	су	су	су (вода)
20	сырт	сырт	кабырга (хребет)
21	тар	дар	тар, кысан
22	тирән	дерин	тирән
23	туфрак	топрак	туфрак (земля)
24	түбә	тепа	калкулык, курган
25	чишмә	чешме	күз, чыганак
26	чокыр	чукур	чокыр, балка
27	югары	йукаркы	югары (верхний)
28	юл	йол	юл (дорога)
29	яр	йар	текә яр

Топонимнар

№	Татар телендә	Гагауз телендә	Терминның мәгънәсе
1	Алакай мәхәлләсе	Алакай маалеси	Алакай мәхәлләсе
2	Ике курган, ике түбә	Ики тепа	Ике калкулык, курган
3	Иске ташлык	Ески ташлык	Иске ташлык
4	Комлык	Кумлук	Комлы урын
5	Мамай яры	Мамайлар йары	Овраг семейства Мамай
6	Мишә чокыры	Мешен чукуру	Мешенский овраг
7	Муса юлы	Муса йолу	Муса юлы
8	Сасы күл	Сасы гол	Сасы күл
9	Чокырлык	Чукурлук	Чокырлык
10	Яңа җир	Ени ер	Яңа җир

Мондый терминнар һәм топонимнар Кырым топонимиясендә дә очрый.

Антропонимнар

	Гани	Гани
1	Акбаш	Акбаш
2	Акчибаш	Хакчыбаш
3	Ашлы	Ашлы
4	Болгар	Булгар
5	Гали	Гали
6	Көчек (шәҗәрәләрдә)	Көчек
7	Кылчык (шәҗәрәләрдә)	Кылчык

Этнонимнар; гелеонимнар

Урум, дуван, татар, алакай, бодырак, туркмен, нугай, кыпчак, уз/гуз/угыз, канлы/канглы, татар	Дуган/дуван, татар, кирәет, татар, алакай, бенеюз, урум, йайман, пытырак (бодырак), туркмен, ногай, кыпчак, гуз/огуз, канглы

Шунысы куанычлы, төрки топонимнарны җентекләп өйрәнү өлкәсенә, аеруча аның тарихи фонетика, тарихи морфология тармагына яңа материаллар өстәлә. Киң территориягә таралган атамаларны караганда, тарихи фонетика калку булып күзгә ташлана. Моның нигезендә татар халкының килеп чыгышы — этногенезы мәсьәләләрендә дә беркадәр мәгълүмат табарга була. Төрки кабилә-кавемнәрнең үзара мөнәсәбәтләре дә ачык күренә. Алар истәлеге топонимнарда сакланган. ■

ЕРАКТАГЫ ЯКЫН КАРДӘШЛӘР

Лирон Хәмидуллин

Урта Азия биләмәсенең көнбатыш тарафында, Арал диңгезеннән көньяктарак, безгә кардәш каракалпак халкы яши. СССР мәмләкәтенә кергән, 1920 нче еллардан бирле үз милли мохтарияте булган бу төрки кавемнең сөйләм теле безнең телгә бик якын, бераз мәгълүматы булган һәркем ул телдә язылган әдәбиятны укып аңлый ала.

1980 нче елларда Каракалпакстан АССРның төп халкы 220 мең чамасы иде. СССР оешкан чорда, ул милли мохтарият хокукын алуга ирешкән иң аз санлы төрки кабилә була. Каракалпакларның бер өлеше күрше Казахстан, Үзбәкстан, Төрекмәнстан республикаларында һәм Әфганстан илендә дә гомер кичерә, дип хәбәр итеp «Каракалпакстан АССР тарихы» (1975) китабында. Күренекле тарихчы һәм археолог С.П.Толстов язуынча («Древний Хорезм», 1948), каракалпаклар борынгы Хәрәзем дәүләте чорынннан бирле Амударья буенда яшәгән. Бу төрки кавемнең исеменә карата төрле фикерләр йөри. Татар тарихчыларыннан кайберләре аларны «кара калпак киеп йөргәнлектән шулай аталганнар», дип белдерә. Бу фикерне дәлилләү өчен, алар Кавказ халыкларының да кайберләрен, кызыл түбәле баш киеме кигән өчен, тарихи

Арал дельтасындагы каракалпак юртасы. 1930 нчы еллар

хезмәтләрдә «кызылбашлар» дип язалар, димәкчеләр. Минемчә, бу хата фикер. Бу исем аларга бик борынгыдан килгән гореф-гадәтләренә бәйле рәвештә бирелгән. Бу кавемнең ир затлары, унике яшьтән алып картайганчы, баш түбәсендә бер учма чәчне калфак рәвешендә урап йөрткәннәр. Кавем исеме дә шул чәч үременә бәйле рәвештә барлыкка килгән. Урта гасырларда каракалпакларның бер өлеше кыпчак кабиләләре белән бергә Днепр, Дунай буйларына барып җиткән. Аларның Киев кенәзе Юрий Долгорукийга тугрылыклы хезмәт итәргә вәгъдә биргән сүзләре рус елъязмаларында теркәлеп калган. Соңрак, үз кавеменнән аерылып, ирекле казак рәвешендә яшәүчеләре дә була. Шуларның бер төркеме, борынгы йолаларын саклап, баш түбәсендә бер учма чәч йөртүче «чубатый казак»ка әверелгән.

СССР хакимияте елларында каракалпаклар яшәгән җирләр элегрәк Казахстанга да, РСФСР биләмәсенә дә кергән. 1936 елның 5 декабреннән ул төбәк хәзерге Үзбәкстан Республикасы буйсынуында яши. Каракалпакстанның Тел, әдәбият һәм тарих институты директоры, профессор Кабул Максютов заманында «Амудәрья» журналында: «XX гасыр башында татар телендә елына өч йөзгә якын китап басыла иде, аның йогынтысы каракалпак халкына да җитеште… Г.Тукай ише олуг әдипләр барлык төрки телле халыкларның сөекле шагыйренә әверелделәр. Каракалпак язучылары, шагыйрьләре алардан үрнәк ала иде», — дип язды.

Милләттәшебез, Казан артындагы Үртәм авылында 1869 елда туган Сәйфелгабит Мәҗит тә — каракалпак әдәбиятын һәм мәдәниятен үстерүгә зур өлеш керткән шәхес. Улына сигез яшь тулганда Мәҗит абзый, бәхет эзләп, Урта Азия якларына таба чыгып китә. Сәйфелгабит казах, каракалпак балалары белән аралашып үсә. Яшь вакытыннан ук ул олуг акын Бердах белән танышу, аралашу бәхетен дә татый. Шигъри әйтешләрдә дә катнаша. 1905 елгы вакыйгалардан соң татар телендә газеталар чыга башлагач, кайбер иҗат үрнәкләрен шуларга да җибәргәли. Аның беренче каләм хезмәте 1907 елда ташбасмада басылып чыккан, дип санала. Каракалпакстанда совет хакимияте урнашкач та турыдан-туры аның катнашында «Беренче адым» (1924), «Иркен Каракалпакстан» газеталары (соңгысында ул җаваплы сәркатип тә), «Хезмәт әдәбияты» (1931) журналы чыга башлый. Әлеге матбугат чараларында каракалпак телендә иҗат ителгән беренче проза әсәрләре дә дөнья күрә. Бу елларда С.Мәҗитовның «Сөен белән Сара», «Җомагол», «Байбәтчә» һ.б. исемнәрдә күләмле проза әсәрләре басылып чыга. Алты пьесасы («Ирназар батыр», «Соңгы киртә», «Багдагөл», «Гөләм — Тайман» һ.б.) яңарак оешкан драма театры артистлары тарафыннан сәхнәләштерелә. С.Мәҗитов 1934 елда СССР Язучылар берлегенә кабул ителә. 1938 елда Нәкис шәһәрендә вафат була.

1970 нче еллар ахырында Татарстан Республикасы башлыклары һәм Язучылар оешмасы җитәкчелеге Үзбәкстанда татар әдәбияты һәм мәдәнияте атналыгын уздырырга, анда яшәүче берничә йөз мең кешедән торган якташларыбыз белән очрашулар оештырырга хыялланган иде. Әмма Мәскәү түрәләре рөхсәт бирмәде. Автономияле республика оешмалары үз дәрәҗәләрендәге оешмалар белән генә шундый аралашу гамәлләрен булдыра ала, диделәр. Шулай дигәч, Үзбәкстан кардәшләребезнең түрәләре андый очрашу оештыруны Каракалпакстан җитәкчеләренә йөкләгәннәр иде. 1980 елда Татарстаннан ул чарада йөздән артык кеше катнашты. Обком секретаре Мирзаһит Вәлиев җитәкчелегендәге делегациягә барлык күренекле язучылар да, артистлар һәм мәдәният оешмалары түрәләре дә кергән иде. Нәкъ шул атналык нәтиҗәләреннән соң иң-иң күренекле каләм әһелләренә һәм артистларга Каракалпакстан Республикасының мактаулы исемнәре бирелде. Шул уңай белән, үзбәк һәм каракалпак телләрендә

Татарстан язучыларының әсәрләре өч китапка туплап чыгарылды.

Каракалпак халкы татар әдәбияты ядкярләре белән элек-электән таныш булган. Каракалпак телендә «Идел — илнең ишеге, Җаек — җирнең бишеге» дигән әйтем дә сакланган. 1970 нче елларда татар шигърияте үрнәкләрен каракалпак теленә актив тәрҗемә итүчеләр буларак, Ибраһим Йосыпов, Таҗетдин Сәетҗанов, Бабаш Исмаилов истә калган. И.Йосыпов, шул елларда Язучылар берлеге рәисе буларак, Казанга да берничә мәртәбә килгән иде. Каракалпак телендә ул Г.Тукай, Һ.Такташ, М.Кәрим шигырьләрен бастырып чыгарды, татар әдәбияты тарихына бәйле мәкаләләр дә язды. Мин, аның бер күләмле мәкаләсен тәрҗемә итеп, «Социалистик Татарстан» газетасында чыгарган идем. Галим һәм шагыйрь Бабаш Исмаилов та Г.Тукай, И.Юзеев һ.б. татар әдипләренең иҗат үрнәкләрен үз халкына җиткерүчеләрдән булды.

1981 елның май аенда Татарстанда каракалпак әдәбияты һәм мәдәнияте атналыгын оештыру чараларын барлар өчен дип, Казанга Каракалпакстанның мәдәният министры, Язучылар берлеге рәисе һәм тагын берничә түрә килеп киткән иде. Шул уңайдан Татарстан китап нәшрияты 26 табаклы калын китап бастырып чыгарган иде. Ул китапның төзүчесе, оештыручысы мин булдым. Кунаклар ул мәҗмуганы бик югары бәяләделәр, «әле үзебездә дә мондый каракалпак әдәбияты антологиясенең нәшер ителгәне юк», — диделәр. Китап минем кереш мәкалә белән башлана. Аннары Әҗинияз, Бердах, Сәйфелгабит Мәҗитов һ.б. иҗатлары белән укучыны таныштыра.

Шушы томны туплар алдыннан миңа да Каракалпакстанда булып кайтырга туры килде. Мин Каракалпакстан язучыларының 8 нче съездына чакырулы идем. Алтмышлап язучыны туплаган ул корылтай ике көн дәвам итте. Башкорт әдәбияты вәкиле буларак, анда Нәҗар ага Нәҗми дә катнашты. Шул көннәрдә төшерелгән бер фотоны игътибарыгызга тәкъдим итәм. Каракалпак халкының батыр, олуг шәхесләре истәлегенә куелган хатирәле урынга чәчәкләр салучылар арасында, алгы рәттә сулда — мин, уңда басып торучы — Каракалпакстан Язучылары берлегенең яңа рәисе, халык язучысы Теләпбиргән Каипбиргәнев. 1980 ел, 9 сентябрь. ■

ҖӘЙРӘННӘР

Әбдиморат Атаҗанов

Төн. Үзәннәр, кырлар, вак куаклар — бар да караңгылыкка чумган. Ерактагы кар каплаган тау башлары гына чак шәйләнә. Икенче көн инде җәйрәннәр бер-бер артлы тезелешеп кояш чыгышы ягына — Өст-йортка таба баралар. Көтү башы тездән кар ерып алдан атлый; ул кайвакыт кар каплаган чокырга төшеп чума да кискен генә сикереп чыга. Көтү аның артыннан чокыр, көртләрне җиңел кичә. Алар кеше яши торган тирәгәрәк җитәргә ашыгалар, юкса җил-буран оясы булган очсыз-кырыйсыз кысыр дагада аларны ач үлем сагалый. Яшь җәйрәннәр Көтү башы салган эздән салмак кына алдыралар, ә кайчакта эзне югалтып, буталышып туктап та калалар.

Менә Көтү башы талчыкты, хәлдән тайды, актык тапкыр көчәнеп атлады да яны белән авып китте. Кузгала алмыйча, ярты көн ятты ул. Әмма аның горурлыгы арганлыгын җиңде, ул яңадан торып басты, җәйрәннәрен ияртеп алга, җылы якка таба кузгалып китте. Өченче көн инде аның авызына үлән эләккәне юк, ул үзен көчкә-көчкә генә барырга мәҗбүр итә, юкса, мондый өшеткеч салкында тукталыш ясау — үлем дигән сүз. Ул көчкә генә селкенсә дә, көтүе алдында үзенең хәлсезлеген күрсәтергә тиеш түгел, мәгърур башын туры тотып, һаман алга омтыла.

Бүгенге таңны җиткерү тагын да авыр булды, Көтү башының бөтенләй көче бетте, һәр адымын атлавы — газап иде, ә алда сукмак очсыз-кырыйсыз булып күренде. Ярый әле, бәхеткә каршы, аларның юлында ерткыч хайваннар очрамады, хәлсезләнгән сылу җәйрәннәр ничек котыла алырлар иде. Быел кар чамадан тыш күп яуды, җир өстенә калын булып ятты, калын катлам астыннан үлән табуы бик авыр иде. Хәер, кояш көйдергән ком чүлендә үләне дә кая үссен инде аның?.. Юк үләнне калын кар астыннан ничек табасың!

Офык читендә таң шәфәгы тибеп чыкканда Көтү башы җегәре китеп сөрлекте, кар өеменә чүкте, дерелдәгән ираннәре салкын карны капшады. Ләкин теш арасында шыкырдап торган кар аңа көч бирмәде, киресенчә, хәлен генә алды. Җәйрәннең озынча дымлы матур күзләре дусларына, балаларына, карлы бушлыкка сагышлы төбәлделәр, гүя ул көтүдәшләренә: «Мине калдырып китегез, барыгыз», — дия иде. Ул хәтта кинәт яннан исә башлаган җилгә каршы да борылмады, күзен йомган килеш селкенмичә ята бирде. Менә ул үзен йомшак үлән өстеннән барган кебек күрде, уйнаклап иптәшләрен узып китте. Нигәдер, җил исә дә исә, имеш…

Җәйрән үз тирәсенә көтүнең туплануын сизмәде, хәтта җилнең котырып көчәюен дә, үзәккә үтә торган салкынны да тоймады. Йокы тылсымыннан айный алмыйча, йөрәге рәхәт бер ләззәт эчендә оеды.

Менә ул куакларны сикереп чыга-чыга такыр буйлап чаба, имеш. Һава саф, йомшак җил исә, тирә-якка тәмле үлән исе таралган, күктә каурый сыман ак болытлар йөзә.

Нәни җәйрәннәр, хуш исле үләнгә тиенүләренә куанышып, утлап йөриләр, уйнаклап, бер-берсен куа китәләр. Ул үзе дә тәмле сусыл үләнне күши-күши, тирә-юньне хуҗаларча күзәтә, һәр тараф тын. Куркыныч-фәлән сизелми… Тукта, чү… Аның

очлы колаклары үрә торды. Хәвеф барлыгын сизде ул, тирә-якка күз салды һәм ерактагы куак арасында посып яткан бүрене күрде. Атылып сикереп торды да чабып китте, артыннан бер адымга да калышмыйча башка җәйрәннәр чаба иде. Йа, каты чаптылар соң алар… Яшел үләннәр, борынны кытыклый торган хуш исле дала артта торып калды. Бер атналык юлны берничә сәгатьтә җилдәй очып үттеләр…

Көтү башы яңадан күзен ачты. Ул әле һаман да кар өстендә ята иде. Баш астында бик каты нәрсәдер бар. Җылы тәне астында эри башлаган һәм яңадан каткан кар икән, ләбаса. Барлык җәйрәннәр аның каршына җыелганнар. Күз ачкысыз давыл купкан. Даланы иңләп ач бүредәй җил улый. Кар өермәсен бөтереп алып күккә күтәрә. Җир белән күк бергә тоташкан.

Көтү башы сизелер-сизелмәс дерелдәп торган нечкә ал аякларына күтәрелде, аннары торып басты. Җәйрәннәр кагынып алдылар, утлы күз карашы белән тирә-якны сөзделәр. Ленин «үз карашын куркытырлык әллә ни барлыгы тоелмады, тик җил генә элеккеч» ыжгыра иде.

Көтү башы яңадан иптәшләре алдына чыгып басты. Горур гәүдәсен мәһабәт турайтты һәм барысы бергә сукмак буйлап, яңадан алга таба кузгалып киттеләр. Алар кайчакта тирән карга төшеп китәләр, аңа карап барыбер туктамыйлар, һаман алга таба баралар. Алар тау итәгендәге үзәнлеккә җитәргә омтылалар, әмма анда нәрсә көтәдер, әлегә билгесез…

Көтү башы кешеләр янына җитәргә ашкына, аларга бигүк ышанып бетмәсә дә, ярдәм итәрләр, дип өметләнә. Печән табарга кирәк. Рәхимсез далада һәлак булганчы, кешеләр кулыннан үлүең — хәерлерәк. Начарлык белән яхшылык һәрвакыт бергә янәшә яши, шуңа күрә ышанырга да, ышанмаска да мөмкин… Тик туктамаска гына кирәк, алга барырга, фәкать алга барырга кирәк… Югыйсә, арттан үкчәгә басып үлем килә… Ә бәлки, үлем аларны алда сагалап торадыр. Белмәссең!..

Көтү башы тагын ятты. Төн шулкадәр караңгы, ник бер йолдыз әсәре күренсен. Ә җил котырганнан котыра, әйтерсең, күтәреп китәргә тели иде. Җәйраннар җилгә аркан борылдылар да, Көтү башын уртага алып, тагын бер күчкә җыелдылар. Көтү башы — ул көтүнең бәхет кояшы, көтүнең җаны, көче; әгәр ул аяктан егылса, көтүнең горурлыгы да, көче дә китәчәк. Шуны белгәнгә күрә Көтү башы арганлыкны җиңәргә, ничек тә торып китәргә талпынды.

…Алга барырга, тик алга таба атларга кирәк… Ләкин алда нәрсә көтәдер бит әле… Көтү башы үз гомерендә начарын да, яхшысын да күп күрде. Бервакытны ул кичке салкын белән тау итәгенә утлауга китте. Уйламаганда-көтмәгәндә кайдадыр артта моңарчы ишетмәгән-белмәгән шытырдау-пытырдау ишетелде. Борынга ят ис килеп бәрелде. Үлән өстендә ятучы Көтү башы муенын сузып, бер ноктага текәлгән күзләрен ала алмыйча, катып калды. Бүтән җәйрәннәр дә баскан җирләрендә аптырап калдылар. Җил исүенә дә, чишмә чылтыравына да, ерткычлар улавына да охшамаган бу гөрелдәү көчәйгәннән-көчәя барды.

Чак кына шытырдауга да сизгер Көтү башы сикереп торды да яшен кебек таш кыя артына атылды. Калганнар да аның эзеннән ташландылар, күз ачып йомган арада юк та булдылар, үткен тояклары астында сытылган үләннәр генә ятып калды. Ят тавыш бөтенләй якынайды, өннәре алынган җәйрәннәр тауга ташландылар, ук шикелле атылып, борыла-сырыла качып барган еландай тезелешеп, өскә, кар каплаган сыртка менеп тә җиттеләр. Алга-артка карарга, вакыт юк, җан кадерле, җан газиз… Алда пеләш баштай ялтырап яткан тип-тигез җирләр, ник берәр куак-мазар күренсен… Берәр кая борылырга да исләренә килмичә, турыдан элдерә бирделәр.

Ләкин тавыш алардан калмады, киресенчә, якынайды гына. Мәңге тын яткан, катып калган бу табигатьнең тынычлыгын алды. Эзгә басып килгән бу афәттән качып кына котылу мөмкин иде. Җәйрәннәр сузылып чабалар. Ә теге билгесез зат һаман калышмады, кинәт ату тавышы яңгырады һәм колак очын нәрсәдер яндырып алды.

Йөрәк атылып чыгардай булып типте, әмма җәйрән тукталмады, бер ун метрлап араны җиргә тияр-тимәс очып диярлек узды. Ара ерагайды, дип уйлаган иде инде, тик дөньяны тетрәткән теге тавыш тагын куып җитте. Арт аягын көзән җыергандай булып тоелды, ләкин үлем куркынычы һәм тәненең кайнарлыгы аңа көч өстәде һәм алга ыргылырга мәҗбүр итте.

Котырып чабудан йөрәк бугазга килеп терәлде, ул бик арыды, хәле бетте. Ах, бер генә тамчы су булса, су! Менә алда аксылланып су күренде. Шик юк, бу — күлнең ялтыравы! Гүелдәүче зат арттан җиткәнче, ичмасам, алданрак күлгә барып җитеп булса иде. Әгәр су эчәргә өлгерсә, хәл керер иде аңа, аннары гүелдәүче затка тоттырмас иде! Җил очырган мамыктай җилеп чапты ул. Суга килеп тә җитте түгелме соң! Ах, суы кайда соң моның? Су кайда! Су!!! Күл төбендә кояш чаткысы гына уйный лабаса!

Йа Ходай, мәдәт бир! Горур күкрәктән йөрәк атылып чыга инде! Сикерергә кирәк! Йөрәк туктый бугай! Су! Су! Гүелдәүче зат тагын килеп җитте. Алда сары нәрсә күренде. Әллә сумы? Булмас! Арган күзгә ялгыш күренәдер. Суга барып җитәм, дип тагын бер талпынды һәм ирене суга тиде. Су куе иде, тозлы иде. Җәйрән егылды! Егылса соң! Тозлы булса да су эчеп егылуы — үзе бәхет иде! Йөрәге дә тибүдән туктады бугай! Гөрелте колак төбенә килеп җитте. Әллә әҗәл тавышы микән бу? Чыннан да, әҗәлдер ул!.. Җәйрән яны белән яткан килеш, алсу телен сузып, ашыгып-ашыгып, тоз ялый башлады. Йөрәге көчкә-көчкә генә тибәргә тотынды, әкренләп хәл керде.

Гөрелте инде җилкәсенә үк килеп терәлде. Ул нәфис башын күтәрә төште, тагын кызу-кызу тоз ялады.

Йөрәк тибеше ешайды, көче кире кайтты. Гәүдәсе, нәкъ элеккечә, төзәйде, ныгыды. Күзләрен зур ачып, аягына торып басты. Үкерүдән курыкмыйча, горур һәм туры итеп басты ул, ә үзе һаман тоз ялады. Гөрелте баш өстендә үк яңгырады һәм ул, яшен утыдай куаклыкка атылып, бер минуттан юкка да чыкты. Шул минутта тавыш та басылды. Әйләнә-тирә тып-тын булып калды…

Туры мөгезле җәйрәннәр салкын һәм ачлык белән озак көрәштеләр. Менә бүген дә көчкә генә таң аттырдылар. Ташлар, тарлавыклар аша сикереп уздылар, иңкүлекләрдә көрткә кереп чумдылар, тагын ыргылып чыктылар. Кояш баер алдыннан гына алар тау итәгенә килеп җиттеләр. Әмма монда куандырырлык нәрсә юк иде: үлән тапмадылар. Еракта, җайдак чабып җитәрлек арада, куе куаклык күренде, һәм Көтү башы, барысын да үзе артыннан иярергә өндәгәндәй, башын төз тотып шунда чапты. Монда тау ышыклый иде, җелеккә үтәрлек түгел, җылы иде.

Җәйрәннәр көне буе утлап йөрделәр һәм йөрәккә төшкән ачлыкны бастылар. Ә алда өй түбәләре күренеп тора иде.

Җәйрәннәр үз аяклары белән авылга килеп керер, дип кем уйлаган! Мондый хәлнең булганы да, ишетелгәне дә юк иде әле.

Ауданбай совхозның дөге амбарында мөдир иде. Һәр көнне ул йокларга кайтыр алдыннан биек капканы ныклап ябып китә. Дөгене шәһәр складына җибәрә башлаганнан бирле ул бераз бушап калды. Теләгәндә көндезләрен генә килгәли, ә кайчакта бөтенләй дә күренми. Ә төнлә өеннән дә чыкмый. Быелгы кыш чамадан тыш суык булды. Ябылмый торган амбарлардагы тәмуг суыгына түзәрлек түгел иде. Әле үз өендә дә, көне-төне ягып та җылы тормый. Стеналары иске читән кебек араданып беткән диярсең, җил уйнап тора, кичкә хәтле бер җылысы калмый. Гадәттә, өебез бик җылы, быел нык карадык, дип мактанучылар да быел, никтер, авызларын да ачмыйлар. Мөгаен генә аларның өйләре дә ягылмаган колхоз клубы шикелле сап-салкындыр.

Ф.Муллахмәт рәсеме

Ауданбай әнә шул сәбәпле соңгы вакытларда ваемсызга чыкты. Хәтта кичә амбар ишеген ябарга да онытып кайтып киткән.

Иртән нык кына итеп ашап-эчкәннән соң, җылы итеп киенгән килеш ул урамга чыкты. Көн аяз. Элекке көннәрне мул булып яуган кар тыгызланган, җемелдәп күзләрне чагылдыра. Күзләрен уа-уа ул амбар ягына таба борылды. Капка ачык иде.

Башта ул бу хәлдән курка калды, ләкин кичә үзе ябарга онытканы исенә төшеп, карны шыгырдата-шыгырдата амбарга таба йөгерде. Кар өстендә ят кеше эзләре юк иде. Аннан әйләнде, моннан әйләнде, караңгы почмакларны карап чыкты, әмма тояк эзләреннән башка нәрсә күрмәде. «Бу нинди кәҗәләр булыр икән? Каян килгәннәр болар? Берәрсенең кайтмый калган кәҗәләре микәнни?»

Ауданбай амбарга керде. Салкыннан дер-дер калтыранып, эчкә узды. Үзәккә үтәрлек иртәнге суык яңакларын көйдереп алды. Шифер белән, ишек белән бүленгән кечерәк кенә бүлемнән кәҗә башлары күренеп калды. Алар утызлап булыр. Йоннары юка, аксыл-саргылт. Ауданбай якынайгач, «кәҗәләр»нең күзләре әсәренде, мөгезләре тырпайды. Бер ун адымлап калгач, Ауданбай аларның җәйрән икәнен күреп алды.

«Һе, кара әле, кәҗә түгел, җәйрәннәр лабаса болар! Әгәр дә кар тагын шулай күп яуса, җәйрәннәр генә түгел, бүреләр дә авылга килерләр. Һай, мескеннәр, кешеләрдән ярдәм өмет итеп килүләрен күр әле син. Акыллары бар, диярсең! Бичаралар! Кирәк бит, кешеләрдән ярдәм көтәләр! Ярый әле килгәннәр, югыйсә ерткыч җанварларга, козгыннарга азык булырлар иде».

Ул тиз генә кирегә борылды. Аларны күргәнен беркемгә дә әйтмәскә булды. Суык, сиздерми генә килгән еландай, тешли. Калын киенүгә дә карамастан, ул дер-дер калтырый, теше-тешкә тими. Кат-кат чолгау ураган аягы да, ялан тәпи кар өстеннән кайткандай, өздереп сызлый. Өенә кайтып кергәч, ул хатынына мичне кызурак итеп якырды, кайнар мичкә аркасын терәп, аякларын сузып утырды. Бераздан гына тәненә җылы үтә башлады.

Кышкы кыска көннең кояшы әле күтәрелергә дә өлгермәгән иде, хатыны, өздергеч салкыннан битләре кызарып, ашыгып өйгә килеп керде.

— Атасы, син ишеттеңме әле, амбарга җәйрәннәр кергән, ди анда?!

— Кем әйтте? Кем күргән? Синнән сорыйм?

Хатыны туңудан рәтләп сүз әйтерлек хәлдә түгел иде, утка якынрак килде.

— Әй, синнән сорыйм? Ник дәшмисең?

— Б-безирген…

Бераздан җылынгач кына ул әкренләп барысын да сөйләп бирә алды:

— Әле генә кулына мылтык тотып шунда таба йөгерә иде, хәзер барып җиткәндер инде.

— Аһ! Җәйрәннәрне харап итә икән! Ач күз комсызлыгын җиңә алмады, туя

да белмәде. Кабер якасына басмыйча, мылтыгын кулыннан төшермәс инде! Йә, Аллам, нәрсә эшләргә соң? — дип ачынды Ауданбай.

— И-и көлке! Көтүеңдәге үз кәҗәң түгел бит, нигә шулхәтле көенәсең? Дала җәйрәннәрен кызганган буласың. Берәр җәйрәнне үтерсә, әйбәтләп аш пешерер идек әле.

Ауданбай урыныннан сикереп торды.

— Җиттеме сиңа, юкмы! Гомереңә шулпа заты күрмәгән, диярсең! Итчедә — ит кайгысы, ә кәҗәдә — җан кайгысы. Безирген аларның барысын да харап итмәгәе, дип борчылам мин, ә син тәмле аш, дисең. Шул шулпаң телеңне куырып алсын иде! Ах! Кырып бетерә инде ул җәйрәннәрне, — дип, Ауданбай ишеккә ташланды.

— Син мышкылдап барып җиткәнче, Безирген җәйрән итеннән шулпа пешереп өлгертер. Аның юлына аркылы төшсәң, үзеңне үтерергә дә күп сорамас ул…

Ауданбай ишектән чыкканда әйтте:

— Кагылып кына карасын, күрербез! Тәкъдирдә нәрсә язгандыр бит әле… Мескен хайваннар рәхим-шәфкать эзләп кешеләр янына килгән, ә ул аларга кул күтәрә!

— Безирген төкерә ул синең борчылуыңа, юкка гына барасың!

Ауданбай сырган бишмәтен эләктерде дә урамга чыкты.

Амбарга җәйрәннәр кергән, ди! Безирген бу хәбәрне ишеткәч, шатлыгыннан кулларын чәбәкләп, урыныннан сикереп торды. Йоны кырыла башлаган колакчын бүреген маңгаенарак төшереп киде дә, мылтыгын кора-кора өеннән йөгереп чыкты. «Йа Хода! Рәхмәт шәфкатеңә, шулхәтле хайванны үз аягы белән өемә китергәнсең».

Җил генә барырга комачаулый, туп-туры Безиргеннең колагына сызгыра. Көн чалт аяз. Аяк астындагы кар, өй түбәләре күзне камаштырып җем-җем килә.

Берәрсе очрап, юлыма аркылы төшмәгәе дип, ул кеше йөрми торган аулак тыкрыкларны сайлады. Олы юл аша йөгереп чыкканда каршысына килгән машинага чак килеп бәрелмәде. Җәйрәннәр турында гына уйлап барганга, кан баскан күзләренә ак-кара күренмәде. Шофёр, машинасын көчкә туктатып, ачу белән кычкырды:

— Хөрмәтлем, яшәүдән туйдыгызмы әллә? Сөякләрегезне изгәнне көтәсезме?

— Үзең дөмек! Алап авыз! — дип мыгырдады Безирген кәкре борыны астыннан һәм машина алдыннан юлны аркылы кисеп, тар сукмак буйлап амбарга таба йөгерде.

Амбарга җитәргә нибарысы ике йөз метрлар калгач, кемдер аның артыннан куркыныч тавыш белән кычкырды. Йөрәгенең дөп-дөп итеп типкәненә хәтле ишетелә иде, анда да ул туктамады, артына да борылмады.

— Әй, Безирген, карак ләгънәт, тукта әле! — дип кычкырды Ауданбай.

Безирген кинәт артына борылды, аңа таба Ауданбай йөгерә иде. Ашыгудан бишмәтенең бер җиңен кияргә дә өлгермәгән.

— Аһ, әле синмени! Якын килеп кенә кара, башыңны бетерәм! — дип зәһәреннән тешләрен шыкырдатты Безирген.

— Тукта, дим! Хайваннар кешеләрдән рәхим-шәфкать өмет итеп килгәннәр! Ашыкма! Көт әле, Безирген! — диде Ауданбай.

— Ничек «ашыкма», әллә дала хайваннарын кызганасыңмы?

Безирген йөгереп килеп җиткән Ауданбайның колак төбенә селтәнеп торып бәреп җибәрде. Ауданбай каты ыңгырашып йомшак карга барып төште. Безирген аңа игътибар итмичә, амбарга таба йөгерде.

Кеше адымнарын ишетеп өреккән җәйрәннәр бер почмакка тыгылганнар. Алар әсәренгән күзләрен ишеккә төбәгәннәр. Ишекнең ике ягындагы тишекләрдән яктылык төшкән. Артта — нык стена, алда — җан кыючы мылтык. Нинди генә гайрәтле булмасыннар, түшәм аша сикереп чыга алмыйлар бит инде алар. Көтү башы хәлләре

аянычлы икәнен аңлады, алга чыгып басты, батыр кулындагы киерелгән уктай сузылды. Бу анның үз нәселен саклап калу өчен дошман белән үлем көрәшенә ташлануы иде.

Җәйрәннең гүзәл күзләре ут булып яна, үткен тояклары ташка бәреп очкын чәчә. Ату тавышы яңгыраганчы, ул ничек сикереп чыгып качарга дип абайлап тора. Горуранә башын югары чөеп, амбарның таш идәненә тояклары белән каты басып, җәйрән алга атлады. Аның матур зур күзләре пычак сырты кебек тар гына ерткыч кеше күзләре белән очрашкач, бөтен тәне буйлап кайнар кан йөгерде. Тагын алга атлады ул... Тагын бер адым атлады... Тагын... Әгәр тагын атламаса... нәселне саклап калырга күпме тырышулары, нихәтле ышаныч һәм омтылышлары барысы күккә очачак; әгәр бу кеше мылтыгын атып өлгерсә, алар чабылган үлән кебек кырылачак...

Ул чакта... ул чакта искиткеч матур дөнья белән, җылы карашлы зәңгәр күк йөзе, иркен киң дала, иксез-чиксез җир-ана, колакларда сызгыручы җилләр, сыгылып төшкән үләннәр, күктәге торналар чылбыры, ашкынулы шарлавыклар белән хушлашырга туры киләчәк. Алар бүтән беркайчан да гөрләп торган тормышның ягымлы авазларын ишетмәсләр. Иркенләп үсә һәм шатлана алмаслар. Бер мизгел... Шулчак җәйрәннең борын тишегенә яңгыр исе, яшел үлән, тәмле чәчәк исләре бөркелеп керде. Җилнең сызгыруыннан кыштырдаучы яшел кырлар күз алдында торды. Дөньяга килеп кенә өлгергән иде әле ул, нәфис үлән өстендәге чык бөртеге ялтыравына, җемелдәгән ташу суына гаҗәпләнгән иде, кояш чыгуга меңләгән яңгыр тамчыларының балкып янарга керешүләренә сокланып, башны исертерлек дала буйлап чабып киткән иде, әнисе янына йөгереп килгән иде — шулар барысы да аның күз алдыннан чагылып уздылар. Ә хәзер? Әгәр бирешсә, ул чагында аның нәселе мәңгегә юкка чыгачак...

Менә имән бармак чакма өстендә ята, бер басу җитә... Менә җәйрәннең күз алдында ут таплары кабынып китә... һәм ул актык көчен җыеп туп-туры Безиргенга атылды, бу көтелмәгән хәлдән Безирген тиргә батты, күз аллары караңгыланды, маңгаена килеп бәрелгән авырлыкка түзә алмыйча, капка белән бергә авып төште. Коралы атылды. Ләкин җәйрән инде якты һәм иркен киңлеккә очкан иде. Вак ядрә ишекне иләк кебек тишкәләп бетергән иде...

Җәйрәннәр бер-бер артлы ватык капка аша сикереп чыктылар да, канга баткан Безирген алдында туктамастан, үлем авызыннан исән-аман чыгуларына шатланып, киң бушлыкка очтылар.

Тупырдаган тояк тавышларына авыл кешеләре өйләреннән атылып чыктылар, тау ягына таба чабучы җәйрәннәрне гаҗәпләнеп карап тордылар. Җәйрәннәр тау ягына таба очтылар, аларны хәзер ачлык та, салкынлык та, явыз эт тә, ерткыч кошлар да — берсе дә туктата алмас иде.

Аларга хәзер Өст-йорттагы җир дә йомшак, үләне дә мул, нәфис булып күренде. Аларны хәзер хәтта үлем дә куркытмый иде, тик ата-бабалары гомер кичергән, үзләре туып-үскән җиргә генә барып җитәргә кирәк иде.

Ә Безиргеннең гәүдәсен туганнары алып кайтып китте; үле гәүдә таш кебек каткан, маңгае уртасыннан агып төшкән кан да куерган иде.

Ауданбайны ашыгыч ярдәм машинасында больницага китерделәр, аңына килеп күзен ачуга, беренче сораган нәрсәсе шул булды:

— Җәйрәннәр ничек? Исән калдылармы?

— Әйе! — диделәр аңа.

Ул яңадан аңын югалтты. Куркудан түгел, ә куанычыннан югалтты ул аңын. Врачлар яңадан аны аңына китерергә ашыктылар.

Каракалпакчадан ***Роза Хафизова*** *тәрҗемәсе* ■

ҮЗБӘК ТЕАТРЫ ҮСЕШЕНӘ ТАТАРЛАР ЙОГЫНТЫСЫ

Шөһрәт Ризаев

(өзек[1])

Төркестан[2] зыялыларының яңа театр сәнгате барлыкка килүенә илһамландырган факторлардан янә бере – татар театрыдыр.

Профессор Рахманов Төркестанда татар театрчылык хәрәкәте татар труппалары Ташкентка килмәстән әүвәлрәк башланганын җитди дәлилләр белән исбатлады. Җөмләдән, 1904 елның 4 апрелендә Ташкентта подполковник С.Г.Еникеев өендә Нәмык Кәмалның «Гыйшык бәласе» спектакле Төркестанда яшәүче татар һәвәскәрләре тарафыннан уйналган. Бу спектакль алдыннан Әбүбәкер Диваев[3] чыгып, Европа театры хакында доклад укыган[4].

Бинаның хуҗасы Сәхиб Гәрәевич Еникеев[5] асылы белән Башкортстан татарларыннан булып, әүвәлге Коканд ханлыгының Санкт-Петербургтагы илчесе Мирза Хәким Парвоначинның татар хатыныннан дөньяга килгән Сәгадәт ханымга өйләнгән иде. Сәгадәт ханым Ташкент гимназиясендә укып, Европача тәрбия алган, рояль уйный белә торган мәгарифпәрвәр хатыннардан булган. Аның хәләл җефете, патша армиясе офицеры С.Г.Еникеев исә 90

Ильяс Ашказарский

еллар ахырларында Асака урынбасары булып, Мәгъдәлихон-Дукчи ишан[6]

---

[1] Мәкалә кыскартылып, татарларның Урта Азиядә театр үсешенә мөнәсәбәтле өлеше генә тәкъдим ителә.

[2] Төркестан – XIX гасыр-XX йөз башында Үзәк Азиядәге тарихи-географик регион атамасы. Көнбатыш Төркестан территориясенә хәзерге Үзбәкстан, Төрекмәнстан, Кыргызстан, Таҗикстан, Казахстан илләре, Себернең төрки халыклар яшәгән көньягы, Әфганстан һәм Иранның төньягы керә (Тәрҗ. иск.).

[3] Диваев Әбүбәкер Әхмәтҗан улы (1855-1933) – галим-этнограф, лингвист-тюрколог һәм фольклорчы (Тәрҗ. иск.).

[4] Рахмонов М. Ўзбек театри тарихи, 264 б. Искәрмә: Шул факт Бузрук Салиховның «Үзбәк театры тарихы өчен материаллар» исемле 1935 елда нәшер ителгән китабының «Татар театрының Үзбәкстанга тәэсире» бабында, Казанда чыккан «Татар театры» китабы нигезендә китерелә. «... 1905 елда апрельнең 4ендә полковник Әбүбәкер Диваевның оештыруы белән Ташкенттагы татарларның югары гаиләләре өчен бер йортта татарча спектакль ясалып, «Гыйшык бәласе» пьесасын уйнаганнар». 57 бит.

[5] Еникеев Сәхибгәрәй Мөхәммәдгәрәй улы (1856-1929) – генерал-майор (Тәрҗ. иск.).

[6] Мадалихон-Дукчи ишан – 1890 елда төбәк халкын патша хакимиятенә каршы милли-азатлык хәрәкәтен күтәргән суфи. Бу вакыйга тарихта Андижан (Әндиҗан) восстаниесе дип мәгълүм (Тәрҗ. иск.).

кузгалуга хәерхаһлыкта гаепләнгән, аннары отставкага чыккан[7]. Әнә шул зыялы йортында тәртипле татар спектакльләре, концерт вә сәнаигы нәфисә кичәләре оештырылып торылган.

1909 елда Ташкентта мәхәллә татар һәвәскәрләре «Мосыйбәте Фәхреддин»[8] һәм «Кызлар ничек көләләр»[9] исемле спектакльләр күрсәткәннәр. «Төркестан вилаяте» газетасы язуынча, 1910 елдан башлап, Ташкентта даими татар театр җәмәгасе эшли башлаган. Мәзкүр труппада азәр, татар, рус драматургиясенең пьесалары сәхнәләштереп барылган.

Татар театр төркемнәре Төркестанга 1911 елда килә башлаган. «1911 елда Ильяс бәк җитәкчелегендәге профессионал татар труппасының Ташкент, Сәмәрканд, Коканд, Бохарада булуы да өлкәдә җирле театрчылык үсешенә нык тәэсир күрсәтте». Ильяс бәк Ашказарский яки Ильяс бәк Кудашев-Ашказарский[10] дуслары Сәхибҗамал Гыйззәтуллина-Волжская һәм Габдулла Кариев — 1906 елда Казанда беренче татар профессионал театрын тәшкил кылган шәхесләр. Алар, гастрольләрдә күп йөргәнлектән, үзләрен «Сәйяр» труппасы дип атаганнар. Репертуарында рус, азәрбайҗан тәрҗемә әсәрләренең барысы белән бергә, «татар Островские» дигән исем алган Галиәсгар Камалның «Бәхетсез егет», «Уйнаш», «Безнең шәһәр серләре», «Банкрот», «Дәҗҗал», Исхак Богдановның «Ярлылык гаеп түгел» исемле А.Островский әсәре нигезендәге «Хуҗа вә приказчик» комедиясе кебек пьесалар булган[11]. «Сәйяр» труппасы әнә шул спектакльләрне 1911 елда Ташкент, Бохара вә Фиргәнә үзәнлеге шәһәрләренә күрсәтергә килде. Арадан, бер ел үткәч, С.Гыйззәтуллина-Волжская Уфада «Нур» исемле театр төркеме төзеп, яңадан Үзәк Азиягә килде. Бохара, Сәмәрканд, Ташкент, Мәрв, Чаржуй[12] шәһәрләрендә спектакльләр күрсәтте.

Ильяс Кудашев-Ашказарский 1913 елны Ташкентта яңа бер даими татар труппасы оештыруга ярдәм итте. 1914 елдан бу труппа Зәки Баязитский вә Мостафа Мансуровлар режиссёрлыгында эшләгән.

«Сәйяр» труппасы 1913 елда Төркестанга икенче мәртәбә килде. Бу сәфәрдә Ташкент, Нәманган, Каган вә Бохарада спектакльләр куйганы мәгълүм. Гомумән, татарларның һәм җирле, һәм гастрольгә килүче театр труппалары Төркестанда бу сәнгать төренең пәйда булышы вә үсешендә мөһим роль уйнады. Мәгънәви ярдәм генә түгел, шул ук вакытта турыдантуры гамәли тәэсир күрсәтте.

Үзбәкчәдән ***Ленар Гобәйдуллин***
тәрҗемәсе ■

---

[7] Бу хакта карагыз: Шарқ юлдузи // 1993 — №10-12. — Б.17-19.
[8] «Мосыйбәте [бәхетсез] Фәхреддин» — азәрбайҗан драматургы Н.Вәзировның 6 пәрдәлек трагедиясеннән Г.Нугайбәк тәрҗемәсе (Тәрҗ. иск.).
[9] «Кызлар шулай кызык итәләр» исемле Г.Атавиның бер пәрдәлек пьесасы (Тәрҗ. иск.).
[10] Рахмонов М. «Ўзбек театри тарихи» китабының 266 битендә Кудашев вә Ашказарскийны башка-башка шәхесләр, дип китерәдер. Бу дөрес түгел. Асылда, бу бер шәхеснең исеме булып, 1913 елда Ташкентта оешкан даими татар труппасын нигезләүчеләрдән бере дә шул Ильяс бәк Кудашев-Ашказарский иде. Ба хакта карагыз: Губайдуллин Х. Татарский театр дооктябрьского периода (1887-1917). АКД. — Казань, 1964. — С.7.
[11] Карагыз: Губайдуллин Х. Татарский театр дооктябрьского периода (1887-1917).
[12] Чаржуй, Чарджоу, ягъни хәзерге Төрекмәнабад каласы (Тәрҗ. иск.).

ГАЛИҖӘНАП ШИГЫРЬ СҮЗ АЛА...

Ренат Харис

***

Дәүләтләрдә халыклары холкы,
ә халыкка кешеләрдән күчә...

Чабуыма ут төрттеләр ничә,
ялкынында җылынмакчы булып...
Гөлләремне ташладылар йолкып...
Учагыма су сиптеләр азмы —
чишмәләрем хәтта кибә язды —
түздем —
Кешеләрдә халыклары холкы.

Халыкларда кешеләре холкы,
ә кешегә тере сүздән күчә...

Сүзебезгә, телебезгә ничә
кизәнделәр үтермәкче булып.
Кала алдык һәлакәттән йолып...
Түздек —
халыкларда кешеләре холкы.

Алааттин СОНАТ

төрек шагыйре

БЕР ЖЫРЛАМЫЙ ЯРАМ УҢМАС

Яраландым. Һичкем белмәс ярамны.
Бу ярамны синең жаның аңлармы...
Син ул, син ул тирән яра дәрманы.
Бер жырламый һич тә уңмас бу ярам...

Хәлне белмәс яралаган ул ярым,
бу сөюгә жанның фида булганын,
йөрәген дә һич борчымас ул аның.
Бер жырламый һич тә уңмас бу ярам...

Карашлары тирән үтте күңелгә,
күзләреннән мәхәббәте түгелә,
ул бар иде минем дөньям күгендә...
Бер жырламый һич тә уңмас бу ярам...

Бирдем аңа «Кара кыз» дип бер исем,
сәбәбе — ул, сөю дигән шул хиснең.
Бу сөюем яралардан мең өстен.
Бер жырлыймын — уңсын әле бу ярам..

Мәхәббәт ул бәлки бер зур ярадыр,
ул яралар жанда мәңге каладыр,
мәхәббәтсез — язмышлар да карадыр...
Бер жырлыймын — уңсын әле бу ярам...

Аллаһ шаһит: юктыр яман уйларым,
ахырларын хәерлегә юрадым,
килешмәсәң — үзең сайла юлларын.
Бер жырламый һич тә уңмас бу ярам...

Үз сүзеңне үз йөрәгең аңласын,
йөрәгең дә бер гамәлсез калмасын.
Яраларым кабул итсен дәвасын,
Бер жырлыймын — уңсын әле бу ярам...

Карлар ятмас тау булмаган тауларда,
курыккан жан чыкмас киек ауларга,
бу сөюем охшаш якты таңнарга...
Бер жырламый һич тә уңмас бу ярам...

*Төрекчәдән **Гөлнур Корбанова** тәрҗемәсе*

Хәмит Латыйф

ТӨРКИЛӘРНЕҢ КҮҢЕЛ ДАЛАСЫНДА

...Тамга кебек, теш эзләре калган
Ак бүренең күкрәк ярасында.
Күкрәгеннән тама яшәү сөте
Адәм булып иңгән баласына.

Якты аваз, чыңлы сорнай моңы
Ишетелер бөек далабызда.
Төркиләрнең изге тамгасына
Тылсымын сонар Рух бабабыз да.

Очкынланып соңгы өмет янар
Күккә баккан бүре карашында.
Тәңренең күзләреннән тамар
Әрнү уты — чикләр арасында.

Хәтердәге уйлар — үткәннәрнең
Катлам-катлам тирән ярасында.
Мәкер янар, соңгы ялган янар
Җирләр белән күкләр арасында.

«Ватан!» — диеп изге теләк калкыр
Кавемнәрнең рух канатында.
Бердәмлекне зурлап дуслык кайтыр,
Бәхет кайтыр төрки даласына!

Гомер үтәр, ачы җилләр китәр
Алтай, Кырым, Казан арасыннан.
Газиз моңнар чыгар кубарылып
Төркиләрнең күңел даласыннан,
Төркиләрнең бөек даласыннан! ■

Х.Латыйф рәсемнәре

ДУСЛЫК КҮПЕРЕН НЫГЫТКАНДА

Рәшит Минһаҗ

Ике ай элек, Татарстан районнарында сабан туе гөрләгән көннәрдә (6-7 июнь), Мәскәүдә (Россия дәүләт гуманитар университетында) «Европа белән Азия арасында медиакүпер» дигән беренче Россия-Төркия журналистлары форумы булып узды. Әлеге эшлекле чарада безнең республикадан да вәкилләр, аерым алганда, «Ялкын» белән «Безнең мирас» журналларының һәм «Казанские ведомости» газетасының баш мөхәррирләре Йолдыз Миңнуллина, Ләбиб Лерон, Венера Якупова, «Ватаным Татарстан» газетасы журналисты Рәшит Минһаҗ, КФУ доценты Дмитрий Туманов, Төркия телевидениесенең (ТРТ) Татарстандагы хәбәрчесе Рәсим Хөснетдинов катнашты.

Башка дәүләтләрне төрле яклап каралтырга тырышу, ялган-гайбәт тарату — һәр илнең сәяси эшчәнлегенә хас күренеш. Бу Россия белән Төркиянең

Истанбул университеты профессоры, язучы, журналист Мәхмәт Алтан

үзара мөнәсәбәтләрендә дә сизелә иде. Россия мәгълүмат чараларының Төркиягә тискәре ярлык тагарга тырышуына бер мисал — Истанбулдагы «Айя-Суфия» чиркәвен кабат мәчеткә әйләндерергә җыеналар, дигән ялган хәбәр тарату. Төркиядә исә Пётр Беренчене тиле Пётр дип атау киң таралган.

«Бу хәлгә чик куярга кирәк, — диде Истанбул университеты профессоры, язучы, журналист **Мәхмәт АЛТАН**. — *Пётр Беренче — Россияне Европага якынайткан зур дәүләт эшлеклесе. Без тарих дәреслекләреннән Пётр Беренчегә кагылган мондый тискәре ярлыкларны алып ташладык. Бүген Россия — иң ышанычлы илләрнең берсе!»*

«Айя-Суфия» чиркәвенә килсәк, ул

«Ялкын» журналының баш мөхәррире Йолдыз Миңнуллина

бүгенге көндә музейга әйләндерелгән. Соңгы елларда Россия туристлары төрек мәмләкәтен аеруча үз итүе — ике ил арасындагы дустанә мөнәсәбәтнең ныгуы турында турында сөйли.

Дөньяда халыкара хәлләр катлауланып торган бер заманда «Медиасоюз» гаммәви мәгълүмат чаралары хезмәткәрләренең гомумроссия иҗтимагый оешмасы белән Төркиядәге язучылар һәм журналистлар фондының ике ил арасында җылы мөгамәлә булдыру һәм үзара уртак тел табу максатында медиакүпер оештыруы бик вакытлы.

Сөйләшүләр барышында яңгыраган кайбер фикерләргә тукталып үтик.

Николай СВАНИДЗЕ (Россия дәүләт гуманитар университетының журналистика кафедрасы мөдире): *«Соңгы вакытта толерантлык сүзе тискәре мәгънәдә кулланыла башлады. Башкалар, чит кешеләр карашына хәерхаһлы мөнәсәбәтне аңлата бу. Журналист һөнәренең киң таралыш алуы сыйфатка тәэсир итүче төп сәбәп түгел. Көндәшлек кимеде. Телевидение каналлары, тулысынча диярлек, дәүләткә бәйле. Башка оештыручылар да булырга тиеш!»*

Алексей СИМОНОВСКИЙ (АГТ коммуникацияләр агентлыгы): *«Мәгълүмат чараларын конфликтлар күбрәк кызыксындыра, тискәре әйберләр белән кызыксыну, нишләптер, алгы планга чыкты».*

Бүләнт КӘНӘШ («Todays Zaman» газетасы журналисты): *«Барыбер газеталар бетмәс, дип уйлыйм. Чөнки газеталарда аналитика күбрәк. Бәлки алар өлешчә электрон вариантка күчәр. Ышаныч, объективлык, бер якны гына якламау мәсьәләсе дә бар. «Безнең «Заман» газетасы дәүләткә, хакимиятләргә бәйле түгел. Үз фикерен әйтә, субъективлыкта гаепләр, дип курыкмый. Һәр журналистның үз карашы булырга мөмкин».*

Сергей ЯРОШЕЦКИЙ («Северо-Запад Медиа» агентлыгы баш мөхәррире): *«Чынлап та, фикере хөкүмәтнекенә туры килмәсә дә, ул барыбер журналист булып кала. Иң мөһиме: каләм иясе пропагандистка әйләнмәскә тиеш!»*

Дмитрий ТУМАНОВ (Казан федераль университет доценты): *«Элек кешеләр эзләгәнен юллар арасыннан таба алырмын, дип өметләнә иде. Бүген матбугат көткән өметне акламый. Хәзерге глобальләштерү нәтиҗәсендә интернет зур базарга әйләнде. Һәркем үзе язарга, кире кагарга, дөрес дип уйлаганын сайлап алырга мөмкин. Хәзер яңа журналистика пәйда булырга, мәдәниятара аңлашу чагылыш табарга тиеш».*

Мәхмәт АЛТАН: *«Әйе, интернет барлыкка килү нәтиҗәсендә яңа хәбәр алмашу, аралашу чаралары пәйда булды. Бер-беребезне тыңлыйбыз да кебек, әмма ишетмибез. Глобальләштерүгә җавап буларак, милләтчелек туа. Франциядә, Германиядә, Украинада хакимияткә милли партияләр килә...»*

Форумда безнекеләрдән Россия Дәүләт думасы депутаты, Төркия парламенты белән аралашу төркеме җитәкчесе, Татар федераль милли-мәдәни автономиясе Советы рәисе Илдар Ирек улы Гыйльметдинов белән «Ялкын» журналының баш мөхәррире Йолдыз Миңнуллина да нотык тотты. Аларның этрафлы чыгышларыннан форумда катнашучыларның күңелләре биһуш булды.

«Бер-беребезне дөрес чагылдырыйк!» — форум әнә шундый шигарь астында узды. Ике ил дә әлеге шигарьгә һәрвакыт тугры булыр, дигән өметтә калабыз. ■

Рәсим Хөснетдинов фотолары

ЯҢА ТӨРЕК ДӘҮЛӘТЕ УҢЧЫЛАРЫ

Йосыф Акчура

Бакчасарай

ИСМӘГЫЙЛЬ БӘЙ ГАСПРАЛЫ... «ТӘРҖЕМАН»

Кырымлы Исмәгыйль бәйнең беренче фикри һәм язма чыгышларында ук инде караш офыгы Кырым белән генә чикләнмәгәнлеге шунда ук күзгә ташлана. Кырымның административ үзәге Акмәчет (Семфирополь) шәһәрендә чыккан «Таври» газетасында рус телендә басылган мәкаләләр циклы «Русское мусульманство» дип аталган. 1881 елда язылган мәкаләләренең темасы колачлы — Кырым мөселманнарын гына түгел, бөтен Русиядә яшәгән мөселманнарны тәшкил итә. Шул ук елда Акмәчеттәге ташбасмада төрекчә дөнья

* Дәвамы. 2014 елның 1 нче санынннан басылып килә.
[1] Төрек-татар — төрки-татар

күргән «Түнгеч» («Беренче язма») газетасының да теле, сюжеты бер — Русиядә яшәүче мөселманнар гына түгел, аз-маз яшерелгән рәвештә, бөтен дөньядагы төрки телле мөселманнар, ягъни Бөтен төрек (төрки) дөньясы күз алдында тотыла. Мәкаләләренең бисмилласыннан төрек-татарларның[1] тел бердәмлеге мәсьәләсен мәйданга куя. Алар һәркемгә аңлашылырлык уртак төрки телдә язылган, ягъни телдә һәм әдәбият өлкәсендә фикерен «Бөтен төрек» (гомум төрки) сызыгыннан башлап җибәрә.

Исмәгыйль бәйнең тәрҗемәи хәле, аеруча аның төркичелек фикере, төркичелек хәрәкәте белән бәйләнешле сәхифәләре, һәммәсе, азмы-күпме билгеле дип уйлыйм. Шуның өчен хәяте һәм эшчәнлегенең кайбер этапларын билгеләү белән генә чикләнәм.

1841 елда[2] туган Исмәгыйль бәй — гадәттән тыш язмышлы адәмнәрдән. Төркичелектә олы хезмәтләре өчен ул, барыннан да бигрәк, яратылышына бурычлы. Тәртипле уку дәвере — бер-ике ел: әлифба һәм Коръән өйрәнә. Мәскәү хәрби академиясендә уку чорында 4-5 ел, өстәмә рәвештә, рус теле дәресләрендә тырышлыклары. Милли хис, милли аң башлангычлары җанлана. Бу базар (ял) көннәрендә өйләрендә кунак була торган рус милләтпәрвәрләре белән милли мәсьәләләрдә сохбәтләшүләр нигезендә формалаша. Панславистлар рәисе Катковның грек ихтилялы мөнәсәбәте белән төрекләр турында язган мәкаләләрен укый. Бу чакта Исмәгыйль бәй 14-15 яшьләрендә була. Михаил Катковның «Москва» газетасында төрекләргә һәм мөселманнарга ачулы мәкаләләре яшь һәм кайнар хисле Исмәгыйль бәйне шул кадәр ярсыта ки, 1867 елның язында ул, Критка китеп, дүрт-биш еллык хәрби белемен андагы төрекләргә багышлау турында чынлап хыяллана. Мостафа мирза Давидович дигән бер дусты белән юлга чыга. Одессада паспортсыз пароходка эләгергә мәш килгәндә жандармнар кулына төшеп, әти-әниләренә тапшыралар.

Бу маҗарадан соң, Исмәгыйль бәй хәрби мәктәпкә әйләнеп кайтмый. Кырымда кала, Бакчасарай шәһәрендә Миңлегәрәй хан заманнарыннан калган «Зынҗырлы» мәдрәсәдә рус теле укытучысы булып эшли башлый. 1871 елга кадәр шунда эшли. Истанбулга китеп төрек гаскәрендә офицер яки берәр идарәдә язу-сызу эшендә эшләү турында уйлый башлый. Бер кардәше Истанбулда нindider идарә эшендә эшли икән… Истанбулда мәэмүр була алыр өчен, ул француз телен өйрәнә. Француз телен адәм рәтлерәк өйрәнер өчен, Истанбулга Париж аша барырга тели. Шул максат белән 1872 елның язы ахырларында Парижга китә һәм ике ел анда яши. Исмәгыйль бәйнең Парижда яшәешенең казанышы — көнбатыш яшәешен, көнбатыш мәдәниятенең гүзәл һәм чиркәнеч якларын, яхшылык-начарлыкларын, меғ төрле каршылыклары белән сугыша-тартыша үз тәҗрибәләре белән өйрәнүе булуы. Андый яшәеш Көнчыгыштан килгән юлаучы бер яшь егет өчен генә түгел, җирле халык өчен дә кыен нәрсә. 21-22 яшьләрендә Исмәгыйль бәй, япа-ялгыз, саф үз хисабына, үз тырышлыгы белән ике ел Парижда яши. Ул чакларда Парижда булган «Яшь госманлылар» белән бәйләнешкә керүен исбатларлык материал кулыбызда юк.

1874 елда Истанбулга килә. Төрек, рус теленнән тыш француз телен дә белә. Госманлы идарәләрендә берәр эш эзли. Берара аны Хәрби мәктәптә рус теле укытучысы итеп алырга булалар. Вакыт уза. Эш барып чыкмый. Бар көчкә тырышулары нәтиҗәсез калгач, ул Кырымга кире кайтырга мәҗбүр була. Ел буена Исмәгыйль бәй Истанбулның идарә даирәләрендә

[2] Исмәгыйль бәй Гаспринский 1851 елда туа.

күп бутала, әмирләр, мәэмүрләр белән якыннан таныша. Истанбул газеталарын өзлексез күзәтеп бара. Госманлы дәүләтенең эчке идарә ысулларын, дәүләтара мөнәсәбәтләрен тикшерә. Кыскасы, Истанбулны, Төркияне, андагы идарә итүчеләрне якыннан күреп, җентекләп өйрәнә.

Исмәгыйль бәйнең журналистлык эшчәнлеге Истанбулда башлана. Ул Истанбулдан Мәскәү һәм Петербургның кайбер газеталарына Көнчыгыш бизәкле, ярымхыялый хатларын җибәреп тора һәм алар бу газеталарда басыла.

Кырымга кайтканнан соң, дүрт ел буе бер кайда эшләмичә, ул милләттәшләреннән төрле катлау кешеләренең тормыш шартларын һәм яшәеш рәвешләрен җентекләп күзәтеп вакыт үткәрә. Соңыннан үзенең кичерешләрен хикәяләрендә чагылдыра. 1906 елда (№9) «Тәрҗеман»да «Төрлеләр» рубрикасында басылган «Көнтугды» хикәясенең каһарманы Даниял бәй — шәхсән, Исмәгыйль бәйнең үз образы. Хикәядән, 1874-1878 елларда Исмәгыйль бәй ниләр уйлаганын, ниләр эшләгәнен бер дәрәҗәдә күз алдына китерә алабыз: *«Милләтнең хәлен белми торып милләткә хезмәт күрсәтү мөмкин булмаганын аңлагач та, Даниял бәй (ягъни Исмәгыйль бәй) шул хакта гыйлем һәм мәгърифәтен арттырырга карар биреп, милләте арасына атылды. Авыл туйларында дәрвиш һәм галәма мәҗлесләрендә, эшсезләр һәм агалар сый табыннарында, мәдрәсә һөҗрәләрендә һ.б. төрле җыелышларда катнашып, аз сөйләп, күп тыңлап, бер ел буена гамәли дәресләр алды. Һәр сыйныфның яхшы якларын һәм сискәндергеч хәлләрен күреп, өйрәнеп, милли зәгыйфьлегебез кайдан килә икәнен, нигә мохтаҗлыкта яшәвебезне аңлады. Ни эшләргә, эшне нәрсәдән башларга, сүнгән күңелләрне нинди очкын белән ялкынландырырга, аңны бикләгән коймаларны ничек ишәргә һәм гафләт сәхрәсендә калдырылган бичара милләтне ни белән аякка калкытырга, кебек сораулардан күп заманнар интекте…»*

1878 елда Бакчасарайда шәһәр башлыгы итеп сайланды. Шәһәр башлыгы буларак, 1879 елда төрки телдә бер газета чыгарырга рөхсәт сорап, бу эш белән бәйләнешле урынга гариза бирде. Туктатылган «Игенче» урынына аксый-туксый чыга торган «Кәшкүл» һәм «Зыя»дан башка бөтен Русиядә бер төрки газета юк. Исмәгыйль бәй үтенеченә тискәре җавап килде. Газета чыгару мәсьәләсенә чумган Исмәгыйль бәй югарыда телгә алынган рус телендәге «Русия мөселманлыгы» мәкаләләрен язып бастыра. Бу мәкаләләр Гаспралыны шул заманнарда, ягъни 1881 елда, борчыган, җәмәгатьчелектә кузгалтырга тырышкан карашларын ачык чагылдырганы кебек, киләчәктәге фикер хәятенең, бер төрле программасының да бәяне иде. Исмәгыйль бәй бу юнәлештә 45 битле бер китап та язып бастыра. Бу китаптан аның милләтче икәнлеге ачык аңлашыла. *Ул кырымлыларны гына түгел, «төрек-татар» атамасын йөрткән барлык төрки халыкны үз милләте дип саный.* Шуңа күрә Исмәгыйль бәйне «бөтен төркиче»ләрдән дип санап була. «Русия мөселманнары»нда милләтчелек мәсьәләсе гаять мөһим күренеш буларак күз алдында тотыла. Шул мөнәсәбәт белән бәйләнештә тагын бер мәсьәлә уртага куела: *«Азиядә һәм Европаның бер өлешендә тупланган бертөсле милләт — төрек-татар милләте бар. Бу милләт кисәк-кисәк бүлгәләнгән, таркау, зәгыйфь. Ул, башка милләтләр белән чагыштырганда, гыйлем һәм мәгърифәт, байлык һәм мәдәният ягыннан бик артта калган. Бу хәл моннан соң да шулай дәвам итсә, табигый яшәү өчен көрәш кануны буенча, юкка чыгачак».* Хәтерләсәгез бу фикер Зәрдәбидә дә бар иде — *«башка милләтләр тара-*

фыннан йотылачак». Шул торышны (вәзгыятьне) күзаллаудан төп мәсьәлә мәйданга килә: Төрек-татарларның зәгыйфьлегенең, башка милләтләрдән артта калуының сәбәбе нәрсәдә? Төрек-татар милләтен бу куркыныч язмыштан коткарыр өчен нәрсә эшләргә? Бу ике мәсьәлә Исмәгыйль бәй фикере һәм эшчәнлегенең соңгы сулышына кадәр өстенлек итә һәм аның бөтен хәяте шул ике мәсьәләгә җавап бирүгә каратыла. Исмәгыйль бәйнең фикер тарихы — шушы ике мәсьәләгә җавап бирү. Аның эшчәнлеге (шәхси тормышы табигый ки, шуңа кагылышлы) — тапкан җавапларын гамәлгә ашыруга юнәлтелгән тырышлыклар тарихы.

«Русия мөселманлыгы» китабы шул мәсьәләнең беренче сызмалары. Безнеңчә, Исмәгыйль бәйнең иң әһәмиятле ачышларыннан берсе — төрекчелек (төркичелек) карашы. *«Төрек-татарлар үз мәктәп-мәдрәсәләрендә үз телләрендә Европа фәннәрен, белемен, һөнәр һәм сәнәгатен өйрәнсеннәр. Мәктәп-мәдрәсәләр белән генә чикләнмәстән, (аларны) үз телләрендәге китап, рисаләләрдә газета-журналларда язып таратсыннар».* Кыскасы, шул максатка каратылган милли бер төрек-татар әдәбияты мәйданга китерелергә тиеш. Күренә ки, фәннәрне, сәнгатьләрне һәммә әдәбиятны иңләрлек милли тел булдыру мәсьәләсенә, шәех Җәмалетдин Әфганидагы кебек үк, олы кыйммәт бирелә. Русларны өркетмәс өчен «Русия мөселманлыгы»н Гаспралы, зур осталык белән саклык күрсәтеп язарга тырышса да, кайбер рус тәнкыйтьчеләре бу әсәрдә бөтен мөселман төрекләрен (төркиләрен) Көнбатыш мәдәнияте белән куәтләндереп бер сәяси көч барлыкка китерү, шул рәвешчә Русия дәүләте башын бөек бер бәлагә юлыктыру, ягъни бөтен төреклек (гомум төрки) идеясен табып, төркиләрне берләштереп хөкүмәткә каршы аякландыру итеп күрсәтергә тырышалар.

Исмәгыйль бәйдә фикер һәм эшчәнлек, үз сүзләре белән әйткәндә, «ният һәм гамәл» бер берсеннән аерылмаган. Бик зур тырышлыклар белән, ниһаять, «Тәрҗеман» газетасын чыгару мөмкинлеген дә кулга кертә. 1883 елның 10 апрелендә газета чыгарыла башлый. Нашир сүзләре белән әйткәндә: *«Яз кояшы белән дөнья терелеп чәчәкләнгән көннәрдә күп еллардан бирле карлы кәфеннәрен өртелеп үле кебек йоклаган төньяк төрекләренең (төркиләренең) беренче ак яз чәчәге «Тәрҗеман» ачыла».*

«Тәрҗеман»ның беренче көннәрдә иң мөһим темасы — милләткә үз телендә гыйлем бирү, Европа гыйлемнәрен һәм мәгърифәтен, һөнәр һәм сәнәгатен казану. Моның өчен милләт балаларын тиз өйрәнү методы белән укыту мөһим. Шул рәвештә формалашып, барлык төньяк төрекләре (төркиләре) арасында «ысулы җәдид» мәктәпләре тарала. «Ысулы җәдит» атамасы Госманлы төрекләреннән алынган. Бу аталма ул чакларда Истанбул социаль тормышында кулланышка кергән тәкъбирләрдән. «Ысул җәдит» башта, мәгариф һәм укырга өйрәтүдә махсус аталма булып күренсә дә, вакыт барган саен, мәгънәсе киңәеп яшәеш рәвеше атамасынача күтәрелә. Кирәк Госманлы төрекләре арасында, кирәк Төньяк төрекләре (төркиләре) арасында «ысулы җәдит»нең мәгънә эчтәлеге — Көнбатыш гыйлемнәрен, мәгарифен һәм укыту ысулларын, Көнбатыш яшәеш рәвешен үзләштерү, кыскасы, «көнбатышлану» димәктер. Исмәгыйль бәй — бөтен төрки дөньяда, аеруча, Төньяк һәм Көнчыгыш төрекләре (төркиләре) арасында «көнбатышлану»ның иң эшчән пропагандалаучысы булды. Моны, үз телләрен җуймау шартларында, төрки милләтләрнең көнбатышлашуы аларның милли хәятләрен саклап яшәүнең чарасы икәненә ул ихлас күңелдән ышана иде.

Төрек теленнән
***Мәсгуд Гайнетдин** тәрҗемәсе* ■

1 АВГУСТ — БЕРЕНЧЕ БӨТЕНДӨНЬЯ СУГЫШЫНДА ҺӘЛАК БУЛГАН РОССИЯ ХӘРБИЛӘРЕН ИСКӘ АЛУ КӨНЕ

БЕРЕНЧЕ БӨТЕНДӨНЬЯ СУГЫШЫ (1914-1918) БАШЛАНУГА 100 ЕЛ

«ВАТАНПӘРВӘРЛЕК НӨМАИШЛӘРЕ*»

(Сугыш башланган көннәрдә Казанда булган демонстрацияләр)

Ленар Гобәйдуллин

Ошбу елда кешелек тарихындагы иң зур сугышларның берсе — Беренче Бөтендөнья сугышы башлануга 100 ел тулды. Сугыш башлануга сылтау булып, 1914 елның 28 июнендә Сараевода Австрия эрцгерцогы Франц Фердинандның Сербия террористы тарафыннан үтерелүе тора. Асыл сәбәп — икътисади-сәяси йогынты ясау өлкәләрен киңәйтү, сәүдә мәйданнарына, чимал чыганакларына, коллонияләргә хуҗа булу һәм гомумән, дөнья белән хакимлек итү өчен барган кискен каршылыклардан гыйбарәт. 28 июльдә Австро-Венгрия — Сербиягә, 1 августа Германия — Россиягә, ә 3-4 августта Фрнциягә һәм Бельгиягә, 4 августта Британия империясе — Германиягә, 6 августта Австро-Венгрия — Россиягә сугыш ача. Шул чор рус һәм татар чыганакларында «Бөек сугыш», «Олуг сугыш», «Икенче Ватан», «Бөек Ватан», «Рус-Герман», «Герман», «Гомуми Яуропа сугышы», 1939 елдан соң «Икенче Бөтендөнья сугышы», «Империалистик сугыш» дип аталган кораллы бәрелешләр башланып китә. Сугыш Антанта илләре (Россия, Франция, Бөекбритания, Сербия, соңрак Япония, Италия, Румыния, АКШ) һәм Үзәк державалар (Германия, Австро-Венгрия, Госманлы империясе, Болгария) арасында (барлыгы 38 дәүләт) барган канкоешлы кораллы бәрелешләрдән гыйбарәт. Сугышта Россия дә үзенең Балканда йогынтысын урнаштырырга, Кара диңгездән Урта диңгезгә чыгу өчен Дарданелл бугазын үзләштерергә теләгән, Константинопольне һәм Австро-Венгриянең бер өлеше булган Галициягә не яулап алырга омтылган. Россиядә Февраль һәм Октябрь, Германиядә Ноябрь инкыйлабларына бер сәбәп булган, Госманлы империясе һәм Австро-Венгриянең җимерелүенә китергән әлеге сугышта, соңгы мәгълүматларга караганда, 10 млн солдат, 12 млн тыныч тормышта яшәүче үтерелә, 55 млн кеше яралана. Россиянең исә 2 млн чамасы хәрбие һәлак була, 2,5 миллионы хәбәрсез югала яки әсирлеккә төшә.

Әмма без биредә сугышның сәбәпләрен, барышын, нәтиҗәләрен тикшермибез — болар турында күптомлы китаплар язылган һәм әле тагын да язылыр. Безне сугышның беренче көннәрен Казан халкы, аеруча башкалабызда яшәүче татарлар ничек кабул иткән — шул кызыксындыра.

1914 елның 20 июлендә (яңа стиль белән 2 августында) Император Николай II Кышкы сарайның балконыннан Россиянең сугышка катнашуы турында «Высочайший Манифест» игълан итә. Әлеге документ татар теленә дә тәрҗемә ителеп, «Гали манифест» исеме белән «Кояш» һәм «Йолдыз» газеталарының 22 июль (4 август) саннарында басылып чыга. Текстлар эчтәлеге белән охшаш булсалар да, тел-стиль, тәрҗемә ителеше ягыннан аерылып тора. Игътибарыгызга әлеге манифестның заманында «Йолдыз» газетасында басылган тәрҗемәсе тәкъдим итәлә, «Кояш»та басылганыннан аерма-

* Нөмаиш — тантана, демонстрация.

лы буларак, биредәгесе рус телендәге нөсхәгә тулысынча диярлек тәңгәл килә. (Рус телендәге текст белән интернет сәхифәләрендә танышырга мөмкин.)

Сугыш башлану белән хакимият алдында катлаулы бурыч — сугышны идеологик яктан оештырырга, халыкның рухын күтәрергә, аны җиңүгә илһамландырырга кирәк була. Патшаның «Гали манифесты»нда Россиянең сугышта катнашуы ике сәбәп белән күрсәтелә: Сербияне яклау («братское чувство русского народа к славянам) һәм «оградить честь, достоинство, целость России и положение её среди Великих Держав». Ягъни патша манифесты, икътисади мәнфәгатьләрне түгел, ә гомум славян һәм Россиянең куркынычсызлыгы мәсьәләләрен күз алдында тота. Беренче мәнфәгатьтән («бер канда булган славян халыкларының башларына килгән вакыйгага катышу») бигрәк, Ватан азатлыгына бәйле икенче юнәлеш, аеруча гади халык арасында, массакүләм ватанпәрвәрлек хисләрен уятырга сәбәп булгандыр. Шул уңайдан, Россиянең төрле шәһәрләрендә, шул исәптән Казан гыйбадәтханәләрендә, урамнарында, Ватан азатлыгын, рус гаскәриләренең җиңүен, падишаһ хәзрәтләренең исәнлеген теләп, шул чор чыганакларында «дога нөмаишләре», «хөббелватан нөмаишләре», «мөхиббелватан», «Ватан нөмаишләре», «ватанпәрвәрлек нөмаишләре», «демонстрацияләр», «манифестацияләр» дип исемләнгән тантаналар уза. Әлеге вакыйгаларга татарлар да бик теләп катнаша, хәтта үзләре, зыялылар һәм имамнар җитәкчелегендә манифестация оештыралар. Манифестациянең төп максаты да халыкны сугышка дәртләндерү, сугышка өндәүдән гыйбарәт, чөнки нәкъ менә Казан губернасы сугышның башыннан азагына кадәр гаскәрне төрле кирәк-ярак һәм солдатлар белән тәэмин итү буенча гомумроссия үзәгенең берсенә әверелә. Әмма сугыш башланып, берничә ай үтүгә, Россиянең сугыштагы алмаксатлары гади халыкка берникадәр аңлашыла төшкәч, аеруча 1 ноябрьдә Россия Төркиягә сугыш игълан итү белән әлеге ватанпәрвәрлек хисләре сүрелә.

Тәкъдим ителгән текстлардан демонстрацияләрнең 20 июльдә (2 август) Александр II мәйданында, Арча кырында булганлыгы, 21 июльдә (3 август) Юнысов мәйданыннан башланып киткәнлеге күренә. 20 июльдә хәзерге «1 май» мәйданында булган «азат итүче патша» Александр II һәйкәле янына 7 меңгә якын кеше «тезләнүе» мәгълүм. (Казанда 1914 елда 194 200 кеше яшәгән.) «Кояш»та «Русиядәге хәзерге хәлләр мөнәсәбәте белән Казан мөселманнары вә хәзрәтләре тарафыннан ясалган манифестация» һәм «Йолдыз»да дөнья күргән «Казан мөселманнарының ватанпәрвәрлек нөмаишләре» исемле мәкаләләрнең сюжетлары охшаш булса да, мәгълүмати яктан алар бер-берсен тулыландыра. Шунысын да искәртик, «Йолдыз» газетасында басылган мәкаләнең авторы — танылган мөгаллим, язучы, журналист Фатих Сәйфи. Ул 1912 елдан 1918 елның гыйнварына кадәр Уфа шәһәрендә яши. Әмма «Йолдыз» газетасы 1914 елның 22 июль санында: «Газетабызның язышучыларыннан Һади әфәнде Атласов, учитель Фатих әфәнде Сәйфи шәһәребездә мосафирлардыр», — дип хәбәр бирә, димәк, журналист вакыйгаларны үз күзләре белән күреп, аның шаһиты була.

Бу мәкаләләрдән мөселманнарның кайсы урамнар буенча хәрәкәтләнүе, бу хәрәкәтне кемнәр һәм ни рәвешле, нинди рухта оештыруы, татарларның Казан губернаторы Пётр Михайлович Боярский, Казан хәрби округының гаскәр башлыгы Антон Егорович Зальца белән очрашулары турында җентекле мәгълүмат алырга мөмкин. Казан мөселманнарының «падишаһка вә Ватанга җан аямыйча берлек илә хезмәт итәргә әзер икәнлекләре» турында, губернатор П.М.Боярскийның төбәктәге христиан һәм башка дин вәкилләренең «Ватанның олуг вә бәхетле булуы өчен дошманны таптап барырга яки үтергә әзер торганлыклары» хакында император Николай IIгә җибәргән телеграммалары һәм императорның, рәхмәт хаты буларак, җавап телеграммасы да тәкъдим ителә…

ГАЛИ[1] МАНИФЕСТ

Алланың мәрхәмәте илә без Николай Икенче, Император һәм Бөтенрусиянең мөстәкыйль хөкемдары, Польшаның падишаһы, Финляндиянең бөек кенәзе вә гайреләр вә гайреләр вә гайреләрнең хөкемдары.

Үземезнең итагатьле рәгыяләремезгә[2] игълан итәмез: Русиянең үзенең тарихи гомерләренә кайтып каралса һичбер заманда да Русиянең үзе илә бер дин һәм бер канда булган славян халыкларының башларына килгән вакыйгаларның һичберсенә дә катышмый калганы юктыр. Соңгы көннәрдә Австро-Венгрия Сербиядән, аның падишаһлыгы тарафыннан кабул ителүе һич мөмкин түгел икәнлеге мәгълүм булган таләбләрдә булды. Сербия хөкүмәтенең ригая[3] илә һәм солыхны саклау юлында биргән җавапларын яратмыйча[4], Русиянең дустлык илә васитачылыгын кабул итмичә Австрия хөкүмәте, корал илә һөҗүм итәргә ашыгып, һичбер җәһәттән мөхафәзә ителмәгән[5] Белград шәһәрен[6] тупка тотты. Ошбу хәлләр вөҗүдкә килү[7] аркасында, тиешле саклык тәдбирләре[8] кыйлырга мәҗбүр булганлыгымыздан без, коры җир һәм диңгез гаскәрләрен сугыш хәленә китерергә әмер иттек[9], ләкин безнең рәгыяләремезнең барлыклары вә анларның каннарының кадерен белгәнлегемездән ике арада башланган мохабәрәләрнең[10] солых илә тәмам булуына иҗтиһадларымызны сарыф кыйлдык. Дустлык илә булган мөгамәләләремез арасында, Австриянең иттифакташы[11] булган Германия, безнең өмидләребезгә, безнең күп гасырлардан бирле килгән яхшы күршелекләремезгә һәм безнең кыйлган тәдбирләремезнең[12] һичберсе аңар дошманлык максудлары илә эшләнгән эшләр түгел икәнлегенә илтифат[13] итмичә, анларның һәркаюсының тизлек илә үзгәртелүләрен таләб кыйлды[14] һәм аның бу таләбләре рәд кыйлыну[15] илә кинәттән Русиягә сугыш игълан кыйлды.

Хәзер инде безгә, үземезгә карендәшлекләре булган вә гадаләтсезлек[16] илә тәхкыйрь ителгән[17] мәмләкәтемезне химая кыйлу[18] илә генә калырга тугры килми, бәлки Русиянең гыйрдын[19], бөтенлеген һәм Русиянең башка мәмләкәтләр гандендәге[20] дәрәҗәсен саклау өчен эшкә керешергә тиеш буладыр.

Без үземезнең сәдакатьле рәгыяләремезнең[21] һәркаюсының үзләренең җаннарын фида итеп[22], рус җирен саклауларына ышанамыз. Бу агыр эшләрне булдыру вакытында, тәкъдирнең агыр сәгатьләрен баштан кичерү заманнарында дахили кинәләр[23] онытылып, падишаһның үз халкы илә якыннан берләшүе мөхкәм[24] булсын һәм бөтен Русия берләшкән бер кеше шикелле булып, дошманның явызлыкларын дәфгы кыйлсын[25].

Үземезнең эшемезнең хаклыгына кямил[26] ышанып һәм Алланың кямил кодрәтенә таянып, без изге Русия һәм аның шөһрәтле гаскәренә Алланың мәрхәмәт итүе илә дога кыйламыз.

Бирелде Санкт-Петербургта, июльнең егерменче көнендә миляде Гайсәдән[27] 1914 нче елда, безнең падишаһлыгыбызның егерменче елында.

Асыл нөсхәсендә падишаһ әгъзәм хәзрәтләренең үз куллары илә имза кыйлынган.

«Николай»

Йолдыз. — 1914. — №1233. — 22 июль.

[1] Гали — бөек.
[2] Рәгыйя — бер дәүләтнең халыклары.
[3] Ригая — хөрмәт.
[4] Солыхны саклау юлында биргән җавапларын яратмыйча — Франц Фердинанд үтерелүне сылтау итеп, 1914 елның 23 июлендә, Австро-Венгрия Сербиягә ультиматум куя: үзләренә каршы пропаганда алып бара торган түрәләрдән дәүләт аппаратын чистартырга, терроризмда катнашы булганнарны кулга алырга, Австро-Венгрия полициясенә Сербия җирләренә керергә һәм антиавстрийстик хәрәкәтләрдә катнашкан гаепплеләрне хөкемгә тартырга таләп итә. Боларны гамәлгә ашырырга нибары 48 сәгать вакыт бирелә. Шул ук көндә Сербия, австрияле полицияне үз территориясенә кертүдән

Николай II Кышкы сарайның балконыннан Германия белән сугыш игълан итә. 1914 ел, 20 июль (2 август)

кала, бар таләпләрне эшли һәм мобилизация игълан итә.

[5] Мөхафәзә ителмәгән — хәрби яктан сакланмаган.

[6] Белград шәһәре — Сербиянең башкаласы һәм иң эре шәһәре.

[7] Вөҗүдкә килү — барлыкка килү.

[8] Саклык тәдбирләре — саклану чаралары.

[9] Сугыш хәленә китерергә әмер иттек — 31 июльдә Николай II гомуми мобилизация турындагы указга кул куя.

[10] Мохабәрәләрнең — хәбәрләшүләрнең.

[11] Иттифакташы — союздашы.

[12] Тәдбирләребезнең — чараларыбызның.

[13] Илтифат — игътибар.

[14] Анларның һәркаюсының тизлек илә үзгәртелүләрен таләб кыйлды — Германия Россиядә моабилизацияне бетерүне таләп итә, үтәмәгән очракта сугыш игълан итәчәге турында ультиматум куя.

[15] Рәд кыйлыну — кире кагылу.

[16] Гадаләтсезлек — гаделсезлек.

[17] Тәхкыйрь ителгән — хурланган.

[18] Химая кыйлу — саклау.

[19] Гыйрдын — «честь», «достоинство» сүзләре шулай тәрҗемә ителгән. «Кояш» газетасында «шәүкәтен» [бөеклеген] дип тәрҗемә ителгән.

[20] Гандендәге — арасындагы.

[21] Сәдакатьле рәгыяләремезнең — тугрылыклы ватандашларыбызның.

[22] Фида итеп — корбан итеп, ягъни җаннарын кызганмыйча.

[23] Дахили кинәләр — эчке ачу тотулар.

[24] Мөхкәм — таза, нык.

[25] Дәфгы кыйлсын — бетерсен.

[26] Кямил — тулы.

«Йолдыз» газетасының Николай II манифесты басылган бите. 1914 ел, 22 июль (4 август)

[27] Миляде Гайсәдән — Гайсә пәйгамбәр туган көннән (Рождество Христово) башланган, ягъни хәзер гамәлдә булган ел исәбе.

КАЗАНДА НӨМАИШЛӘР

20 июльдә[1] көндез күп халык император Александр икенче мәйданына флаглар вә император Николай хәзрәтләренең рәсемен күтәреп: «Яшәсен падишаһ Николай икенче! Яшәсен гаскәре вә Русия!» — дип кычкырып урамнар буенча йөрделәр. Халык бик күп иде. Йөри торгач, 6000нән 7000гә кадәр булды.

Шул ук көнне кич сәгать 11 илә 12 арасында Арча кырында Русская Швейцариядә[2] 300ләп кеше җыелеп, нөмаиш ясый башладылар. Флаглар вә император Николай хәзрәтләренең рәсемен күтәреп, Русская Швейцариядән кузгалып, Грузинская урамга[3] төштеләр. Гаскәр башлыгы йорты катында туктап: «Яшәсен император Николай!», «Яшәсен гаскәри Русия!» «Далой Германия вә Австрия!» — дип кычкырып гимн җырладылар вә «Ура!» кычкырып, урамнарны тутырдылар. Моннан Император Александр II мәйданына[4] килеп, аның һәйкәле[5] каршысында бар кеше тезләнделәр. Соңрак, губернатор җәнапларына барып[6], гимн җырлый башладылар. Губернатор җәнаплары чыгып, халыкка рәхмәтләр укыды. Шулвакытта халык 3000нән артык иде. Моннан, казармаларга барып[7], офицерларны күтәргәннән соң, 16 нчы сапёрный батальонның музыкасын алып, икенче часть районына[8] төшеп киттеләр. Бу манифестациядә 5000 кешедән артык булган һәм иртә илә кояш чыкканчы урамнар буенча йөргәннәр.

Йолдыз. — 1914. — №1233. — 22 июль.

КАЗАН МӨСЕЛМАННАРЫНЫҢ ВАТАНПӘРВӘРЛЕК НӨМАИШЛӘРЕ

21 июльдә мөселманнар тарафыннан сугышта русларның галәбә килүен [җиңүен] теләп, дога кылыначак иде. Шуңа бинаән иртән сәгать 10да Юнысов мәйданына халык җыела башлады. 11 нчегә киткәндә мәйдан инде мөселманнар берлә тулган иде. Мөселманнардан башка, бераз руслар да, полицмейстер могавине [ярдәмчесе], приставлар, полицейский шикелле мәэмүрләр [чиновниклар], бәгъзе офицерлар хазир иде. Мәйдан төрле флаглар берлә зиннәтләнгән иде. Мөнбәрнең кырыена падишаһ хәзрәтләренең рәсеме дә куелган иде. Иң башта мөнбәргә мелла ахун Хисаметдин хәзрәт һәм бер кариэ[9] менделәр. Кариэ әфәнде Коръәннән берничә аять вә сүрәи «Ихлас» укыды. Аның артыннан бөтен халык бер авыздан тәкбир әйттеләр. Соңрак дога кылдылар. Догадан соң ахун хәзрәт торып, үзенең электән язып куйган, татарча догасын укыды. Доганың мөндәриҗәсе [эчтәлеге] яхшы булдыгыннан, ярыйсы гына әсәрле чыкты. Халык: «Амин! Амин!» — дип кычкырып тордылар. Соңрак мөнбәргә управа члены Шакир әфәнде Апанаев менеп, Казан мөселманнары исеменнән падишаһка биреләчәк телеграмманы укып күрсәтте. Соңрак халык акырын гына мәйданнан кузгалып, флаглар, патша хәзрәтләренең рәсемен күтәргән хәлдә, Екатерининская урам[10] буйлап, крепостька[11] юнәлделәр. Урам-

[1] Даталар иске стиль белән бирелә.
[2] Русская Швейцария — ял һәм күңел ачу паркы хәзер М.Горкий исемен йөртә.
[3] Грузинская урам — хәзерге Карл Маркс урамының Ирек мәйданына кадәрге өлеше.
[4] Александр II мәйданы — хәзер «1 май» исемен йөртә.
[5] Әлеге мәйданга Александр IIнең һәйкәле 1895 елда куела һәм 1918 елда җимерелә.
[6] Губернатор җәнапларына барып — губернатор саренда хәзер ТР Президенты резиденциясе урнашкан.
[7] Казармаларга барып — Кремльдә Юнкерлар пехота училищесы һәм аның казармалары булган.
[8] 2 нче часть районына — Сул як Болак урамыннан Идел елгасы үзәнлегенә кадәрге мәйдан.
[9] Кариэ — Коръән хафиз.
[10] Екатерининская урам — хәзерге Тукай урамы.
[11] Крепостька — кремльгә.
[12] Тихвинская урамы — шул ук Тукай урамы, Екатерининская белән Тихвинская урамнарын Евангелистовская урамы (хәзерге Татарстан) аерып торган.

да туктап тәкбирләр әйтәләр, «Ура!» кычкыралар. Мәэмүрләр алдан тәртип саклап баралар. Екатерининскаядан Тихвинскаяга[12] чыгып, аннан Проломнаяга[13] чыктылар. Проломнаядан мөселманнарга күп кенә руслар да кушылдылар. Бу кушылган руслар бераз җырлап бардылар. Ләкин тиз туктадылар. Урамда һәмишә [һаман] тәкбир тавышлары яңгырый. Йортларның тәрәзәләреннән кешеләр карап кала. Тамашачылардан бик күп кешеләрнең күзләрендә яшьләр ялтырый. Бәгъзе кычкырып җылаучылар да очрый. Халыкның рухы күтәренке. Җыелган халык, крепость тугрысына җиткәч, казармадан оркестр килеп кушылды. Губернатор сараена музыка берлә юнәлделәр. Крепость эчендә һәмишә музыка уйный, тәкбир, «Ура!» тавышлары яңгырый. Инде халык бик күбәйгән, руслардан да бик күп кушылганнар. Губернский мөәссәсәләрдә [оешмаларда] хезмәт итүчеләрнең һәммәсе тәрәзәгә, ишекләргә килгәннәр. Бергә кушылып, «Ура!»кычкыралар. Сарай алдына керделәр. Губернатор йортының ишек төбенә туктадылар. Озакламый ишектән губернатор җәнаплары үзе дә күренде. Меллалар вә башкача олуглар илә исәнләшкәч, хәлгә вә мәкамгә мөнасиб [ярашлы] кыска гына нотык сөйләде. Мөселманнардан үзенең бик мәмнүн [канәгать] икәнлеген бәян итте. Ниһаять, Сөембикә манарасы каршындагы буш урынга килеп, бер мәйдан ясалды. Уртада губернатор, меллалар вә башка мәэмүрләр булган хәлдә, кариэ тарафыннан Коръән укылды. Ахун хәзрәт догасын укыды. Халык: «Амин!» — дип тордылар. Тәкбир әйттеләр. «Ура!» кычкырдылар. Соңрак губернатор сараена кереп китте. Халык музыка илә шәһәр башлыгына таба юнәлде. Юлда шәһәр думасы[14] рында туктап, «Ура!» кычкырдылар, тәкбир әйттеләр. Аннан Воскресенская[15] буйлап бераз баргач, Грузинская урамыннан гаскәр башлыгының йорты каршына килделәр. Анда туктап, тәкбир әйткәч, «Ура» кычкыргач, озакламый гаскәр башлыгы үзе килеп чыкты. Халык белән исәнләшкәч, кыска гына нотык ирад итте [сөйләде]. Аңа шәһәр мөселманнары исеменнән русча язылган адрес тәкъдим ителде. Соңрак, музыкачылар казармага, халык үз йортына кайтып китте.

Ф.Сәйфи.
Йолдыз. — 1914. — №1233. — 22 июль.

РУСИЯДӘГЕ ХӘЗЕРГЕ ХӘЛЛӘР МӨНӘСӘБӘТЕ БЕЛӘН КАЗАН МӨСЕЛМАННАРЫ ВӘ ХӘЗРӘТЛӘРЕ ТАРАФЫННАН ЯСАЛГАН МАНИФЕСТАЦИЯ

21 июльдә Юнысовлар мәйданында мөселманнар тарафыннан дога булачак, дип берәр көн алдан билгеләнгәнгә, мин көндез 11 сәгатьләрдә мәзкүр мәйданга киттем. Ләкин мин бераз соңга калганмын икән. Мин Екатерининская урамының башына җиткәндә берничә йөз мөселман Евангелистовская урамына[16] таба киләләр иде. Иң алда егермеләп флаг күтәргән бүрекле мөселманнар килә вә ике мөселман падишаһ әгъзәм хәзрәтләренең зур бер рәсемен мәһабәт бер рәвештә күтәргәннәр иде. Ошбуларның артында, беренче сафта, шәһәрнең могтәбәр хәзрәтләре һәм башка могтәбәр затлары тезелгән. Фәкать ягъмур явып торганга халыкка бераз уңайсыз иде. Евангелистовская урамына чыккач, хәзрәтләр вә халык туктап, тәкбир әйттеләр. Соңрак ошбу халык күбәя-күбәя Ак мәсҗед[17] янына килде вә шунда туктап, янә тәкбир әйтте. Манифестацияләр эчендә һәртөрле кар-

[13] Проломная — хәзерге Бауман урамы.
[14] Казан шәһәре думасы хәзер дә шул ук бинада урнашкан (Кремль урамы, 1 йорт).
[15] Воскресенская — хәзерге Кремль урамы.
[16] Евангелистовская урамы — хәзерге Татарстан урамы.
[17] Ак мәсҗед — хәзерге Париж Коммунасы һәм Мәскәү урамнары чатындагы Нурулла мәчете.

ты вә яше күп иде. Хосусан [аеруча], мәсҗед картлары вә суфи мөселманнар күбрәк иде. Һәм бу халыкның йөзләрендә җәдид вә тәэсир галәмәтләре күренеп тора. Халык Ак мәсҗед яныннан Печән базары (Сенная) урамы[18] илә Мәскәүский урамына[19] чыкты вә Мәскәүский урамы белән квартал баргач, ягъни Фуксовская урамга[20] җиткәч, Болак тарафына вә аннан үтеп, Проломнаяга чыкты. Ягъмурның шәбәюенә карамый халык һаман күбәя бара, халык туктап, гяһ [кайчак] тәкбир әйтә, гяһ «Ура!» кычкыра иде. Бәгъзе урыннарда тәкбир белән «Ура!»ның катнашып китүләре дә булды. Проломнаяда халык бигрәк күбәйде.

Манифестантлар урам буенча барганда тәрәзәләрдән караган руслар «Ура!»ларга вә тантанага катнашалар һәм мөселманнарны тәбрик кылалар иде. Ниһаять, мөселманнар крепость астына җиттеләр вә шуннан Хан мәсҗеде[21] янына, ягъни губернаторның икамәтгяһенә [тора торган урынына], кайсы юл илә менү тугрысында бераз ихтиляф булып [ызгышып], байтак вакыт туктап калдылар. Ягъни крепостька Воскресенская урамына караган зур капкадан[22] керергәме яки астан[23] барып керергәме? Шул арада 16 нчы сапёрный батальонның канцеляриясенә өчдүрт мелла кереп, музыка сорадылар. Һәм озакламый музыка чыкты. Музыка чыгып «Боже, Царя храни!» дигән көйне уйнады. Мөселманнар һәркаюсы бүректән, меллалар чалмадан иде. Мәзкүр көй уйнала башлагач, бәгъзе эшләпәле мөселманнарга бүрекләрен салырга хосусый тәклифләр [әмерләр] булды. Ахырдан, мөселманнар, зур капкадан үтеп, губернатор Боярскийның фатирына бардылар. Губернатор каршы чыгып, мөселманнарга рәхмәт әйткән һәм падишаһыбыз хәзрәтләренең Кышлык сарайда[24] сөйләгән нотыгын бәян иткән (чөнкин мин якын бара алмаган идем, ишетә алмадым). Соңра губернатор Хан мәсҗеде манарасының төбенә килде. Шунда Коръәннән берничә аять укылып дога кылынды. Һәм Хисаметдин хәзрәт кулъязмасына карап, бер дога укыды. Догасы падишаһыбыз хәзрәтләренең һәм гаиләи мөхтәрәмәсенең саулыгын теләүдән һәм хәзерге хәлләрдә Русия дәүләтенең дошманнарына галәбәсен теләүдән гыйбарәт иде. Дога тәмам булгач, Кәшшаф хәзрәт Тәрҗемани[25] берничә сүз белән падишаһ хәзрәтләренең саулыгын һәм губернатор Боярскийның саулыгын теләде. Халык «Ура!» кычкырып, аннан чыгып китте. Манифестантлар шәһәр думасы турында туктап, тәкбир әйттеләр вә «Ура!» кычкырдылар. Аннан соң Воскресенская урам белән үтеп вә Николаевская[26] һәм Черек күл бакчалары арасыннан чыгып, Грузинская урам буенча тәкбир әйтә-әйтә һәм «Ура!» кычкыра-кычкыра Казанский военный округның начальнигына[27] килделәр. Шәп ягъмур яуганына карамый военный начальник халыкка

---

[18] Печән базары (Сенная) урам — хәзерге Париж коммунасы һәм аңа перпендикуляр Мәскәү урамының бер өлеше.

[19] Мәскәүский урам хәзер дә шул ук исем белән атала, әмма аның хәзерге Чернышевский урамы киселешеннән соңгы өлеше Владимирская, ә Г.Камал урамы киселешеннән соңгы өлеше Сенная (Печән базары) урамы дип аталган.

[20] Фуксовская урам — хәзерге Галиәсгар Камал урамы.

[21] Хан мәсҗеде — биредә шул ук Сөембикә манарасы турында сүз бара. Әмма археологларның ТР Президенты резиденциясе урнашкан ишегалдында Хан сарае һәм Сөембикә манарасы янәшәсендә Хан мәчете нигезен табып өйрәнүләрен дә искәртергә кирәк.

[22] Воскресенская урамына караган зур капкадан — Спас манарасы капкасыннан яки яныннан.

[23] яки астан — Тайницкая (Нургали) манарасы капкасыннан.

[24] Кышлык сарай — Санкт-Петербургтагы Зимний дворец.

[25] Кәшшаф Тәрҗемани (1877-1943) — дин һәм җәмәгать эшлеклесе, дин галиме. 1904 елдан Яңа Татар бистәсендәге 11 нче мәчет (хәзерге Кызыл Татарстан урамында булган) имам-хатибы, мәчет каршындагы мәдрәсә мөдәррисе.

[26] Николаевская площадь — хәзерге Ленин бакчасы.

каршы чыкты һәм мөселманнарга хитаб [мөрәҗәгать] кылып: «Сезнең мондый ихлас вә сәдакатегезне [тугрылыгыгызны] күреп мәмнүн булдык, Сезнең бу ышанычыгызны җиренә җиткерергә без тырышырбыз», — дип, кыска бер нотык сөйләде. Мөселманнар губернаторга мөрәҗәгать кылып, падишаһ хәзрәтләренә сәдакать телеграмма бирергә үтенделәр. Губернатор үзе дә: «Мин инде Сезнең бу хәлегезне үз күзем белән күрдем, падишаһыбыз хәзрәтләре каршында үзем шаһид булып, Сезнең сәдакатегезне күрсәтә алырмын», — дигән.

Военный начальникка да бер кәгазь тапшырылды. Манифестацияләр военный начальниктан киткәч, таралып бетми, тәкбир вә «Ура!»лар белән кычкырышып, Балык базарына[28] вә аннан мөселман ягына юнәлделәр.

Кояш. — 1914. — №468. — 22 июль.

СӘДАКАТЬ [ТУГРЫЛЫК] ТЕЛЕГРАММАСЫ

Казан мөселманнары 21ендә Ватанның сәламәтлеге өчен дога кылганының соңында, падишаһ әгъзам хәзрәтләренә ошбу сәдакать телеграммасын җибәрделәр:

«Мусульманское населеніе города Казани, возносся горячіе молитвы Всевышнему о дарованій побѣдъ славному Россійскому воинству и о здравіи Вашего Императорскаго Величества и Всего Царствующаго Дома, повергаетъ къ стопамъ Вашего Императорскаго Величества чувства безпредѣльной преданности и готовности служить Царю и Родинѣ всѣ какъ одинъ, не щадя живота своего»[29].

Тәрҗемәсе: *«Казан шәһәренең мөселманнары, шөһрәтле Русия гаскәренә мозаффарияты [өстенлек] вә Сез хәшәмәтле Император әгъзам хәзрәтләренә һәм җәмигъ ханадан шаһанәгә сәламәтлек теләп, Аллаһы Тәгаләгә дога кыйларак, гатәбәи шаһанәгезгә ниһаятьсез [чиксез] сәдакатьләрен һәм падишаһка вә Ватанга җан аямыйча, берлек илә хезмәт итәргә хазир икәнлекләрен гарыз кыйлалар».*

Йолдыз. — 1914. — №1234. — 23 июль.

ГАЛИ [БӨЕК] ТЕЛЕГРАММА

24 июльдә падишаһ хәзрәтләреннән губернатор Боярский җәнаплары исеменә ошбу гали телеграмма алынды: *«Вилаять [губерна] халкына, миңа һәм Ватанга хезмәт итәргә хазир [әзер] торганлыклары өчен рәхмәт укыйм».*

Мәзкүр телеграмма губернатор тарафыннан падишаһ хәзрәтләренә ошбу мәфһүмдә [эчтәлектә] бирелгән сәдакать телеграммасына каршы алынды: *«Сез падишаһ хәзрәтләренә түбәнчелек белән гарыз итәмен ки, һәркем тарафыннан шатлык белән кабул ителгән мобилизация көненнән бирле халыкның үтенүе буенча православный һәм башка дин руханилары тарафыннан догалар кылына һәм Казанда вә вилаятьнең һәммә җирендә хөббе Ватан[30] нөмаишләре булып тора. Ул нөмаишләргә шатлык белән байрак астына чакырылган кешеләр дә иштирәкъ итәләр [катнашалар] һәм Сез падишаһ әгъзам хәзрәтләренең гатәбәи шаһанәсенә үзләренең сәдакать хисләрен, падишаһ һәм Ватанның олуг вә бәхетле булуы өчен дошманны таптап барырга яки үлергә хазир торганлыкларын гарыз итүне үтенәләр».*

Сез, падишаһ әгъзам хәзрәтләре сараеның камергеры губернатор Пётр Боярский.

Йолдыз. — 1914. — №1237. — 27 июль.

Текстларны һәм искәрмәләрне басмага ***Ленар Гобәйдуллин*** *әзерләде.* ■

[27] Казан хәрби округының гаскәр башлыгы Антон Егорович Зальца (1843-1916) хәзерге К.Маркс урамындагы 64 йортта яшәгән. Биредә 1964 елдан ТР Дәүләт рәсем сәнгате музее урнашкан.
[28] Балык базары — хәзерге Тукай мәйданы.
[29] Текст шул чордагы график үзенчәлекләрне саклап тәкъдим ителә.
[30] Хөббе ватан — Ватанга мәхәббәт.

Халкыбызны әле дә булса миллəт буларак саклап килгəн асыл сыйфатларның берсе – үткəн тарихка һəм үз тамырларына гамьле мөнəсəбəттер, мөгаен. Хәзер Интернет заманы: туган ягының килеп чыгышы белəн кызыксынучылар, Беренче, Икенче бөтендөнья сугышында югалган, канлы репрессия елларының корбаны булган туганнарын барлаучылар төрле форумнарда фикер алыша, архивларга мөрəҗəгать итə, кыскасы, җан талəбенə буйсынып, үзенең нəсел тамырын эзли.

Айгөл Әхмәтгалиева

«ТАМЫРЛАРДАН БЕЗНЕ ТАНЫРЛАР...»

Кем мин, нəселемнең чишмə башы кайларга тоташа — əнə шул сорауларга җавап эзлəп, рухи мирасны барларга омтылганнар үзлəренең шəҗəрə агачын гына түгел, халкыбыз өлешенə тигəн фаҗигале еллар карурманын төзи кебек. Әлмəт шəһəрендə яшəүче Венера һəм Фикус Закировлар гаилəсе белəн танышкач, үзем өчен əнə шундый ачыш ясагандай булдым.

Сүземне кыл уртадан башлыйм əле... Үткəнгə борылып карасаң, кул сузымы арада сынаулардан гына торган еллар, юк, еллар түгел, гасырлар җәйрəп ята. Әллə ни еракка китмичə, егерменче йөзгə генə күз салсаң да, адəм балаларын бер сынаудан икенчесенə ташлаган, кеше язмышлары белəн курчак уены уйнаган вакыйгалар бихисап. 1814 елда туып, 1900 елда вафат булган Таһир хəзрəт һəм бүгенге көнгə кадəр аның нəсел рухын саклап килүчелəр турындагы истəлеклəрдə затлы бер гаилə тарихы гына түгел, миллəтебез язмышы да күпмедер дəрəҗəдə чагылыш таба.

Минем алдымда 1917 елда Казанда, «Бертуган Кəримовлар» типографиясендə басылган «Мең дə бер хəдис» дигəн китап. Гаҗəплəндергəне — аның бер гасырлык булуы түгел, ə титул бите почмагына пөхтəлəп язылган сүзлəр иде: *«Хəсəнгата ибн мелла Габделкаюм ибн мелла Таһир ибн мелла*



Әбелхәер ибн мелла Баязит ибн мелла Мостафа ибн мелла Бәшир. Яңа Чокалы, 1917 ел». Гарәп графикасында басылган әлеге китапның хуҗасына карата шунда ук кызыксыну, алай гына да түгел, ихтирам уятырга өлгергән нәсел агачының һәр яфрагын бармак бите белән сыпырып карыйм, еллар пәрдәсе аша чын мәгънәсендә олпат затларны күргәндәй булам. Янәшәмдә утырган Венера ханым — шушы чылбырдагы Таһир хәзрәтнең оныкчасы. Аның әнисе Шәмсенур — Таһир хәзрәт улы Габделкаюм кызы. Укымышлы, затлы, зыялы нәсел дәвамчысы. Таһир хәзрәтнең тормышы хакында беркадәр мәгълүматлар бүгенге көнгә кадәр килеп җиткән. Тагын шунысын да искәртик: югарыда санап үтелгән, китап битенә теркәлгән шәҗәрә агачының башында Сәйфулла бине Бәшир әл-Чокалый исемле ерак бабаларының торуы да билгеле. Бу хакта Риза Фәхреддиннең китабында телгә алына (Р.Фәхреддин. «Асар». — Казан, 2006, 138 бит).

Буыннан-буынга сөйләнеп килгән истәлекләр күңел сандыгында шулкадәр таслап саклангынмы, дары исе сеңгән фронт хатлары чын хәтернең үзе булып, әледән-әле чаң сугып торганмы, әллә балаларның нәсел җебе белән җитди кызыксынулары үзенекен иткәнме — ничек кенә булмасын, Закировлар гаиләсе үткәннәрнең табылган һәр төймәсен хәтер дисбесенә тезәргә алынган. Венера ханым ерак бабасы Таһир хәзрәт турындагы хатирәләрне моңарчы серле риваять итеп хәтерләгән: әнкәсе Шәмсенур — Сембер губернасының Буа өязе, Яңа Чокалы авылының Таһир мулла оныгы. Хәзрәтнең 1900 елда җәяүләп хаҗ сәфәренә кузгалуы, юлда вафат булып, Драка дигән авылда җирләнүе турында Шәмсенурга, мөгаен, әтисе Габделкаюм сөйләгән булгандыр. Шәмсенур апа сөйләгәннәр исә Венерадан уллары Айрат белән Камилгә чәчми-түкми тапшырыла. Бүгенге көннең техник мөмкинлекләреннән әллә нинди могҗизалар көтәргә мөмкин бит: иң башта Драка исемле авылларны барлау башлана. Картада шундый дүрт авыл булып, аның берсе Яңа Чокалыдан йөз чакрым ераклыкта, хаҗ юлы өстендә ята икән! Шушы кечкенә генә табыш артыннан икенчесе дә пәйда була: бүгенге көндә Ульяновск өлкәсенең Инза районына кергән Драка авылы тарихы турында компьютерда Марат Зибировның язмасы бар икән! Аның белән элемтәгә кереп, Таһир хәзрәт турында белмисезме, дигән сорашуга, бер-ике көннән җавап та алына. Чыннан да, Драка авылы зиратында иске бер каберне элек-электән изге Таһир кабере дип йөрткәннәр. Бу мәгълүматны ишетү канат өстенә канат өстәгәндәй

була. Телефон номерларын табып, әлеге авылга шылтыратуга, иң беренче тап булган 80 яшьлек Аделия апа да Венера ханымны: «Ничек белмик ди инде изге Таһир хәзрәтне, без бит намаз укыган саен башта Мөхәммәт пәйгамбәр рухына, аннан изге Таһир хәзрәт рухына дип, дога кылабыз!», — дип шаккатыра. Икеләнүләрдән тәмам котылу өчен тагын бер номерга шылтыраткач, телефонны алган Сафия Рахманкулова да: «Көненә биш тапкыр изге Таһир рухына дога кылабыз, ничек белмәскә! Туп-туры үзебезгә килегез, күпме булсагыз да сыярсыз», — дип шунда ук кунакчыллык күрсәтеп, үзләренә дәшә.

XIX нчы гасыр ахыры, XX нче йөз башы татар авыллары яшәешенә бәйле рәвештә, Таһир мулланы нык тормышлы, тирә-якта абруйлы («Соборная» дип йөртелгән төп мәчеттә указлы мулла!), хөрмәткә ия шәхес итеп күзалласак, ялгышмабыз. Аның җәй айларында муллаларны җыеп укытуы, тирә-як авылларга барып, мәчет-мәдрәсәләрнең, зиратларның торышын тикшереп кайтуы, өч хатынга өйләнүе мәгълүм. Беренче, икенче хатыннары Җамал, Һаҗәр исемле булып, алар вафатыннан соң хәзрәт Сәрбиҗамалга өйләнгән, өч хатыннан егерме биш баласы булган.

Таһир хәзрәтнең улларыннан Габдерәкыйпнең — мөәзин, Якубның Драка авылында мулла булганлыгы билгеле. Мөгаен, хаҗ сәфәренә кузгалган Таһир хәзрәт юлын улы Якуб белән дәвам итәргә тиеш булгандыр. Аны, аркасына биштәр асып, кулына таяк тотып, хаҗ сәфәренә җәяүләп киткән дип күзаллау да, Драка авылына пар ат җигеп килеп төшкән, дип гөманлау да бар. Авылга килгәч, вазифасына бәйле рәвештә, ул биредәге мәчет-мәдрәсәләрнең дә хәл-әхвәле белән танышып чыга. Зиратка килгәч, аулак, матур бер почмагына сокланып, «вафат булсам, мине шунда җирләрсез», дип, алдан күргәндәй, васыятен дә әйтеп куя. «Хаҗ юлында үлеп калсам, алып кайтып йөрмәгез, шунда гына күмәрсез», дигән сүзләрен дә истә тотып, Драка авылында вафат булган хәзрәтне үзе үк күрсәткән урында җирлиләр.

Авыл халкының бүгенге көнгә кадәр әлеге кабергә изге дип карауларының үз сәбәбе бар. Ул сәбәп анда яшәгән татарларның шанлы да, фаҗигале дә үткәненә барып тоташа.

...Явыз Иванның чукындыру сәясәте татар халкын кайларга гына сибелергә мәҗбүр итмәгән! Драка авылы да — шундый язмышка ия милләттәшләребезнең сыену урыны. Таулар, урманнар арасына качып та эзәрлекләүләрдән тиз генә котыла алмаган алар: патшаның каратель отрядлары тынгылык күрсәтмәгән. Дегет мичкәсе алып килеп, чукыныргa теләмәгәннәрнең капкасын буярга җыенганда, авыл халкы, бер булып, күтәрелеп чыга, әлеге мичкәне җиргә түгеп, кулга төшерелгәннәрнең үзләрен дегеттә ауната. Шушы вакыйгадан соң гына җәза отряларының эзе суына. Егерменче гасыр башында Дракада сигез йөздән артык хуҗалык, дүрт мәчет, ике мәдрәсә, өч су тегермәне, кирпеч заводы, пекарня һәм кибетләр булуы билгеле. Беркадәр иркен сулап яшәр өчен милләттәшләребезгә шактый сынаулар үтәргә туры килә, авыл ике тапкыр янгынга дучар була. Хаҗ сәфәренә чыккан Таһир хәзрәт биредә җирләнгәч, ни хикмәт, бәла-казалар күзгә күренеп кими. Шул сәбәпле авыл халкы хәзрәтне изге дип олылый башлый, аның кабере өстенә кызыл кирпечтән төрбә (склеп) корып куя. Хәзерге картлар үзләренең яшь чакларында ул төрбәнең ишекле, тәрәзәле булуын, эчендә өстәл, эскәмия, комган, сөлгеләр, китаплар торуын тәфсилләп сөйлиләр. Янәшәдә генә челтерәп чишмә агып торган, бирегә дога кылырга йөргәннәр, бәйрәм намазлары укыганнар. Сугыштан соңгы елларда исә, хуҗалык җитәкчеләре, төрбәнең кирпечләрен сүтеп, башка кабер таш-

Өч бертуган Әшрәф, Хәсәнгата, Мирза. 1928 ел

ларын да алып, юл төзү эшендә файдаланганнар. (Игътибар белән караганда, шулчакта салынган юл читендә бүген дә кайбер ташларда язулар күрергә мөмкин икән.) Хәзрәтнең кабере югалмасын өчен, авыл картлары анда каен агачы утырткан булганнар. Агач картаеп корыгач, берничә ел элек кенә аны кисеп алганнар.

Драка авылында яшәүчеләр изге хәзрәт турындагы хатирәне буыннан-буынга тапшырып килгәннәр, аның рухына һәрчак дога кылып торуны да балаларына, оныкларына васыять итеп калдырганнар. Әманәткә хыянәт итмичә, әлеге васыятькә гасырдан артык тугры булып яшәү нәтиҗәсендә, алар хәзрәтнең ерак оныкларына шушы олы мирасны тапшыра алганнар да инде. Әлмәттән алты йөз чакрым юл үтеп килгән Закировлар әлеге кабернең чыннан да бабалары Таһир хәзрәтнеке икәнлегенә инанып, чардуган һәм гранит таш куеп хөрмәтләгәннәр. Ул хәзер нәсел дәвамчылары өчен дә, Драка авылы халкы өчен дә югалмас билге булып тора.

***

Ата белән улны, туган белән туганны кара-каршы ярларга бастырып, бер-берсенә корал күтәрткән еллар бик күпләрнең гөрләп торган тормышын пыран-заран китерә. Илдә Совет

власте урнаштыру, канкоеш, аклар-кызыллар сугышы Таһир хәзрәт улларын да читтә калдырмый. Телдән-телгә күчеп килгән истәлекләрдән аңлашылганча, гражданнар сугышы елларында хәзрәтнең сәүдәгәр уллары Вафа һәм Гата, мөгаен, аклар ягында булганнардыр. Бертуган абыйлары Зариф исә, киресенчә, кызыллар ягында. Вафа белән Гатаны кулга алып, «Совет властен таныйсызмы?» дип, кат-кат тинтерәткәндә, комиссиядә утыручылар арасында революционер Зариф та була. «Юк, танымыйбыз!» — дигән катгый җаваптан соң энеләре басып торган идән убыла, хөкем ителүчеләр шунда төшеп китә (кешеләрне физик юк итү алымы ул елларда ук җиренә җиткереп эшләнгәндер...), моны күреп торган Зариф абыйлары исә һуштан яза.

Алдарак «Таһир хәзрәтнең өч хатыныннан 25 баласы булган», дип хәбәр иткән идек. Аларның күбесенең язмышы анык түгел. Ә менә Һаҗәрдән туган төпчек улы Габделкаюм турындагы мәгълүматларга тукталып китә алабыз. Каюмга дигән кәләшне Таһир хәзрәт Нугай авылыннан, үзенең шәкерте Сөнгатулла мулланың эшен тикшерергә баргач күзләп кайта. Бу вакытта исә Габделкаюмның, мулла буласы килмичә, эш эзләп Әстерханга киткән чагы икән. Мөгаен, Таһир хәзрәттә тәвәккәллек тә, тешләгән җирендә өзү гадәте дә, тимерне кызуында сугарга ярату да җитәрлек булгандыр: өлкән уллары Габдрахман белән Габдерәкыйпне җибәреп, тиз арада Каюмны авылга да кайтарта, Сөнгатулланың кызы Нәгыймә белән кавыштырып та куя. Муллалык эшен дәвам итәргә ризалашкан Каюмны, аерым йорт салып, башка чыгаралар. (1928 елгы саргая төшкән фотода Каюм мулланың утары сурәтләнгән. Безгә күренгән өлешендә генә дә иркен, заманына күрә шактый нык хуҗалык күзгә ташлана.)

Каюм мулла Яңа Чокалы мәдрәсәсендә малайлар, Нәгыймә остабикә исә өйдә кызлар укыткан. Алар үз балаларына да башлангыч белем биргәннәр. Үсә төшкәч, балалары Буаның «Нурия» мәдрәсәсендә, рус мәктәбендә, кызлар мәктәбендә укыганнар, дини сабак белән бергә, дөньяви белем дә алганнар. Олы уллары Хәсәнгата соңрак Казан университетының көнчыгыш телләре факультетында укый, укытучы булып эшли. Утызынчы елларның канлы геноциды — милләтнең зыялы затларын кулга алып, юк итү сәясәте аны да читләп үтми — солтангалиевчелектә, контрреволюцион оешмада торуда гаепләп, Хәсәнгатаны кулга алалар. Туганнарына аның исемен кеше алдында кычкырып әйтү дә куркыныч була, соңрак, еллар үткәч, энеләре: «Без абый турында юрган астына качып кына сөйләшә идек», — дип әрнеп телгә алачак әле...

Венера ханым 2007 елда абыйсының язмышын ачыкларга теләп, төрле архивларга мөрәҗәгать итә, ФСБның Үзәк архивыннан килгән җавапта түбәндәге мәгълүмат бирелә: «Таһиров Хәсәнгата Каюм улы, төгәлләнмәгән югары белемле, Казанның 17 нче мәктәбе укытучысы. 1929 елның 9 августында кулга алына, 1930 елның 28 августында ОГПУ Коллегиясе карары белән, 58 нче статья буенча гаепләнеп, 5 елга концлагерьга ябыла. 1932 елның 2 июлендә ОГПУ Коллегиясе карары нигезендә, өч елга сөргенгә җибәрелә. 1933 елның 28 октябрендә азат ителә.

СССР Прокуратурасының 1990 ел, 14 март карары нигезендә реабилитацияләнә.

Кулга алынганда тутырылган анкетада гаилә хәле графасында «Хатыны — Хәйруллина Рилә Хисамуровна, 29 яшь, кызы Һава, 8 яшь», дип күрсәтелгән. Х. Таһировның азат ителгәннән соңгы язмышы билгеле түгел».

Татарстанның Дәүләт архивыннан җибәрелгән архив белешмәсе һәм ТООГПУның 2 нче бүлеге карарларының күчермәләре (1929 ел) исә шул дәһшәтле елларның кайтавазы булып яңгырый. Бу урында өзекләрне документтагыча рус телендә китерү урынлырак булыр:

Нәгыймә остабикә. 1927 ел

Каюм мулланың өлкән улы Хәсәнгата Таһиров. 1920 нче еллар

«ПОСТАНОВЛЕНИЕ

1929 года, ноября 23 дня, я — уполномоченный 2-го Отделения ТООГПУ Калинин, рассмотрев следственное дело № 215 по обвинению гр-н Батыршина Хариса, Гадеева Галея (Гальгаф), Раимова Лукмана, Москова Худжа, Урманчеева Бакия, Ягудина Абдуллы, Ассановича Измаила, Еникеева, Ширина, Ягафарова, Тагирова Хасангата и Урманчеева Хадыя, обвиняемых в совершении преступления, предусмотренного 58/4, 58/8 и 58/10 ст.ст. УК...

Постановил:

Войти с ходатайством перед Прокурором ТР, путём посылки копии настоящего постановления о продлении срока следствия и содержания под стражей по отношению к названным обвиняемым на 2 недели, т.е. по 7-е декабря включительно.

Уполномоченный 2-го Отделения Калинин.

Согласен: нач. 2-го Отделения Музафаров».

«ПОСТАНОВЛЕНИЕ

1929 года, декабря «...» дня гор. Казань. Я, уполномоченный 2-го Отделения ТООГПУ Царевский, рассмотрев дело по обвинению Батыршина Хариса, Раимова Лукмана и др в совершении преступления, предусмотренного 58-4 и 58-10 ст,ст.УК,

НАШЁЛ:

что проходящий по делу в качестве обвиняемого Тагиров Хасан-Гата, войдя в связь с прибывшим из Турции от группы тюрко-татарских белых эмигрантов, руководящей борьбой против Советской власти, со специальными заданиями по контрреволюционной деятельности — Батыршиным Харисом, принял активное участие в деятельности последнего, в частности участвовал в изготовлении контрреволюционных прокламаций, разбросанных по городу с целью разжигания национальной вражды.

А по сему, на основании изложенного и руководствуясь 128 ст. УПК,

ПОСТАНОВИЛ

Тагирову Хасан-Гате предъявить обвинение… в преступлениях ст.ст. 58-4 и 58-10 УК…

Уполномоченный 2-го Отд. Царевский

Согласен: начальник 2-го Отд. ТО-ОГПУ Музафаров».

Һәр сүзеннән шом бөркелеп торган бу документлардан күренгәнчә, Хәсәнгата Таһиров белән бергә кулга алынучылар арасында абыйлы-энеле Бакый һәм Һади Урманчеевлар да була. Ни кызганыч, бу мәгълүматлар туганнар кулына беркадәр соңрак килеп ирешә шул. Татарның атаклы рәссамы Бакый ага исән чагында күрешеп сөйләшкән булсалармы?.. Бәлки ул Хәсәнгатаның ни өчен срогыннан алда азат ителүе сәбәбен дә әйткән булыр иде… Беломорканалны төзүдә катнашкан, Соловки лагерьларының бөтен «тәмен» татыган Хәсәнгата сөргеннән азат ителгәч, бер генә көнгә өйләренә сугылып чыга да Себер якларына китеп гаип була. Әнисе Нәгыймә апа аны эзләп, Томскига хат язгач, улыннан бердәнбер һәм соңгы хәбәр ала: «Әни, син мине бүтән беркайчан да эзләмә, хат та язма», диелгән сүзләр туганнарына хәзергәчә тынгылык бирми. Абыйлары ни могҗиза белән вакытыннан алда азат ителгән; әллә соң, чит телләрне яхшы белгәнгә, разведчик сыйфатында эшләргә күндергәннәрме; чик аша Әфганстан якларына чыгып киткәнме… Җанны тырмаган җавапсыз сорауларның очыкырые күренми. Мин үзем, учларны пешергән «Постановление»ларны каткат укыгач, бүгенге көн сәясәтен дә күз уңыннан үткәреп, ачы көлемсерәп куярга мәҗбүр булдым. Еллар уза — тарих кабатлана, диюләре шулкадәр хак. Хәзер дә ислам дине кануннарын алга сөргән, әхлакны пропагандалаган, адәм балаларын күз ачып уйланырга чакырган затларны төрле ярлыклар тагып эзәрлекләү дәвам итә ләбаса. Кемдер ваһһабчы, кемдер террорист, кемдер чит илдә укып, монда махсус задание белән кайткан… Бүгенге заманга да күпне күргән, күпне аңлаган артык акыллы кешеләр кирәкми. Шушы хакыйкатькә тагын бер кат төшенүдән куркыныч булып китә…

Үзәге нык булганнарны нинди генә юллар белән юк итәргә теләмәсеннәр, нәсел җебен өзми саклаучылар барыбер кала бирә. Зыялылык та, сабырлык та, гыйлемлелек тә, фидакярлек тә аларның җанында кан хәтере аша сакланып кала. Әнә бит, Каюм белән Нәгыймә гаиләсендә генә дә ун бала дөньяга килә. Дөрес, гомер озынлыгын гына төрлесенә төрлечә бирә Ходай: Хәсәнгата, Өммегөлсем, Вәлиәхмәт, Мөхәммәтвазыйх, Мәсгутне үз янына тизрәк алырга ашыга. Ә менә Шәмсенур, Фәтхелислам, Камәрия, Әшрәфелислам һәм Мирзаҗанга, сынаулы булса да, бәрәкәтле гомер язган икән, аларның нәсел дәвамчылары бүген дә милләтнең зыялы ул-кызларыннан санала.

Каюм мулла үзе 1918 елда кинәт кенә вафат була. Дөнья йөген нәзек иңсәсенә алып калган Нәгыймә остабикәгә еллар афәтен сыңар канат белән күтәрергә туры килә. Кызамык авыруы эләгеп, улы Мөхәммәтвазыйх үлеп китә. Колхозлашу елларында, мулла хатыны дип, Яңа Чокалыдагы өеннән куып чыгаралар, кече улы Мәсгутне җитәкләп урамда калган Нәгыймә апа мунчада яшәргә мәҗбүр була. Улы Фәтхелисламның хокук саклау органнарында эшләве ярдәм иткәндер, күрәсең (ул озак еллар төрле районнарда адвокат, судья булып эшли. Тукай шигырьләрен тулысынча яттан белә!), бер елдан соң остабикәгә үз өен кайтарып бирәләр.

Исән калган балаларны да төрле яклап сыный язмыш. Әшрәфелислам, Бөек Ватан сугышында немецларга әсирлеккә эләгеп, Дахау концлагере газапларын кичерә, чыкмаган җаны гына калган гәүдәсен чак йөртеп, Ватанга кайтып егыла. Кабат аякка басарга ту-

ган як туфрагы һәм яшәүгә чытырдап ябышу көч биргәндер, күрәсең: гаилә корып, алты бала үстерү бәхетенә дә ирешә ул. Сугышка кадәр Мунчали авылында укытучы булса, кайткач, Иске Чүпрәле авылында колхоз бакчасында эшли. (Кызы Наиләнең биология фәннәре кандидаты булу сере нәкъ менә шул бакча сукмакларына барып тоташмый микән әле...) Бүгенге буыннар колагына Әшрәфелислам абый кичергән газаплар бөтен ваклыгы белән килеп ирешмәгән шул. Мулла улы, халык дошманы энесе, немец әсире... Мондый тамгалар белән җан асраган кешеләр кайда да телсез-чукрак булуны хуп күргәннәр, хәтта иң якын кешеләренә дә телләре чишелмәгән андыйларның...

Каюм мулланың кызлары Камәрия белән Шәмсенур да, улы Мирзаҗан да укытучы белгечлеген сайлаган — ата-бабадан килгән игелекле һөнәр хуҗалары булган алар. Сугыштан сыңар күз, баш миендә алынмаган ядрә кыйпылчыгы һәм үзенә буйсынмаган аяклар белән кайткан Мирза абый утыз елдан артык Әлмәт шәһәренең 1 нче номерлы мәктәбен җитәкли. Ул мәктәп шәһәрдә генә түгел, республикада да дан казана, директоры күп мәртәбәләр шәһәр советы депутаты булып сайлана. 1960 елда укытучыларның беренче Бөтенсоюз съездында катнашып, Мирза абый аннан ил башлыгы Хрущёв үз кулы белән тапшырган Ленин орденын тагып кайта. Яңа гаилә корып, тормышны да өр-яңадан башларга туры килә үзенә. Балалары игелекле булып үсәләр, йөзгә кызыллык китермиләр: кызы Илсөяр Казанның атаклы СК заводының лабораториясен житәкләгән, уллары Роберт белән Марлес исә, нефтьче һөнәрен үзләштереп, үзләре эшләгән коллективта хөрмәт һәм абруй казанганнар. Яңа гаилә кору дигәнемнең сәбәбе — язмышның югалтулар белән сынавы. Сугыш гарасатын кичеп кайткан, ике аягы да йөрмәгән ир-егетне өенә күтәреп алып кергәндә, шыксыз стеналар аны кайгы белән каршылый: хатыны да, кечкенә улы да вафат икән. Олы улы Робертны куенына кысып, тешен кысып елады микән Мирзаҗан абый, әллә күз яшьләрен эчкә йотып: «Без синең алдыңда тез чүгә торганнардан түгел, язмыш!» — дип, йөрмәс тоелган аякларына күтәрелде микән... Мин аны да көчле рухлы шәхес итеп күзаллыйм. Шулай булмаса, Әлмәт халкы аның исемен бүген дә олылап хәтерендә саклар идеме? — Ул укыткан мәктәпкә мемориаль такта эленгән, мәктәп урнашкан урам М.Таһиров исемен йөртә.

Каюм кызы Шәмсенур һәм Кәрим улы Нәҗип турында иркенләбрәк тукталасым килә. Венера ханым әнкәсенең көндәлек дәфтәрләрен, әткәсенең фронттан язган хатларын кадерләп кенә өстәлгә салган мәлдә энҗе кебек тезелешкән хәрефләр, «кадерлем, бәгърем» дип атап дәшкән сүзләр күз алдыннан йөгереп үтә. Ир белән хатынның бер-берсенә ихтирамы, мәхәббәте һәм шулар белән бергә гыйлемлелек, зыялылык бөркелеп торган кәгазь битләре... Шәмсенур — Каюм мулланың икенче баласы. Кече Тархан кызлар мәктәбендә, аннан Буада укытучылар белемен күтәрү курсларында укыган, шунда ук укытучы булып калып, Буада 7 ел мәктәптә эшләгән, башкалар алдында абруй казанган зат. Аның иң белемле укытучылардан булуы, бик матур тавышка иялеге, мисыр мәкаме белән моңлы итеп Коръән укуы турында истәлекләр сакланган. Нәкъ менә Буада укытканда гомерлек мәхәббәтен — шушы мәктәпнең директоры Нәҗип Кәримовны очрата Шәмсенур. 1924 елның җәендә гаилә дә корып өлгерәләр, бер-бер артлы Зөбәйдә, Әлфия, Наилә исемле өч кыз алып кайталар. Ләкин кызларның гомерләре генә кыска булып чыга, ата белән ананы утка салып, сабый чакларында ук дөнья куялар. Соңыннан, Лалә, Илгиз, Рөстәм, Венера тугач кына, гаилә тормышы түгәрәкләнеп китә.

Нәҗип Кәримов. 1938 ел

Әшраф Таһиров. 1940 ел

Нәҗип Кәримов — Яңа Кәкерле авылы (бүгенге көндә Чүпрәле районына керә) егете. Аның әтисе Кәрим — мулла нәселеннән, гайрәтлелеге, кызу канлылыгы белән аерылып торган. Яшь чагында алты ел буе патша армиясендә кавалерист булып хезмәт иткән (шуннан алып кайткан кылычы бүген дә төп йортта саклана икән). Беренче хатыны Маһиҗамал авырып киткәч, тота да Латифә исемле кызны икенче хатынлыкка алып кайта. Ул дуамалланган вакытларда хатыннары, аның тынычланганын көтеп, ат абзарындагы печән астында качып утыра торган булганнар. Нәҗип ике әниле шундый тормышта үсә, туган авылында башлангыч белемне ала, 1911-1916 елларда Буаның «Нурия» мәдрәсәсендә укый, шул ук чорда мондагы рус-татар мәктәбен дә тәмамлый. Буада укыганда булачак драматург Фәтхи Бурнаш белән танышып, тәмам дуслашып өлгерә.

Авылдан-авылга күчеп мөгаллимлек иткән елларда Нәҗип абыйның укучылары арасында булачак шагыйрь Шәрәф Мөдәррис (Түбән Каракитә мәктәбе), булачак Советлар Союзы Герое Зариф Алимов (Яңа Кәкерле мәктәбе) кебек шәкертләр дә белем ала.

Утызынчы еллар шаукымы Нәҗипкә дә кагылып уза: укытучының абруе-даны тынгылык бирмәгәнме, аны, мулла малае дигән сылтау белән, 1930 елда кулга алалар. Әтисе Кәримнең фронтта кавалерист булып хезмәт итүе генә аны тоткынлыктан коткарырга җитәрлек сәбәп булды микән, анысы билгесез — 1931 елның язында ниндидер могҗиза белән Нәҗип төрмәдән чыгарыла. Шулай да аның өстеннән булган күзәтү 1938 елга кадәр дәвам итә. Әлегәчә гаиләсе белән әле бер, әле икенче авылда укытып йөрергә мәҗбүр булган Нәҗип Кәримов шуннан соң гына үз авылы Яңа Кәкерлегә кайтып төпләнә. Бөек Ватан сугышы башлангач, броне булуга карамастан, ул үзе теләп сугышка китә. «Мәктәптә этиләре үлгән балаларның, ирләре үлгән хатыннарның күзенә карый алмыйм» — ир-егетнең карары нык була. Суслонгер лагерьларын үтеп, Белоруссия сазлыкларына кадәр килеп җиткән Нәҗип абыйның ут эчендә үзен уты-

зынчы еллар күзәтүенә караганда күпкә иреклерәк хис итүенә шаккатырлык — Суслонгер лагереннан язган хатлары менә нәрсә сөйли: *«...Килгәннән бирле аяк киемнәрен салмый, пинжәкләрне дә чишенми коры тактага ятып йоклау да, унбиш чакрымнан такта күтәреп кайтулар да гади әйбер булып исәпләнә. Гомумән, минем өчен һәртөрле авырлык та куркыныч түгел. Чөнки кешеләр белән бергәләп күрелә. Ялгыз башка төшкән кыенлыкларны кичерү авыр. Бигрәк тә мораль изелү авыр...* (15.05.1942). *...Мин тулы ирекле, ягъни башкалар белән бертигез җаваплы...»* (25.05.1945).

Венера апада әтисенең фронттан килгән 78, әнисе Шәмсенурның исә, фронтка җибәрелеп, иясен эзләп табалмыйча, кире әйләнеп кайткан 5 хаты саклана. Дары исе сеңгән ул хатларны укыганда, янә кат-кат гаҗәпкә каласың. Минем үземне иң беренче чиратта нинди авыр, дәһшәтле чорда да почтаның шулкадәр төгәл, җаваплы эшчәнлеге сокландырды: гап-гади кәгазь битенә язылган, өчпочмаклап кына төрелгән хатлар алгы сызыктан урап, ерак төпкелдәге бер авылга кире кайтып җитсен әле! Тагы да ныграк сокландырганы — хат ияләренең бербереснә мөнәсәбәте. Һәр минутның соңгы булырга мөмкин икәнлеген әзгә генә дә башыннан чыгармаган килеш тә, Нәҗип абыйның хатларында хатынына һәм балаларына эчкерсез мәхәббәте, алар турында кайгыртуы ярылып ята. *«Умарталарны болайрак карагыз... Икмәк запасы әзерләп куярга тырышыгыз... Утын өчен каралтыларны*

файдаланыгыз...» Болары — гаилә башы буларак киңәшләр. Яшь аралаш елмаерга мәҗбүр иткәне — Нәҗип абый язган хатларны бер генә цензура да тоткарлый алмас иде, мөгаен. Чөнки аның хатлары шулкадәр осталык белән язылган — һәр сүз, һәр җөмлә астында яшеренеп яткан мәгънәне тоеп алу өчен гади күз генә җитеп бетмәс иде. *«Минем үз хәлемә килгәндә, тамак тук, өс бөтен. Аш алдыннан бисмилла әйтсәң, бәрәкәтле була, дигәнгә күрә, бисмилланы калдырганым юк. Кайчакта әгүзесен дә әйтеп куям. Укымыш ярый бит ул бер урынга. Сез әгүзе генә түгел, колхуалланы да укый торгансыздыр инде...»* (20.04.1944)

«Бу аралар аеруча тыныч үтә. Тиздән көнбатыштан көньякка күчеп киткән кошлардан сәлам алырсыз. Аларның аерым төркемнәре инде очып киттеләр...» (29.04.1944)

«Кадерлем Шәмсенур! Мин бу минут исән әле. Әгәр соңгы хатым була калса, бу аның соңгы хаты иде, диярсез. Хат яз. Кем белә, гомер була калса, бәлки кулга тияр». (10.01.1944)

«Үзем бу минут исән әле. Бу хатны алдагы сафта траншеяга аякны салындырып утырып, снарядлар тавышы астында язам. Тирә-якта снарядлар ярыла. Әтрафка осколкаларын сибәләр. Бик якын төшә башласа, траншеяга сикереп төшәм. Гади күзләр белән без аларны, алар безне күреп торалар... Үзеңнең һәм балаларның саулыгы ничек? Авыр уздырганыгызны беләм инде. Ул хакта сорашырга да куркам. Уйларга уйларым җитми. Мин сезне төшләрдә күргәнем кебек, сез дә мине күрәсезме икән?..» (20.06.1944)

«Дошман белән ике арабыз 150-200 метр. Арада зур су бар. Төнлә анда күпер салып өлгертелгән, танклар инде күптән дошман окопларына барып җиткәннәр. Самолётлар үзләренә тапшырылган бурычларны үтиләр. Озак та үтми, дошман окобыннан алынып ташлана. Дошман чигенә, авылларны яндырырга да өлгерә алмый. Авыллар бөтен һәм сәламәт килеш калалар. Газетада 2 нче Белоруссия армиясе дип укысагыз, безнең көрәшне аңларсыз». (1.07.1944)

«Ләлә белән Илгиз кирпеч утыны хәзерләделәр, дигәнсең — бик зур шатлык. Сау булсалар, дүртәү үсәләр бит... Мин үз-үземне иң куркынычлы ихтималлар алдында да аларның сиңа тиздән булышлык итә башлаулары белән юатам. Эшне сөеп эшләсеннәр, эшчән булып үссеннәр». (13.08.1944)

Нәҗип Кәримов 1944 елның 4 сентябрендә каты яралана, аны Чита шәһәре янындагы госпитальгә җибәрәләр. Биш ай буе дәвалангач, ул янә үзе хезмәт иткән частька кайта. Ул утырган поезд Яңа Кәкерледән нибары кырык чакрым ераклыктагы Борындык станциясе аша көнбатышка юнәлгәндә, кул сузымы арада калган хатынын, балаларын уйлаганда, солдат йөрәге ничекләр түздe икән?.. Ярлануы турында өйләренә хәбәр иткәндә дә ничек тә җайлап кына, үз хәлен йомшак кына итеп язарга тырыша Нәҗип:

«Мин сезгә беренче хатымда раным бил сөягендә дигән идем, ләкин алай ук түгел. Син кыз чагыңда вечерларда биегәндә, баш һәм имән бармакларыңны ачып, кулыңны ике як биленә атландырып куйган булсаң, нәкъ инде менә шул сөяк өстенә басып торалар. Беренче операциядә, карт кешегә кыскарак эчәк белән дә ярар әле дип, артык-портык эчәкләрне кисеп алдылар. Үземне һәрвакыт яхшы хис иттем». (31.10.1944)

Шәмсенур апаның иренә язган хатлары да шундый ук эчкерсезлек, самими һәм ихтирамлы хисләр белән сугарылган. Бик еракта, ут эчендә булган иреннән, ир хакын хаклап, һәрнәрсәдә киңәш сорау, өйдәге хәлләрне бәйнә-бәйнә тасвирлау, сагынуын белдереп тору... *«Кадерлем Нәҗип! Син мине сагындыңмы? Сагынган булсаң, кара, обрисовать итәм: башта кара шәл, өстә кыска юбка, синең Казаннан*

кайткан былтыргы яратып кия торган фуфайкаң, аякта озын итекләр, кулда сукно иске перчаткаларың... Бик еш бураннар булып тора. Безнең бакчада олы таулар өеп китте. Анда теге зур умарта калган иде, аны хәзер көрт күмеп китте, аңар зыян булмас микән? Әллә казып чыгарыймы икән? Шуңар җавап язар идең... Җитәр инде, хуш, бәгърем. Сагынып сәлам белән Шәмсенур» (24.12.1942)

Утны-суны кичеп, Җиңү көнен Германиядә каршылаган Нәҗип абый: *«Бу җәһәннәмнән исән калу, кайтып исән-сау гаиләңне күрү һәм алар белән тагын ун ел гомер итү — шуннан да зур бәхетнең булуы мөмкинме? Арабыздан берәү генә булса да шул бәхеткә ирешер микән?»* — дип хыялланулары турында сөйли торган була. 1945 елның 15 августында гаиләсе янына исән-имин кайтып кергән солдат тыныч тормышта нәкъ тугыз ел яшәп кала — 1954 елның 1 августында юл һәлакәте аның гомерен өзә.

«Әтинең үлеме безне тетрәндерде, ләкин аяктан ега алмады, — дип искә ала Венера апа бу хакта сүз кузгалткач. — Үзенең түземлеге һәм батырлыгы белән әни безгә үрнәк иде. Хәтерлим, безне кинодан чакырып кайтардылар. Күрәбез, әниебез алгы өйнең ишегенә аркасын терәп баскан. Безне куркытмас өчен, гаять тыныч тавыш белән: «Кайттыгызмы, балалар? Утырыгыз», — диде. Үзен тыныч тотып, әүвәлге тавыш белән ул безгә кичектереп яки үзгәртеп булмый торган хәбәрен җиткерде». Бар хәсрәтен учларына йомарлап тоткан Шәмсенур апа, соңыннан, иренең вафатыннан соң төгәл бер атна узгач, бу сабырлыкның никадәр авырлыгын түбәндәге юллар рәвешендә үз көндәлегенә язып куячак: *«...Син генә, тик син генә минем куанычым, бердәнберем, шатлыгым идең. Инде мин тормыш юлында берьялгызым калдым... Юлым ерак... Төнем караңгы. Япа-ялгыз. Барам берүзем...»*

Ана кешенең бу ялгызлыгын тормышта үз урыннарын тапкан акыллы балалары күпкә җиңеләйткәндер. Аларның әти-әни һөнәренә тугры калып, мөгаллимлек хезмәтен сайлаулары да үзенә күрә бер юаныч биргәндер: Лаләләре Самарада яшәп, укучыларны француз теленә өйрәтә, Илгизләре Яңа Кәкерледә 33 ел буе мәктәп директоры булып эшли; соңрак икенче институт бетереп, төзүче-инженер һөнәре алганчы, Рөстәм дә укытучы булып хезмәт юлын башлый; төпчек кыз Венера исә Әлмәттә мәктәптә укыта, 20 ел буе Төзүчеләр техникумында эшли, Татарстанның атказанган укытучысы дигән мактаулы исемгә лаек була.

Кеше китә — җыры кала, диләр. Таһир хәзрәтнең дә, Каюм мулланың да балалары күңеленә салып калдырган иман һәм гыйлем орлыклары буыннан-буынга тапшырылып, инде ерак оныкларга кадәр килеп җиткән. Дәвамчылар арасында кайсылары геология фәннәре, кайсылары техник фәннәр кандидаты, данлыклы нефть предприятиеләрен җитәкләүчеләр булганга күрә генә әйтүем түгел. Иман нуры булмаса, кырык эшне кырык якка ташлап, Фикус абый һәм Венера апаның уллары Айрат белән Камил, оныклары Зиннур хаҗ юлында ятып калган Таһир хәзрәт эзләрен барларга тотынырлар идеме? Өй тутырып, ерак араларны якын итеп, әби-бабай янына Луиза, Данияр, Сәет, Айдан кайтып төшәр идеме? Нәсел тарихы беркайчан югалмый, төсен һәм көчен җуймый торган, килер буыннар өчен дә олы мирас булып калырдай йомгакка тупланыр идеме?

Тормыш зилзиләләре ничек кенә талкымасын, үзәге һәм тамыры нык булганнар сыгылып төшми, чөнки ул тамырлар бик еракка — иманлы кавемгә барып тоташа. Иман булганда, хәтер дә исән, тарих та исән, кешелек үзе дә бүгенгәчә исән әле... ■

Фоторәсемнәр Венера һәм Фикус Закировларның гаилә архивыннан алынды.

1996 ел

СҮЗ ҺӘМ СУРӘТ

Разил Вәлиев

«Ул көнне без Татарстан Милли китапханәсендә Татар ПЕН-үзәгенең Габдулла Тукай иҗатына багышланган «Түгәрәк өстәл»енә җыелган идек.

Мәҗлес тәмамланганнан соң истәлек өчен фотога төшәргә булдык. Кемне кем янына куярга белмичә, хан заманыннан калган борынгы өстәлне берничә тапкыр әйләнеп чыккач, Әмирхан ага: «Әйдәгез, без — картлар алга тезелешеп утырыйк, ә бу яшь җилкенчәкләр басып торсын», — дип әйтеп куйды.

Инде менә ул көннәрдән соң егерме елга якын гомер узып та киткән.
Бу фотога утырып төшкәннәрнең инде һәммәсе берәм-берәм бакыйлыкка күчеп бетте, бары тик басып төшкәннәребез генә әле һаман җиргә нык басып йөри. Кайчак мин: «Әгәр безнең белән бергә басып төшкән булсалар, бәлки, алар да исән булырлар иде», — дип хыялга чумып алам».

1985 ел

«Бөек Җиңүгә 40 ел тулган көнне шагыйрь Нури Арсланга багышлап язган шигырьне үзенә укыган мәл. Уртада — Гомәр Бәширов.

Ил явында булсын, җыр явында —
Чигенмәдең син бер карыш та.
Син — җиңүче бүген һәр фронтта,
Йөзең нурлы, җаның Арслан».

«Чыңгыз исеменең бетмәс-төкәнмәс сихри көче, тылсымлы куәте бардыр, ахрысы. Чыңгызхан кылыч белән ярты дөнья җирен үзенә буйсындырган булса, Сез — Чыңгыз Айтматов, үз әсәрләрегез белән бөтен дөнья халыкларының күңелен яуладыгыз», — дигән идем мин ул көнне татар канлы бөек кыргыз әдибенә». ■

2006 ел

ҖӘЛИЛЧЕЛӘР ИҖАТЫ

Абдулла Алиш

....

***

Төн. Бүлмәмдә тыныч кына
утырамын ялгызым,
Күк йөзендә минем кебек ялгыз
яна йолдызым.
Ул сүнмәде таң атканчы,
Чулпан иде микәнни?
Күтеп алдым алсу кояш тәмам
чыгып җиткәнне.

Һәр көнне ул таң атканчы тора
шулай постында,
Тапшыра бу изге эшне якты
Кояш дустына.
Әй син, Чулпан, серле йолдыз,
ничек инде армыйсың?
Күп йөзләгән еллар кичеп,
ничек сүнеп калмыйсың?

Күр син мине, әгәр кичтән,
минем йокым туймаса,
Мин җуямын зиһенемне,
күзләремне кан баса.
Әйтегезче, иң бәхетле кем соң,
кем соң дөньяда?
Нигә мин дә йолдыз түгел,
йә гөнаһсыз яшь бала?

Син биектә, син иректә,
иң бәхетле син генә.
Күк йөзендә урын булса,
ал яныңа мине дә.
Тәүбә-тәүбә, тәүбә итәм,
менмимен мин биеккә,
Бар теләгем: сөйгән халкым
чыксын иде ирекккә.

Абдулла Баттал

....

ИДЕЛ

Тирә-ягы аның яшел камыш,
Җил тибрәтә ярсу Иделне!
Дулкыннарга кояш нуры белән
Сәлам хатлар язган шикелле.

Бар кайгымны онтып, мин дә элек
Кочагында йөздем Иделнең;
Минем кебек хәзер күңел ача
Күп яшьләре туган илемнең.



Муса Җәлил

....

КАТЫЙЛЬГӘ

Мин тез чүкмәм, катыйль, синең алда,
Кол итсәң дә, тоткын итсәң дә,
Кирәк икән, үләм аягүрә,
Балта белән башым киссәң дә.

Мeңен түгел, бары йөзен генә
Юк италдым синең сыңарның.
Һәм халкымнан, кайткач, шуның өчен
Мин, тезләнеп, гафу сорармын.

Ноябрь, 1943

Гайнан Кормаш

....

ДАНИЯГӘ

Их, Даниям, белмим, акылым җитми,
Су кызымы син — күлдә йөзүче?
Әллә күктән иңгән фәрештәме,
Саф мәхәббәт алып килүче?

Әйт, Даниям, әйт, кайда үстең,
Кайдан алдың гүзәл матурлык?
Диңгез кебек тирән зәңгәр күзләр...
Карар идем — җитми батырлык.

***

Данлы Казанның чал Кремле янында Муса Җәлил һәйкәле тора. Ул югарыга очар өчен канатларын җайлап куйган бөркетне хәтерләтә. Ике кулы артка каерып бәйләнгән... Менә-менә җилкәләрен киереп, чылбырларны өзәр дә һавага күтәрелеп китәр кебек.

Җәлил татар халкының намусы һәм батырлык символына әверелде. Аның исеме бөтен планетабызга мәгълүм. Ә бит ул берьялгызы булмаган үлем җәзасын ун сугышчан дусты белән иңгә-иң торып каршылаган. Аларның берсе дә дошман алдында баш имәгән, палач балтасы алдында каушап калмаган...

Менә инде ничәмә еллар бик күп галимнәр, язучылар, әдәбият сөючеләр, җәлилчеләр эзләреннән барып, серле йомгакны сүтәргә тырыша.

Шулай да, җыр һәм көрәш йомгагының очына җиттек, дип әйтә алмыйбыз әле. Һәм ул мөмкин дә түгелдер. Бу серле йомгакны алдагы буыннар да, алардан соң килүчеләр дә сүтәргә тырышачаклар, җәлилчеләрнең исемнәрен олылап, зур ихтирам белән искә алачак...

Рафаэль Мостафин

Яза алмыйм артык, акылым җитми,
Сүз табалмыйм сине мактарга.
Әгәр әйтсәң, мин синеке, диеп,
Мин әзермен алга барырга,
Карамыйча җилгә-давылга.

Зур урманнар, ерак илләр аша
Эзләр идем сине ак таңда.
Шуның өчен көям ут-ялкында —
Мәхәббәтем калды Ватанда.
Ул мәхәббәт тагын дөрләп кабынып,
Әгәр кайтсам туган якларга.

Әхмәт Симай

....

АНАМ КАБЕРЕ

Кара илдә, яман чорда туып,
Аз тордың һәм кыен яшәдең,
Их син, минем ачылмыйча шиңгән,
Тиңсез якын зәңгәр чәчәгем!

Бәлки, юкка сине кызганамын,
Бәлки, сиңа хәзер яхшырак,
Бу тормышның кара көннәреннән
Синең ләхет, бәлки, яктырак?

Ах, йөрәгем, көлгә әйләнсәң дә,
Юатмаслар синең яраңны.
Әнкәй, әнкәй! Җәфа чигәр өчен
Калдырдың ла ялгыз балаңны.

Йокла, бәгърем, артык авыр чакта
Мин килермен башың очына.
Авыру башым күкрәгемә салып,
Таянырмын кабрең ташына…

Х.Латыйф рәсемнәре

***

Абдулла Алишның (15 сентябрь, 1908—25 август, 1944) берничә шигырь дәфтәре булуы билгеле. Беренчесе турында әсирлектә аның белән бергә булган, тоткынлык-коллык газапларын Алиш белән бүлешкән Газыйм Кадыйров сөйләде. Бу шигырь Г.Кадыйров дәфтәреннән.

Абдулла Баттал (1 май, 1916—25 август, 1944) оста башкаручы-декламатор булган, бик күп шигырьләрне яттан белгән. Шуңа күрә әсирләр аның үзен дә шагыйрь дип белгән, күпләр аны абыйсы Салих Баттал белән дә бутаган. Сугыш алдыннан берничә ай редакция хезмәткәре булып эшләп алган А.Баттал үзе дә шигырь язган, шигъриятькә омтылган. Әлегә аның бер генә шигыре мәгълүм. Ул Төркиядә, Ә.Симай шигырьләре арасында табылды.

Гайнан Кормаш (14 июль, 1919—25 август, 1944) шигырен илгә Г.Фәхретдинов алып кайта. Аның раславы буенча, шигырь Г.Кормаш тарафыннан язылган һәм сөйгән кызы Даниягә багышланган.

«Анам кабере» шигыре Әхмәт Симайның (28 декабр, 1915—25 август, 1944) Төркиядә табылган кулъязмасыннан.

А.Алишка, А.Батталга, Г.Кормашка һәм Ә.Симайга нисбәтле шигырьләр һәм аларга искәрмәләр Р.Мостафинның «Җәлилчеләр» дигән китабыннан (1988) алынды.

«КАЙТУ» ТАРИХЫ: ФСБ АРХИВЫННАН БЕР ДОКУМЕНТ

Алексей Литвин, Рәис Төхфәтуллин

Бөек Ватан сугышы, батырлыклар кылу дәвере белән бергә, коточкыч фаҗига – миллионлаган кешеләрнең һәлак булу чоры да... Советлар Союзы Герое һәм Ленин премиясе лауреаты, шагыйрь Муса Җәлилнең кылган батырлыгы, тормыш юлы тарихчыларны, әдәбият белгечләрен һәм журналистларны еш кызыксындыра. Шагыйрь турында туганнарының, якыннарының, иҗатташларының, аның белән бергә фашист әсирлегендә булганнарның истәлекләре бар. 1968 елда Муса Җәлил турында «Моабит дәфтәре» исемле фильм төшерелә, ә мәшһүр татар композиторы Нәҗип Җиһанов «Җәлил» операсын яза.

Муса Җәлил һәм аның көрәштәшләре һәлак булуга бу елның август аенда 70 ел тула. 1944 елның 25 августында Берлинның Плетцензее төрмәсендә антифашистик мөселман оешмасының 11 әгъзасы үлем җәзасына хөкем ителә — башлары чабыла. 1944 елда рейх җитәкчелеге, хакимиятнең кояшы баюга таба баруын сизеп, үзенең дошманы дип санаганнар белән үч алуны активлаштыра. Бу вакытта совет гаскәриләре СССР чикләреннән чыга һәм Европаны фашизмнан азат итә башлый. Икенче фронт ачыла, Гитлер һәм аның фаворитларына һөҗүмнәр ешая. Җәлилне һәм аның көрәштәшләрен урта гасырдагы кебек ерткычларча яшерен үтерү — сүнеп баручы гитлеризмның коточкыч гамәлләренең бер өлеше була.

Заманында Җәлил һәм аның иптәшләре әсирлектә булганнары һәм «Идел-Урал» оешмасы белән хезмәттәшлек иткәннәре өчен «хыянәтче» дип саналдылар. Җәлилне аклау, аның элекке шөһрәтен кире кайтару шактый катлаулы эш булып чыга. Совет хакимиятенең хәрби әсирләргә мөнәсәбәте дә шикләнүчән була, фәкать 1990 елларда гына ялган һәм уйдырма гаепләүләр юкка чыгарыла. Фашист әсирлегеннән уңышлы гына качып котылган күп кенә хәрбиләр шунда ук совет концлагерьларына озатыла. Немец очкычын кулга төшергән һәм шуның белән фашист концлагерыннан качкан, ә аннары озак еллар Совет төрмәсендә утырган легендар очучы, якташыбыз Михаил Девятаевның язмышын искә төшерү дә җитәдер. Фәкать 1957 елда гына аңа Советлар Союзы Герое исеме бирелә һәм реабилитацияләнә. Җәлил һәм аның көрәштәшләренең язмышы турында бу вакытта бик аз гына мәгълүмат була. Өстәвенә, Берлинның инглиз секторында яшәүче тәҗрибәсез һәм намуссыз Дәүләт куркынычсызлыгы министрлыгы агентының үз җитәкчелегенә Җәлил белән Алишның Көнбатышка качканлыгы турында хәбәр иткәнлеге ачыклана, гәрчә инде алар күптән үтерелгән булса да.

1946 елда СССР Дәүләт куркынычсызлыгы министрлыгы Җәлилне эзләү эшен башлап җибәрә. Шагыйрь

Андре Тиммерманс Әминә һәм Чулпан Җәлиловалар белән. 1950 нче еллар ахыры. ТР Милли музее фондыннан

Ватанына хыянәттә һәм дошман белән хезмәттәшлектә гаепләнә. 1947 елның апрелендә әлеге оешма аны аеруча куркыныч җинаятьчеләр исемлегенә кертә. Шул ук вакытта, туган җирләренә әйләнеп кайткан хәрби әсирләр Җәлил һәм аның көрәштәшләренең батырларча һәлак булганлыгы турында сөйли. Нәкъ менә алар шагыйрьнең ватанпәрвәрлек хисләре белән тулы «Моабит дәфтәре»н алып кайта. Хәрби әсирлектә булган Нигъмәт Терегулов, Габбас Шакиров, Казыйм Миршан, Җәлил белән бергә төрмәдә утырган бельгияле Андре Тиммерманс шигырьләрне СССР һәм Татарстан Язучылар берлекләренә тапшыра. Аерым шигырьләрне Җәлилнең соңгы көннәре узган немец төрмәсе чүп савытыннан очраклы рәвештә Совет хәрбиләре табып ала. Каршылыклы дәлилләр Татарстан чекистларын хакыйкатьне ачыклар өчен актив эзләнүләргә этәрә. «Хыянәтче» мөһере тиз генә юылмый. 1949 елның маенда ТАССР Дәүләт куркынычсызлыгы министры Д.С.Токарев Мәскәүгә җибәргән чираттагы хатында Җәлил турындагы Германия резенденты мәгълүматларын төгәлләштерүне үтенә. Җавап катгый була: «Җәлилнең Көнбатышка китүе расланган, эзләү эше дәвам итә».

1952 елның июнендә генә Татарстан чексистларының «М.Җәлил үлеме турындагы фактны төгәлләштерергә» дигән үтенеченә, коллегалары бер ай үткәннән соң гына, эзләнүченең 1944 елда үтерелүе сәбәпле, аның турындагы оперативэзләү эше ябылганлыгы турында хәбәр итә. Шунда ук чекистлар Җәлилнең үзләрендә булган шигырьләрен КПСС обкомының идеология буенча секретаре С.Г.Батыевка (1911-1985) тапшыра. Ә ул, үз чиратында, әлеге шигырьләр белән ТАССР Язучылар берлеген таныштыра. Сезнең игътибарыгызга тәкъдим ителә торган, Россия Федерациясенең Татарстан Республикасы буенча ФСБ идарәсе архивыннан алынган белешмәне (Ф.1. Оп.2. Д.2.Л.15-22) 1952 елның 2 августында Токарев КПССның ТАССР обкомының беренче секретаре З.И.Моратовка җибәрә.

1953 елның 25 апрелендә «Литературная газета»ның баш мөхәррире, язучы һәм җәмәгать эшлеклесе К.М.Симонов (1915-1979) үзенең кереш сүзе белән «Моабит дәфтәре»н рус теленә тәрҗемә итеп бастыра. М.Җәлил әсәрләрен актив пропагандалауда шагыйрь белән сугышка кадәр үк таныш булган шәхесләр — язучы К.Г.Нәҗми (1901-1957) һәм әдәбият белгече Г.С.Кашшаф (1907-1975) зур гамәлләр башкара.

Игътибарыгызга тәкъдим ителә торган документ 1952 елның августында язылган, ә белгечләр өчен ул 1996 елның маенда гына ачыла. Россиядә, аеруча аның элек ябык булган архивларында, тикшерүчеләр өчен әлегә кадәр билгесез булган шактый чыганаклар саклана һәм алар белән файдалану мөмкинлегенә карап, без Ватаныбыз тарихы буенча да яңа мәгълүматлар ала алабыз.

ИПТӘШ З.И МОРАТОВКА ТАТАР ЯЗУЧЫСЫ ҖӘЛИЛ МУСА МОСТАФА УЛЫ ТУРЫНДА БЕЛЕШМӘ*

Җәлилов М.М., әдәби псевдонимы «Муса Җәлил», 1906 елда туган, Чкалов өлкәсе Мостафа авылыннан, язучы-шагыйрь һәм драматург, ВКП(б)ның әүвәлге әгъзасы, сугышка кадәр Казан шәһәрендә яшәгән.

Татарстан АССР МГБсында булган тикшерү һәм башка мәгълүматларга караганда, Җәлилов М.М., Бөек Ватан сугышы фронтында булганда, 1942 ел башында немецларга әсирлеккә төшә, аннары билгесез сәбәпләр аркасында Вустрау дигән урынга /Берлин янында/, туган иленә хыянәт юлына басучы совет хәрби әсирләре укытыла торган герман агент-пропагандистлары мәктәбенә килеп элегә.

1943 ел башында /башка мәгълүматлар буенча, язында/ Җәлилов бу мәктәптән немецлар тарафыннан оештырылган һәм сугыш дәверендә Германия Көнчыгыш министрлыгы җитәкчелеге кул астында эшләгән «Идел-Урал» Берлин антисовет оешмасы комитетына эшкә җибәрелә. Бу комитетта Җәлилов нинди дә булса аерым бер вазифаны башкармаган, ә комитет тарафыннан нәшер ителгән «Идел-Урал» газетасы редакциясе хезмәткәре булган.

1943 елның мартында Җәлилов үзенең шәхси инициативасы белән немецларга һәм «Идел-Урал» оешмасына каршы көрәш алып бару бурычын куйган яшерен антифашистик төркем оештыра башлый. Бу төркем эшчәнлегенә Җәлилов тарафыннан комитетның һәм «Идел-Урал» газетасының бер төркем хезмәткәрләре җәлеп ителә. Мәгълүм булганнарыннан:

Алишев Абдулла Бари улы, әдәби псевдонимы «А.Алиш», 1905 елгы, Татарстан АССРның Куйбышев районында туган, балалар язучысы, сугышка кадәр Казан шәһәрендә яшәгән, Кызыл Армиянең әүвәлге хәрбие;

Булатов Фуат Зыятдин улы, 1913 елгы, Башкортстан АССР Стәрлетамак районында туган, инженер-төзүче, сугышка кадәр Казан шәһәрендә яшәгән, Кызыл Армиянең әүвәлге 3нче ранг хәрби инженеры;

Симаев Әхмәт Садретдин улы, 1919 елгы, Мәскәү шәһәрендә туган, журналист, сугышка кадәр Мәскәү шәһәрендә яшәгән.

Шабаев Гариф Хафиз улы, 1907 елгы, Башкортстан АССРда туган, сугышка кадәр Ташкент шәһәрендә яшәгән, Үзбәкстан ССР Финанс халык комиссариатында ревизор булып эшләгән, Кызыл Армиянең әүвәлге хәрбие.

«Идел-Урал» газетасы хезмәткәре булуыннан файдаланып, Җәлилов немец армиясенең татар легионерлары бүлекчәләре буенча йөреп чыга һәм легионерлар арасында антифашистик пропаганда алып бара.

1943 елның август аенда Җәлилов, «Идел татарлары легионы»ның бер бүлекчәсендә антифашистик листовкалар таратканда, немецлар тарафыннан кулга алына. Аның эше белән шулай ук Алишев А., Булатов Ф., Симаев А., Шабаев Г., Ишмуров К., Газиев М., Ямалетдинов М., Хисаметдинов Р. һәм башкалар кулга алына.

Кулга алынган Ишмуров, Газиев, Ямалетдинов, Хисаметдинов һәм башкалар тиздән сак астыннан азат ителәләр, ә Җәлилов, Алишев, Симаев, Булатов, Шабаев Берлин төрмәсенә ябыла һәм соңрак немецлар тарафыннан антифашистик эшчәнлек алып барганнары өчен атып үтерелә. Бу түбәндәге мәгълүматлар белән раслана.

Кулга алынган Надиев Н.Н. 1946 елның 28 ноябрендәге сорау алу вакытында сөйли:

«...Беренче очрашудан соң ике атна узгач, ягъни 1943 елның мартын-

*Тәрҗемәдә документның стиль үзенчәлекләре сакланды.

да, мин Муса Җәлил белән икенче мәртәбә очраштым, ул миңа: «Әйдә, сөйләшәбез», — диде. Шуннан соң без парк буйлап җәяү киттек. Минем белән әңгәмә вакытында Муса Җәлил миңа әйтте: «Без тиешле урынга эләкмәдек. Мин ябык лагерьдан һәм «Идел-Урал» оешмасында катнашудан чыгарга ризалыгымны бирдем. Кешеләрдән ишеттем, син үзеңне начар тотасың. Истә тот, коммунист буларак син әле бетмәгән. Әгәр дә без кул кушырып утырсак, начар булачак. Мин, эшләргә килешсәм дә, башка эш алып барырга тиешмен, гәрчә бу гомер бәрабәренә торса да. Бу эш «Идел-Урал» идеяләренә каршы көрәшүдән гыйбарәт булачак».

1943 елның июнендә мин М.Җәлил белән яңадан очраштым. Ул миңа яшерен оешманың киңәшмәсен чакырачагын, шунда катнашучылар белән таныштырачагын хәбәр итте. Бу киңәшмә чакырылды һәм ул Берлиндагы зоологик парк ресторанында оештырылды. Анда Муса Җәлил, Алишев, Симаев, Булатов һәм мин — Надиев булдык. Бу тар даирәдәге киңәшмәдә М.Җәлил: «...Безнең эшебез канәгатьләнерлек бармый, аны кискен һәм оператив эшләүдән курыкмыйча активлаштырырга кирәк...», — дип әйтте.

...1943 елның июнендә мине «Идел-татар комитеты»на чакырдылар, анда Познань шәһәрендә мөгаллим вазифасын башкарырга тәкъдим иттеләр. Бу мәсьәлә буенча Муса Җәлил минем белән сөйләшеп, анда барырга һәм Халитов белән бергә патриотик эш җәелдерергә кушты...

...1943 елның июль уртасында Берлиннан Познань шәһәрендә Кунафин килде һәм миңа Муса Җәлил, Булатов, Шабаев, Алишев, Симаев — барлыгы унбер кешенең немецлар тарафыннан кулга алынганлыгы турында хәбәр итте...»

Кулга алынган Ишмуров К.М. 1950 елның 27 мартындагы сорау алу вакытында сөйли:

«Алишев Абдулланы мин беләм. Аның белән Ватан сугышына кадәр үк Казан шәһәрендә таныш идем. Немец әсирлегендә мин Алишевны 1942 елның көз азагында Краков /Польша/ шәһәрендә очраттым. Моннан мин, Алишев һәм башка легионерлар белән бергә, Вустрау /Германия/ шәһәренә җибәрелдем, ә аннан — Берлин шәһәренә. Шунда без Алишев белән 1943 елның җәенә кадәр фашистларның «Идел-Урал» газетасы редакциясендә эшләдек. 1943 елның җәендә Алишев немец гестапосы тарафыннан легионерлар арасында антифашистик листовкалар таратуда гаепләнеп, кулга алына. Шул ук вакытта аның белән бергә мин, Завиров Роян / «Идел-Урал» газетасының рәссамы/, Булатов Фуат һәм мин исемен, әтисенең исемен белмәгән Шабаев кулга алынды.

Моннан тыш миңа немецларның шул ук эш белән турыдан-туры легион бүлекчәләрендә кулга алулар оештыруы мәгълүм. Аерым алганда, мин легионда татар язучысы Муса Җәлил һәм җырчы Афзаловның кулга алынганын беләм.

...Миңа Муса Җәлилнең төрмәдән азат ителмәгәнлеге мәгълүм. Һичьюгы мин «Идел-Урал» редакциясендә эшләгәндә, ягъни 1945 елның мартына кадәр Җәлилнең азат ителмәгәнлеге һәм редакциядә яки комитетта күренмәгәнлеге турында беләм».

Кулга алынган Ишмаев А.Г. 1948 елның 17 сентябрендәге сорау алу вакытында сөйли:

«...Җәлилов гестапо тарафыннан 1943 елның июль азагында яки август башында татар легионында антифашистик прокламацияләр чыгарганы өчен кулга алына. Аның белән бергә 16лап кеше кулга алына.

Миңа Җәлилов һәм «Татар легионы»нан башкаларның Берлинга китерелгәнлеге һәм «Шпандау» төрмәсендә утырганнары мәгълүм. Алга таба алар белән нәрсә булгандыр, миңа мәгълүм түгел. 1945 елда мин унбер әсирнең немецлар тарафыннан атылганлыгы турында сөйләшүне ишеттем, әмма кемнәрне, мин белмим...»

Кулга алынган Уразаев Г.А. 1945 елның 26 июлендә һәм 1950 елның 26 гыйнварында булган сорау алу вакытында сөйли:

«...Дәүләтшин Тимербәк сүзләреннән аңлашылганча, Җәлилов Муса газета хезмәткәре буларак, антифашистик листовкалар һәм прокламацияләр таратканы өчен немецлар тарафыннан кулга алынган. Шунысын әйтергә тиешмен, Дәүләтшин күрсәткән шундый прокламацияләрнең берсен мин шәхсән күрдем һәм үзем укыдым. Җәлилов 1943 елның 10 августында Берлин шәһәрендә кулга алына һәм үлем җәзасына хөкем ителә...

...Муса Җәлилов, Симаев, Шабаев, Булатов, Алишев һәм тагын фамилияләрен мин хәтерләмәгән икәү, гестапо тарафыннан үлем җәзасына хөкем ителәләр. 1944 елның 27 августында аларның башлары чабыла».

Кулга алынган, 1943 елда Җәлил белән бергә Берлинда Моабит төрмәсендә утырган Мингалим Ф.М. 1949 елның 20 июлендәге сорау алу вакытында сөйли:

«...Җәлилов белән бергә Булатов, Алишев, Симаев Әхмәт кулга алынды...

Җәлиловны һәм югарыда телгә алынганнарны хөкем иттеләр һәм аларны атып үтерергә дигән карар чыгардылар, әмма, тулы бер ел диярлек, алар исән була. Гитлерга һөҗүмнән соң барлык сәяси тоткыннар да 1944 елның августында атылдылар».

Җәлилов һәм башкаларның Берлин төрмәсендә булган вакытта алар янына Галимҗан Идрисинең улы Илдар килә. Кулган алынган Газиев бу мәсьәлә буенча 1948 елның 24 ноябрендә сөйли:

«...Бервакыт Идрисинең улы Симаевка әйберләр алып килә, әмма аннан аны алмыйлар, инде ул юк, дип әйтәләр. Шулвакытта ул төрмәдә эшләгән солдаттан Симаевның кая китүе турында сораштыра башлый. Тегесе татар комитеты радиоредакциясеннән 12 кешенең, шул исәптән Симаевның да атылганлыгы турында әйтә. Алга таба солдат, аларны алып барган вакытта, аңа /немец солдатына/ таныш булмаган телдә җыр җырлауларын сөйли. Идрисинең улы да татар шагыйре, татар комитеты әгъзасы Муса Җәлилнең төрмә администрациясе биргән шигырьләрен алып килә...»

1947 елда ТАССР Совет Язучылары берлегенә СССР Тышкы эшләр министрлыгының Илчелек идарәсеннән Муса Җәлилнең патриотик эчтәлектәге шигырьләре язылган куен дәфтәре килә. Бу дәфтәр СССРның Бельгиядәге илчелегеннән алына, бирегә аны бельгияле партизаннар китергән була. Җәлиловның язмаларыннан, аның немецлар тарафыннан Германиядәге сәяси эшчәнлеге өчен үлем җәзасына хөкем ителгәнлеге күренә.

Җәлилов, Берлин шәһәре төрмәсендә булганда, Советлар Союзына үзенең тугрылыгын һәм фашист Германиясен күрә алмаганлыгын белдереп, шигырьләр язган.*

Совет язучысы Константин Симонов, Җәлиловның фашист диварлары артындагы тормышын тасвирлап, шигырьләре Бельгиядәге СССР илчелегенә аның белән бергә Берлин төрмәсендә тоткында булган кешеләр тарафыннан тапшырылган, дип искәртә һәм әйтә:

* Биредә М.Җәлилнең «Кичер, илем!» һәм «Җырларым» шигырьләреннән өзекләр китерелә.

> «Бер үк вакытта авторның тынгысыз шигъри талантына һәм Совет кешесенең авыр әсирлек һәм үлемнең үзе каршындагы батырлыгына дәлил булып торган әлеге шигырьләрнең, кыскача гына әйткәндә, тарихы шуннан гыйбарәт...»

Советлар Союзы язучыларының Генераль секретаре Александр Фадеев 1946 елда Муса Җәлилнең хатынына язган хатында хәбәр итә:

> «Совет язучыларының 1945 елда Мәскәүдә узган пленумы вакытында Кызыл Армия бүлекчәләренең берсеннән Берлиндагы Моабит төрмәсеннән килгән хат алынды. Бу хатта алар төрмәдәге төрле кәгазь чүп-чары арасыннан ниндидер китаптан ертып алынган, чиста полялары булган кәгазь табып алулары, полядa татар язучысы Муса Җәлил язмасы бар икәнлеген хәбәр итәләр. Әлеге кәгазь хат белән җибәрелгән. Полядагы Җәлил язмасы якынча түбәндәге эчтәлектә:
>
> «Мин, мәшһүр татар язучысы Муса Җәлил, әсир буларак Моабит төрмәсенә ябылдым һәм, мөгаен, тиздән атып үтереләчәкмен. Әгәр дә бу язма руслар арасыннан кемгә дә булса эләксә, алар минем иптәшләремә — Мәскәүдәге язучыларга миннән сәлам әйтсеннәр».
>
> Әлеге кәгазьне җибәргән бүлекчәдәге кызылармеецлар, язманың эчтәлеге белән танышканлыклары һәм язучы Җәлилов үлеме өчен үч алырга ант иткәнлекләре турында язганнар...»

1948 елның апрелендә Бельгиядәге СССР илчелегенә бельгияле Эмиль Мэзон килә. Ул, 1943 елда немецлар кулга алгач, үлем җәзасына хөкем ителгән совет язучысы Алишев белән тотык булганлыгы һәм А.Алишевның Моабит төрмәсендә язган хатын туганнарына тапшырганлыгы турында сөйли. Бу хатта Алишев яза:

> «1943 елның августында татар әсирләре, татар легионерлары арасында листовкалар таратуда гаепләнеп, кулга алындым. Минем белән Муса Җәлил, Гариф Шабаев, Сәйфелмөлеков, Фуат Булатов, Әхмәт Симаев кулга алынды. Килдем, күрәштем һәм киттем. Безнең инде шулай, күрәсең, язмыш. Без соңгы сулышыбызга кадәр үзебезнең халкыбызга тугры булып калабыз».

Немец фашистлары тарафыннан Җәлилов М., Алишев А., Булатов Ф., Симаев Ә. һәм Шабаев Г.ларның кулга алыну һәм атылулары турында югарыда сөйләгәннәр, кулга алынган Забиров Р.Р., Гыйләҗиев К.Г., Вафин Р.В., Фатихов Г.Ф. һәм башкаларның күрсәтмәләре белән дә дәлилләнә.

Шуны әйтергә кирәк, 1948 елда түбәндәге мәгълүмат алына: янәсе Җәлилов фашист Германиясе капитуляцияләнү алдыннан Берлинда булган, шуннан Көнбатышка киткән. Әмма, җентекле тикшерү вакытында Берлинның инглиз секторында яшәгән бәндә бу мәгълүматның бердәнбер чыганагы булып торганлыгы ачыкланды. Бу аз гына да ышаныч яулый алмый һәм мораль яктан таркалган сәрхуш кебек сыйфатлана. Әйтергә кирәк, аның Җәлилов турындагы хәбәрләре тулысынча каршылыклы һәм шуның белән алар дөреслеккә туры да килми, шикшөбһә булырга мөмкин дә түгел.

Татарстан АССР Дәүләт куркынычсызлыгы министры,
генерал-майор

/Д.Токарев/

2 август 1952 ел
№ 1/769
Казан шәһәре.

Кереш мәкалә һәм чыганакны русчадан
***Ленар Гобәйдуллин** тәрҗемә итте.* ■

КЕМ УЛ – АБДУЛЛА БАТТАЛ?!

Фәрит Баттал

Мин – Фәрит, шагыйрь Муса Җәлилнең фашистлар әсирлегендәге көрәштәше Абдулла Батталның кардәше. Туганнарыбыз, Абдулла абыйны иң яхшы белүче – минем әти Фуат, дигән фикер белән килешә иделәр, чөнки ул аның белән авылда бүтәннәргә караганда озаграк яшәгән. Әтинең сүзләренә башка туганнарның, авылдашларның хатирәләрен дә өстәсәк, шундый портрет килеп чыга:

Абдулла Баттал (Габдулла Вазыйх улы Баттал) 1916 елның 1 маенда элекке Казан губернасы Спас өязе (хәзерге Татарстанның Алексеевск районы) Зур Тигәнәле авылында урта хәлле гаиләдә туган. Ун баладан исән калган алтының бишенчесе булган. Ул тугач та әниләре авырган һәм Габдулланы күрше хатыннары имезгән. Аксыл йөзле, сипкелле егет булып үскән. Сипкелне бетерү өчен шундый ысул бар дигәнне кемнәндер ишетеп, чыпчык эзләреннән алган кар белән битен сөртеп тә караган. Җиде классլы авыл мәктәбеннән соң Чистайда урта мәктәпне тәмамлый; колхозда, аннары әтисе кебек Донбасс шахтасында эшләп ала. Уен-көлкеле, җор телле, шаян кеше булган. Балаларны үлеп яраткан. Аның тирәсендә гел бала-чага чуала, ул аларны ияртеп урманга менә, шигырь юлларына салып агачлар, үләннәр, чәчәкләр турында кызык әкиятләр сөйли. Ул киң холыклы, бик юмарт, ярдәмчел; кешеләр белән бик тиз аралашучан була. Зур Тигәнәлегә шәһәр-район җиреннән кем генә килмәсен, аның белән башта Габдулла танышкан. Таныша да, өйгә дә чакыра. Әнисе тиргәнә, син алдан кисәтер идең, улым, мин табын-мазар хәстәрләп куяр идем, болай кунактан оят бит, ди.

Тора-бара егет, Салих абыйсыннан (Салих Баттал – күренекле шагыйрь, очучы) үрнәк алып, хәрби хезмәткә китү турында хыяллана башлый. Салихның очучы фуражкасын, анна-

1930 ел

ры аның зәңгәр йолдызлы будёновкасын киеп урамга чыкканда, Габдулла һәрдаим кызларның игътибар үзәгенә эләгә. Шул будёновкада ул колхозчылар белән 1930 елда югары уңыш җыеп алган өчен бирелгән күчмә байрак астында карточкага төшкән. Бу фотографиядән зурайтып алынган Габдулла рәсеме классик булып китте — шул рәвештә итеп аны төрле плакатларда һәм, әлбәттә, Казан Кремле янындагы барельефта да күреп була. (Габдуллага бертуган Ләйлибәдәр апасының уллары искиткеч охшаган булып, шулардан берсе — Нариман — рәссам Искәндәр Рафиковның «Җәлилчеләр» исемле картинасына күчергеч булып торган) Салих абыйның улы Виктор: «Габдулланың «армиядә миңа ат белән кылыч бирәчәкләр», дигән сүзләре исемдә калды», — дигән иде.

Үскәч, Габдулла Казандагы Татар-башкорт хәрби мәктәбенә укырга керә. Ләкин бер еллап укыгач, бәхетсезлеккә юлыга: пар ат җигелгән арбага утырып складтан азык-төлек алырга барганда, Болакка җитәрәк, атлар дулап китә дә, Габдулла егылып төшә һәм аягын сындыра. Аны госпитальгә салалар, ә терелгәч, янә тикшереп, хәрби хезмәткә яраксыз дип табалар. Шуннан аның бер аягы аз-маз аксый торган булып кала. Тик Габдулла төшенкелеккә бирелми. Ул кире Зур Тигәнәлегә кайтып, клуб мөдире булып эшкә урнаша. Нинди генә кичәләр, нинди генә уеннар оештырмый! Ул клубта эшләгән елларда авыл гөр килеп яшәгән. Атна саен концерт, спектакль куела, һәркайсында Габдулла йә алып баручы, йә нәфис сүз остасы, йә артист булып чыга. Баянда да ул оста уйнаган. Хәтта Батталлар гаиләсе концерты да куелган: барысы җырлаган, биегән, Салих дәртләнеп шигырь сөйләгән. Габдулла үзе дә лирик шигырьләр яза (район газетасында күп басылган алар), тәнкыйть мәкаләләренә дә оста. Авылда берәр җитешсезлек, кимчелек күрсә, «утка бастыра», ә мәкалә астына «Г.Баттал» дип имза куя. Галимҗан абые: «Син язасың да, миңа бәйләнәләр», — дип ачулана. Шуннан Габдулла исемен «Абдулла» дип үзгәртә һәм бу исеме астында танылып кала да.

Аның кулдан төпләп ясаган җыентык дәфтәрләре шактый була. Минем эти: «Габдулла исән калса, шигърияттә,

Вазыйх Баттал

Нурдидә Баттал

бәлки, Салихны да узып киткән булыр иде», — дия иде. Кызганыч, дин күзлегеннән карап, әнисе шул дәфтәрләрне яндырып бетергән булса кирәк. Бервакыт Габдулланы Казанга радиодан чыгыш ясарга җибәрәләр, авыл җитәкчеләрен үтереп мактаган текст тоттыралар. Ул заманда тавышны магнит тасмасына язу әле юк, «тере эфир» гына, шуңа күрә күп кеше микрофон алдында югалып кала. Хәтта үз шигырьләрен яттан белгән Хәсән Туфан да шуларны китаптан укып сөйләгән. Ә микрофон алдына беренче баскан Габдулла Туфан шигырьләрен яттан, чатнатып укып биргән дә, аннары авыл җитәкчеләрен үз сүзләре белән тәнкыйтьләгән — ялганны яратмый, куштанлыкны сөймәгән. Күпмедер вакыттан соң аңа район газетасында корреспондент урынын тәкъдим итәләр. Шулай итеп, Бөек Ватан сугышы алдыннан Габдулла берничә ай редакция хезмәткәре булып эшләп алган. Үзе теләп, Фин сугышына китмәкче булган, алмаганнар. Сизенгән төсле: «Гомерем кыска булыр», — дия торган булган ул. Казанга килгәндә Габдулла Ләйләбәдәр апасында тукталган. Әсирлектә дә үзенең «үлем карточкасы»н тутырганда, тору урыны дип ул — Казан, ә ата-анасы дип, Ләйлибәдәрне һәм аның ире Гарифны атаган. Шул рәвешле ул әнисенә кайгысын җиңеләйтер өчен эшләгән, дип ишеттем. Әтиләре, минем бабам Мөхәммәтвазыйх, 1940 елда вафат була.

1938 елда Габдулла үз авылыннан Хәдичә исемле кызга өйләнә. Рәйсә атлы кыз балалары да туган. Тик сабый ике яше тулыр-тулмас вафат була. Сугыштан соң әти, авылга бер кайтканда, Хәдичәне тегермәндә очраткан. Булмады безнең бәхетләр, дип елаган Хәдичә. Соңыннан, Габдулланың әнисеннән рөхсәт сорап, ул бүтән кешегә кияүгә чыга. Анысының ике баласы була, шуннан тагын җиде балалары туа. Соңгы елларында Хәдичә, шуларда торып, 2003 елда үлгән.

Бөек Ватан сугышы башлануга Абдулла фронтка китәргә ашкына һәм бу максатына ирешә дә. Аның сугышкан, әсирлеккә эләккән урыннары безгә билгеле түгел. Моны аның яшерен оешмадагы көрәштәше Фәрит абый Солтанбәков та белмәгән (мин аның белән танышып өлгергән идем). «Ул

турыда Абдулладан сорашканым булмады», — дип җавап бирде ул миңа. Әсирлектә Абдулла абый Гайнан Кормаш җитәкләгән яшерен төркемгә керә, элемтәче вазифасын үти. Кормаш, Хәсәнов, Солтанбәков белән фашистларга каршы листовкалар тарата. Хыянәтче аркасында төркемнәре фаш ителгәч, 1943 елның 10 нчы августыннан башлап, аның бөтен әгъзалары кулга алына, ә 1944 елның 25 августында Абдулла Баттал ун иптәше белән бергә гильотинада, сигезенче булып, җәзалап үтерелә.

***

Сугыштан соң, «җәлилчеләр» дип аталганнары турында нинди генә хәбәр кайтмасын, аларның, шул исәптән Габдулланың да, сатылганына бер туганыбыз да ышанмаган. Югыйсә, адәм баласы гайбәткә тиз ышана. Яшерен заводларның берсендә мастер булып эшләгән эти үзе турында: «Менә, халык дошманының энесе», — дигән авыр сүзләрне гел ишетеп торган. Аны дәүләт бүләгенә тәкъдим ителгәннәр исемлегеннән дә сызып атып барганнар. Вакыты белән бу хәл бераз җиңеләйсә дә, эти, эшләгән цехтан китеп, шул ук заводның конструкторлык бюросына күчкән. 1966 елда Муса Җәлилгә һәйкәл ачу да халыкта йөргән фикерне әллә ни үзгәртмәде — кемнеңдер хыянәтче булган дигәненә ышану, намуслы булган дигәненә караганда тизрәк ябыша бит. Абыйсын хыянәтче дип һаман телгә алу этинең дә холкын боза барды һәм, минемчә, ахыр чиктә сәламәтлеген какшатты. Җитмәсә, Брежнев заманында хәрби билетларны алмаштыру кампаниясе нәтиҗәсендә, этинең сугышта катнашканы турында язуы да юкка чыккан. Шул сәбәпле, ул тиешле таныклыгын да ала алмаган. Менә шулай: хәрби бүләкләре — орден-медальләре дә бар, ә таныклыгы юк — ялган исем белән йөрүче кебек. Шуңа түзә алмыйча, пенсиягә чыкканда, эти берьюлы партиядән дә чыкты. Соңыннан, бик зур көч куеп, аның сугышта катнашканлык статусын торгыза алгач, минем кулымнан яңа таныклыкны эти дәвалап булмый торган авыру хәлендә алды, шунда кул куярга да аның хәле җитмәде. Бер ай ярым да узмыйча, ул дөнья куйды...

Бервакыт эти: «Абдулланың әсирлектә һәлак булуы хәтта яхшыга булды. Сугыштан кайткан булса, аны Сталин лагерьларында үтергән булырлар иде», — диде.

...1990 елның мартында безгә аноним хат килеп төште. 1969 елда Төркиядә үлгән тарихчы Габделбари Баттал турында «Татарстан яшьләре» газетасындагы мәкалә кырыена хаталы, ямьсез язу белән тутырылган язма ята иде:

Яшерен заводларның берсендә мастер булып эшләгән эти үзе турында: «Менә, халык дошманының энесе», – дигән авыр сүзләрне гел ишетеп торган.

«...Баталов, вы врёте, что ваш брат казнён — он жив, он фашист, предатель... Ты хуже абдуллы *(исем кечкенә хәрефтән — Ф.Б.)*, вас судить надо...» — һ.б. Почерк һәм хаталар буенча анонимны таныдык: унбиш ел элек бу кеше безнең туганыбыз булып китте, һәм аның улы уңайсызланып булса да, безнең фаш итүебезне таныды.

Мәгълүм ки, 1994 елда Кормаш төркеме әгъзаларын җәзалап үтерүгә илле ел тулу уңаеннан Җәлил һәйкәле артында аларга барельефлар ачылды. 1999 елда Абдулла Батталның туган авылында авыл советы карары нигезендә, урамнарның берсенә аның исеме бирелде (Салих Баттал, Муса Җәлил урамнары да бар). 2003 елның 8 маенда авылда тантаналы рәвештә Туган якны өйрәнү музееның яңа бинасы ачылды, шуның бер бүлмәсе Батталларга багышланган. Язучы Туфан

Батталлар гаиләсе. 1949 ел

Миңнуллин тырышлыгы белән 1990 елның 5 маенда СССР президенты Михаил Горбачёвның «җәлилчеләр»не үлгәннән соң I дәрәҗәдәге Бөек Ватан сугышы ордены белән бүләкләү турында Указы да чыкты. Бу хәбәрне ишетү безнең өчен бәйрәм кебек булды. Бигрәк тә — әти өчен! Бу Указны үтәп, ел ярымнан Татарстанның беренче президенты Минтимер Шәймиев геройларның туганнарына орденнар тапшырды. Ә 2005 елда алар «Бөек Җиңү» орденына да лаек булдылар.

***

Хәзер инде берничә моңсу, әмма дә үзем өчен һич тә бәхәссез булган фикерләрем белән дә уртаклашасым килә. Җәлилнең көрәштәшләре, бөтенесе дә диярлек, аның күләгәсендә кала бирәләр. Аларны кайвакыт аерым, кайвакыт «иптәшләре» дип, Җәлилнең йә чираттагы туган көнендә, йә җәзалап үтерелгән көннәрендә генә телгә алалар. 2006 елның 23 августында Җәлилнең фатир-музеенда язучы Рафаэль Мостафин сөйләгәнчә, язучыларның «җәлилче»ләргә Советлар Союзы Герое исемен бирү үтенечен Мәскәүдә берничә мәртәбә кире каккач, исемнәрен шәһәр урамнарына, торак пунктларына биреп булса да мәңгеләштерү карар ителгән иде. Чынбарлыкта бу карар да фәкать Абдулла Алишка карата гына үтәлгән. Сүз уңаеннан, «җәлилчеләр»нең исемнәрен бирү-бирмәү аларның элекке профессияләренә карап хәл ителгән, дигән фикер туа. Язучы Җәлил белән Алиш исемнәрен мәңгеләштерү — бик тә урынлы, ләкин аларның иптәшләре — элекке укытучы, Госстрах инспекторы, колхозчы-клуб мөдире, сатучы, төзүче, бухгалтер һәм хәрби хезмәткәрләр — әсирлектә алардан һич тә ким булмаган батырлык күрсәткәннәр ләбаса.

Җәлилне, үлгәннән соң, Герой итеп, Ленин ордены һәм «Алтын Йолдыз» медале белән 1956 елда бүләкләгәннәр, ә иптәшләре, Бөек Ватан сугышы орденына да 1990 елда гына — Җәлил бүләкләнгәннән соң 34 ел узгач кына лаек булдылар. Җәлилгә һәйкәлне 1966 елда ачканнар, иптәшләренә барельефларны 1994 елда — 28 елдан соң. Урамнар чираты кайчан җитәр икән? Әллә Җәлил исеме кушылган урамнар саны иптәшләренең исемнәре булмавын тулысынча аклыймы?!

2007 елның 17 февралендә «Яңа гасыр» телеканалында барган «Хәерле

иртә» тапшыруында профессор Хатыйп Миңнегулов, Җәлилнең тууына 101 ел тулуга багышлап, болай дип әйтте (язма буенча сүзгә-сүз китерәм): *«Йөзьеллыгы узды, аннан тыш — берьеллык. Әле менә шушыннан соң да шактый чаралар уздырылыр, ләкин әле Муса Җәлилне, үзенең эшчәнлегенә, үзенең иҗатына югары лаеклы дәрәҗәдә күтәрә алганыбыз юк. Ә бит Муса Җәлилнең менә шундый эшчәнлеге, фидакярлеге шулкадәр зур, һәм аны инде, теге, татарның бер символы итү кирәк, бу һич тә инде арттыру түгел».* Ә мин бу эш күптән арттырып үтәлгән, дип уйлап йөри идем әле... Бер-беренә тиңнәрдән фәкать берсен генә нык «аллалаштыру» аңа ихтирамны ныгытмый бит. Казандагы Бөек Ватан сугышы музей-мемориалы мөдире Михаил Черепановның «Зачем живым Долина смерти?» китабында язганы белән тулаем килешәм: «Такие «приписки» только компрометируют Джалиля» («В чём заключался подвиг Джалиля?» мәкаләсе, 181 бит).

Шул ук елда — 25 августта, Кремль янындагы чираттагы митингта Татарстан мәдәният министры урынбасары Айрат Жаббаров: *«Җәлил — татар халкының горурлыгы, какшамас милли рух символы»,* — диде. Туфан Миңнуллин: *«Җәлилне без конкрет язучы, герой буларак кенә искә алмыйбыз, татар халкының символы буларак, батырлык үрнәге буларак искә алабыз...»* Шагыйрь Ренат Харисның чыгышы бүтәннәрдән конкрет булуы белән аерылып торды: *«Мәрмәргә, гранитка, бронзага әйләнгән кешеләрнең исемнәре, һичшиксез, энциклопедияләрдә булырга тиеш иде, әйе бит? Әмма ләкин сез безнең энциклопедияләрне, энциклопедик сүзлекләрне актарып карасагыз, Сәлим Бохаров турында да, Зиннәт Хәсәнов турында да, Абдулла Батталов турында да, хәтта Гайнан Кормаш турында да аерым мәкаләләр таба алмассыз... Аларның исемнәрен, һичшиксез, энциклопедияләрдә, китап битләрендә ныграк һәм тирәнрәк калдырырга кирәк».* Бу фикер күптән ап-ачык иде, ләкин аның мондагы аз санлы җәмәгатьчелек алдында булса да әйтелүе күңелемә хуш килде.

«Моабит дәфтәре» исемле нәфис фильм (заманында «Вузовец» кинотеатрында барды) туганнарыбыздан беркемгә дә ошамады. Алар фикеренчә, фильмда Җәлилнең көрәштәшләре турында рәтләп әйтелмәгән, Абдулланы уйнаган актёр да аның үзенә ни төскыяфәте, ни холык-фигыле белән туры килми.

Кормашның яшерен төркемен фаш итүдә Батталның гаепле икәнлегенә нинди дәлилләр бар? Имеш, ул провокаторны танымыйча, аңа төркемнәре турында сөйләгән... Иптәшләре аны ышанучан кеше итеп сыйфатлаганнар, дигән сүзгә мин, мәсәлән, документларга нигезләнгән «Люди и маски» исемле китаптан өзек китерә алам (Карчевский Ю., Лёшкин Н., Уфа, 1982): *«Можно документально подтвердить, что и Курмаш вёл откровенные разговоры с Ямалутдиновым, да и с Исламгуловым и Тинчуриным тоже (фашист агентлары — Ф.Б.)»* (102 бит); *«Пока Джалиль готовил на кухне ужин, Мурзагулов знакомился с немногочисленной библиотекой... Между страницами 46-47 был заложен листок, исписанный по-татарски... Это было «Обращение к солдатам легиона». Оно призывало принять участие в дне «Х», повернуть оружие против гитлеровцев...»* (104-

Җәлилнең көрәштәшләре, бөтенесе дә диярлек, аның күләгәсендә кала бирәләр. Аларны кайвакыт аерым, кайвакыт «иптәшләре» дип, Җәлилнең йә чираттагы туган көнендә, йә җәзалап үтерелгән көннәрендә генә телгә алалар.

105 бит); *В одной из «Моабитских тетрадей» Муса Джалиль указал, что предал подполье Ямалутдинов… Но он знал лишь нескольких человек и только в Едлино. Тюремному же заключению подверглось сразу несколько десятков — одновременно в Едлино, Берлине и на Украине»* (109 бит).

2006 елда Рафаэль Мостафинның «Муса Җәлил турында истәлекләр» исемле китабы чыкты — бераз тулыландырылган булса да, чынбарлыкта Гази Кашшафның 1964 елда чыккан «Муса турында истәлекләре»ннән ерак китмәгән». Ләкин яңа автор монда чыннан да кызык нәрсәне керткән — подпольщик Михаил Иконниковтан алган ике хатның өзекләрен шундый кереш сүз белән биргән: *«Әлегәчә басылмаган шул ике хаттан өзекләр китерәм. Сүз, нигездә, Әхмәт Симай турында бара. Ләкин бу хатлар Җәлил һәм башка җәлилчеләр кичергән хәлләрне тулырак күзаллауга ярдәм итәләр» (218 бит — Ф.Б.).* Иконниковның бер хатыннан шушы өзек мәгънәле: *«Рабендорф лагерена ике качкынны тотып кайтаргач, Симаевка тагын бер борчу өстәлде: баш күтәрергә әзерләнгәндә генә, яшерен оешма кешеләре, саклану чараларын онытып, кирәкмәгән кешеләргә ышаныч белдереп, үзләрен сиздерделәр… Алар әле күп нәрсәне судтан соң гына аңлап алалар. Берберсенең хатасын күрәләр, ләкин үпкәләү юк. …Муса чамасыз ышанучан иде, хәер, төркемдә бер ул гына түгел, ышанучанлык аркасында башкалар да интегә. Чөнки совет кешесе арасында ниндидер сатлык җаннар бардыр, дип берәүнең дә башына килми. Бу — Җәлилнең төп ялгышы, ди Симаев. Шушы чамасыз ышаныч аркасында Җәлилнең листовкаларны кая яшергәнлеген дә беләләр…»* (223 бит). Әлбәттә, «ышанучанлык аркасында интегү»челәр арасында Абдулла абыйның да булуын мин фараз итә алам, тик нигә «башкалар»да «Баттал»га әверелгәннәр?!

Ниһаять, Фәрит Солтанбәков үз китабында болай яза: *«50 нче елларның урталарында һәм ахырларында матбугат битләрендә җәлилче каһарманнар турында истәлек-язмалар күренә башлагач, «Идел-Урал» легионында, Едлинода бергә булган иптәшләребезнең кайсысыдыр тарафыннан саксыз рәвештә: «Абдулла Батталовның, үзе дә сизмичә, сатлык җан Ямалетдиновка артык ышануы, аны тизрәк үз ягыбызга аударырга ярдәм теләве, фашистларга яшерен оешма эзенә төшәргә ярдәм итте кебек», — дигән ялгыш фикер әйтелә. Аннары шул фикер Җәлил һәм җәлилче каһарманнарның тормыш юлын өйрәнүче мөхтәрәм язучыларыбызның һәм тарихчы галимнәребезнең китапларына да кереп китте. Мин дә моңа, ничектер, үз вакытында тиешле игътибар бирмәгәнмен — шуңа бик үкенәм хәзер. …Төннәр буе йокламыйча, Баттал турында еш уйланам — аңа карата әйтелгән хаксыз сүзләрне тәмам юкка чыгарып, намуслы, пакь исемен сөйгән халкыма кайтарырга телим. …Соңыннан, гестапочылар тарафыннан кулга алынгач та, фашистлар өчен «теш үтмәслек чикләвек» булды ул»* (67-68 бит).

Ахыры киләсе санда ■

ХАТЛАР ЯЗДЫМ УТЫРЫП

Хәдичә Җәлилованың* Афзал Шамовка** язган хаты

«Исәнмесез, Афзал абый!

Күңелне йомшата торган җылы хатыгыз өчен бик зур рәхмәт. Сезгә үпкәләргә һич тә хакым юк. Сезнең эшле булуыгызны, вакытыгызның әз икәнен бик яхшы беләм, шуңа күрә хатлар язганда сездән җавап алырмын, дип өмет тә итмәдем.

Путёвка турында. Зәйнәпкә*** әйттем, ул бик шатланды. Ул хәзер бик авырый, докторлар торырга кушмыйлар шуңа күрә. «Нинди генә айда путёвка җибәрсәләр дә барам», — ди. Сез анда яхшырак айга туры килсен дип мәшәкатьләнмәгез. Аның кызын мин алып калам. Шулай булгач,

Муса әнисе Рәхимә (1877-1928) һәм сеңлесе Хәдичә белән

Муса Җәлил – туганнары арасында

ул майда да китә ала. Тик беренче сентябрьгә хәтле генә булса иде — баласы мәктәпкә киткәнче. Үзем исән-сау. Белмим, абый үзе Оренбурда вдруг популярный булып киттеме, әллә просто «компания»ме, бу айларда абый турында истәлекләр белән бик күп йөрергә туры килде. Йөрү генә җитми. Өйгә дә килеп азаплыйлар. Бөтен ял көннәрем шуңа үтә. Элек Зәйнәп тә йөри иде, хәзер йөри алмагач, миңа гына йөрергә туры килә. Мин үзем аннан арып-талып бетсәм дә, Муса өчен шатланам.

Шәйхи абый**** Мусаның 55 яшьлек юбилее турында язылган Казан гәзитләрен безгә җибәргән иде, шатланып укыдык.

Ярый, Афзал абый. Хәзергә хушсау булыгыз. Сезгә Зәйнәптән бик күп сәлам. Бездән иптәшегезгә һәм балаларыгызга күп сәлам.

Зур ихтирам белән, Хәдичә Җәлил.
19 март, 1961 ел.

P.S. Бу хәрефләр белән әле бик начар язам, ошибкалар күптер, гафу итегез инде мине — шулхәтле надан кешене.*****
(Имза урынына «Х» хәрефе генә куелган. — Л.Л.)»

*Хатны журналга әзерләүче һәм искәрмәләр язучы — **Л.Леров***

*Хәдичә Мостафа кызы Җәлилова (20.09.1918-3.11.2000) — герой-шагыйрь Муса Җәлилнең бертуган сеңлесе. 1942 елның маенда, үзе теләп, Кызыл Армия сафларына баса. Горький (Түбән Новгород — Нижгар) шәһәрендә элемтәчелеккә укый, Брянск фронтындагы сугышларда катнаша.1943 елда немецлар листовкасын укыган өчен кулга алына һәм «халык дошманы» дип хөкемгә тартыла. 10 ел Түбән Тагил төрмәсендә утыра. 1952 елда ирекккә чыгарыла һәм реабилитацияләнә. Оренбургта метеоролог булып эшли. Абыйсы М.Җәлил турында истәлек китабы (1969) авторы. 1996 елның 22 июнендә да Оренбургта (Постников урамы) М.Җәлилгә һәйкәл ачыла. Әлеге һәйкәлне (скульптор Кадим Җәмитов) ачу тантанасында, кадерле кунак буларак, Х.Җәлилова да катнаша.
**Афзал Шамов (4.03.1901-19.01.1990) — күренекле прозаик, публицист, тәрҗемәче, җәмәгать эшлеклесе. 1958-1961 елларда Татарстан Язучылар союзы идарәсе рәисе.
***Зәйнәп Мостафа кызы Җәлилова (1908-1965) — М.Җәлилнең бертуган сеңлесе.
****Шәйхи Маннур (15.01.1905-10.06.1980) — күренекле шагыйрь, прозаик. М.Җәлил турындагы роман (1964) авторы.
*****Хаттагы орфографик хаталар төзәтелеп бирелде.

Әсәр филология фәннәре докторы, профессор **РИФКАТЬ ӘХМӘТҖАНОВ**ның шигъри тәрҗемәсендә бирелә.

КУТАДГУ БИЛИК*

(Котайткыч белем)

Йосыф Баласагуни
(Йосыф Хасс-Хаҗиб)

Йәзәкләр артыннан җитешсә тоткак,
Һөҗүмгә әзерлек күрелә шулчак.

Чирүне тезергә юртуглар[20] китәр:
Һичкем алда-артта калмасын читтә.

Юртуглар саф тезсен төшенеп, белеп,
Ир-ат сакта торсын бик уяу, берүк.

Юрыкны[21] күзәтсен әләмче ирләр:
Читкә китмәсеннәр иң төп яугирләр.

Әсирләр тотылсын бергә җыелып,
Бер якка китәргә катган тыелып.

Гафил булмасын ир, уяу булсын гел,
Югыйсә баскынчы бик ерак түгел:

Сугышка кергәндә йәзәкне алсын,
Әсирләргә әзер булсын тур[1], аш-су.

Чирү әзерләнгәч, «тел алу» кирәк,
Дошман гаскәр хәлен чамалау кирәк.

Кала инде шуннан «эшне башкару»:
Ягъни тәгәрәтү дошман башларын.

---

* Дәвамы. 2013 елның 10 нчы саныннан басылып килә.
** Курсив илә язылган юллар нәкъ оригиналдагыча, тик сүзләрнең фонетик йөзе генә борынгыча.
[1] Тур – әсирләр өчен махсус әзерләнгән җыелу урыны. Әсирләргә аш-су бирү — тизрәк тынычландыру өчен.

Сугышны хәл итә саклык-уяулык;
Кем уяурак булса, шул өстен калыр.

Уяу бий болай ди (сүзе акыллы):
«Арыслан менгән ир булсын камчылы.

Дошманны җиңәргә бар ике алым,
Шул алымнар аңар китерер үлем:

Иң элек — дошманга хәйлә куллан син,
Шулай итеп, аның йөзе кызарсын.

Икенчедән, саклык-уяулык мөһим,
Кем уяу-сак булса, шул булыр өстен».

Кем уяурак булса, шул отар яуда,
Уяулык китерер шиксез зур файда.

Дошман явы күбрәк булса, алдатып,
Һөҗүм иттер аны уңай бервакыт.

Ярашып-килешеп булса, тиз яраш.
Югыйсә кораллан, нишлисең – көрәш.

Дошманга һөҗүм ит төнге гафләттә,
Син азмы йә күпме – белмәс халәттә.

Әгәр һөҗүм җае чыкмаса, тукта,
Ялавач[2] җибәр, юл эзлә солыхка.

Телең оста булсын, сак бул һәр сүздә,
Җаңнән качу өчен төрле юл эзлә.

Дошман ил булмаса һәм киреләнсә,
Сугышка омтылып, кулын бирмәсә,

Сөйләшүне сузма, әзерлән җәңгә,
Корал өләш, мактап, рух бир гаскәргә.

Хәзерлекне озак сузма – дошман сак,
Көчең азлыгын ул күреп алачак.

Ни ди күп дошманны кат-кат җиңгән ир,
Яуда күпне күргән, күп кичергән ир:

**Кем уяурак булса, шул отар яуда,
Уяулык китерер шиксез зур файда.**

«Күренмәгән яуның хәбәре ерак,
Күренгәч, беленер – кем ул, нindирәк».

Ялкын бул – хәлеңне сизмәсен дошман,
Югыйсә качарсың килгән юлыңнан.

Сүвнең бер өлешен поскында калдыр,
Җәяү гаскәр белән йөгер иң алдын.

Чал карт яугирләрең алга куелсын,
Төп гаскәр алдында калкандай булсын.

Яуларны күп күргән чыннан да яугир,
Сугышта төп терәк, белә күп тәдбир.

Кече кор[3] егетләр нык булмый бер дә:
Ялкыннары сүнә сугышка кергәч.

Ныклы ирләрне куй алга һәм артка,
Уртакулларны куй уң һәм сул якка.

Дошман батырлары ыргылса алга,
Тиң егетләр[4] каршы торсын аларга.

Ерактан иң тәүдә ук ату кирәк,
Якынлашкач, эшкә китә сөңгеләр,

Кылыч һәм айбалта. Китә буталыш:
Кул-аяк, теш-тырнак, якадан алыш.

Ныгын шулчак, арка бирмә дошманга,
«Җиңү яки үлем икән» дип аңла.

Ни ди сугышларда чыныккан көр ир:
Ныклы бул – ныклылык җиңү китерер.

**Ялкын бул – хәлеңне сизмәсен дошман,
Югыйсә качарсың килгән юлыңнан.**

[2] Ялавыч – дипломат.
[3] Кор – яшьтәш ир-егетләр түгәрәге (шуннан – кордаш). Корлар: 0-12; 12-24; 24-36; 36-48; 48-60; 60-72; 72-84 һ.б. яшьтәгеләр. Һәрбер корның үз атамасы бар. Кече кор — 18-24 яшьлекләр; 24-36 яшьтәгеләр — бүзьегет; 36-48 яшьтәгеләр — ир уртасы һ.б.
[4] Тиң егетләр «гвардия». Оригиналда уры – хөкемдарның туганнары, кардәшләре.

Кәләш кыз шатлыгы – никах төнедер,
Егет куанычы – җиңү көне, бел.

Кәләш кыз шатлыгы – никах төнедер,
Егет куанычы – җиңү көне, бел.

Батырлар сындырыр дошман муенын,
Алырлар яуларда әсир һәм полын[5].

Алпар яуны күрсә, гайрәте таша,
Бүтәннәргә алын бирми – сугыша.

Яуны күргәч, алпар арыслан булыр.
Йә үзе үтерер, йә шунда үлер.

Яуны күрсә, ярсып кызарыр алпар,
Сугышка ул керсә агачак ал кан.

Корал-ярак, чапрак кып-кызыл була,
Алсу йөзләр исә гүя көл була.

Яу укталса[6], сине таптарга атта,
Тыныч бул, чигенмә, тайпыл бер якка.

Әгәр яу чигенсә, эзеңә басып,
Бар һәм тукталмастан һөҗүм ит, ярсып.

Әгәр дошман качса, шундук ку аны,
Әсир алыйм, диеп калма юанып.

Яу кыйраткан ирләр кыйратыр тагы,
Тәмам таркалганчы шул дошман явы.

Тик таркалган яуның чапма эзеннән,
Чөнки таркаласың, арып, үзең дә.

Тар-мар ителгән яу үзе дә үлә,
Үлемгә йөз тоткач кирәк ул кемгә?

Гафил кеше үлә, ди, аягүрә,
Гафил түгелләр юл таба, көн күрә.

Бу чакта үзеңне кара син, угыл,
Күзәт һәм үлемнән коткарыл, түңел.

Белдекле кешеләр миңа әйттеләр
(Белдекленең сүзе юллама, диләр):

Яу таркалып качса, артыннан кума,
Үз-үзеңне кыйнап әвәрә булма.

Тәмам таркалса яу, җыелмый кабат,
Сүндерелгән ялкын кабынмый кабат.

Өметсез кешеләр үлемгә барыр,
Яраланган ерткыч эчеңне ярыр.

Кем батыр сугышса, бүләклә шундук,
Йөзенә йөгерсен якты кызыллык.

Кем алпар асраса, аны мактасын,
Хәстәрләсен көнен, алпар шатлансын.

Яманны мактасаң, яхшырып китә,
Яхшыны мактасаң, китми исе дә.

Ирне макта: аулар — арыслан тотар,
Атны макта: чабыр, кош кебек очар.

Имгәнсә ят алпар — аны дәвала:
Әсир яугирләрне йолып алалар[7].

Яуда үлгәннәрне хөрмәтләп күмдер,
Угыл-кызларына тәгъзия[8] күндер.

Моңа шатланырлар алпар-яугирләр,
Сугышта, кирәксә, җаннар бирерләр.

Җылы сүз, көләч йөз, бүләкчел холык –
Бу өч нәрсә белән кеше агымлы.

Шуннан «кол итәрсең» азат кешене,
Сөенеп, кирәксә, йолыр үзеңне.

Өметсез кешеләр үлемгә барыр,
Яраланган ерткыч эчеңне ярыр.

[5] Төп текстта шулай: ихтимал, әсир һәм полын төшенчәләренең аермасы булгандыр.
[6] Укталу – «һөҗүм итү» (хәзерге телдә дә бар).
[7] Йолып алу — акча (йолып) түләп алу. Күрәсең күрексез, гади әсирләрне дәвалап тормаганнар.
[8] Тәгъзия – яуда үлгән сугышчыларны хөрмәтләп искә алу, гаиләләренә ярдәм итү һ.б.ш.

Моңа дәлил булган мәкаль бар, бөкәм
(Уйлап карасаң бик дөрес әйтелгән):

Көләч йөз, җылы сүз, әйбер бүләгең –
Шундый кармак, аңа һәркем эләгер.

Сатып алма колны акча чыгарып:
Шул өч нәрсәдән күп булыр колларың.

Сәргаскәрең булсын дисәң юньлерәк,
Монда да бүләкләр куллану кирәк.

Бир алтын-көмеш һәм әйбереңне дә,
Җанын фида кылыр бәрабәренә.

Килер хезмәтчеләр шул өч нәрсәгә,
Шуны белсен бийләр, шул төп мәсьәлә.

Юмарт булсаң әгәр гаскәр башына,
Ни авыр гамәлне эшкә ашырыр.

Шундый булса әгәр гаскәр-сүв башы,
Җиңү генә булыр аның юлдашы.

Чын сүв башы бүтән төрдә булмыйдыр,
Һәм эшлекле вәзир дә нәкъ шундыйдыр.

Шундыйга илбикләр ышансалар да
Ярый – теләгәнне шиксез табарлар.

Һәм әйтте Үгделмеш: – Котлы хөкемдар,
Бөек эшләр эшләр ике кеше бар:

Вәзир һәм сүв башы – байракчы-тучы,
Берсе каләм тота, берсе — кылычны.

Шуларның кулында ил дилбегәсе,
Алар бердәм булса — ил җиңелмәслек.

Хөкемдар аларны бик белеп сайлар,
Башларын кистерер бик узынсалар.

Юмарт булсаң әгәр гаскәр башына,
Ни авыр гамәлне эшкә ашырыр.

Илгә баш булсаң да көч белән бик тиз,
Илдә хөкем йөртеп булмый каләмсез.

Алар дус булсалар, файдасы хәтсез,
Башбаштак булсалар – ил бәрәкәтсез.

Бәкләре дә булса яхшы кешеләр,
Бу ике сайланмыш яхшырак эшләр.

Болардан булала зур файда илгә,
Бу хәлдә – куанып хөкемдар бийгә.

Ишет, ни ди бөкә, күрче, илбашы
(Акыллы сүз була ич рухи ашың):

«Кылыч белән илне кулга алалар,
Идарәне каләм илә кылалар».

Илгә баш булсаң да көч белән бик тиз,
Илдә хөкем йөртеп булмый каләмсез.

Сугыш бетеп, кылыч кергәчтен кынга,
Гадел хөкем йөртеп булмый бер ел да.

Каләмгә ал авыл, кала, улусны,
Шулай гына тияр сиңа өлешең.

Шушы иде бийем минем белгәнем,
Соравыңа тәгәл җавап биргәнем.

Илбик әйтте: «Тынлап төгәл ишеттем,
Тагын бер сүзем бар, сиңа, егетем,

Яхшы уйлап, дөрес итеп бир сөйләп –
Олуг хаҗиплеккә нинди зат кирәк.

Хаҗипләргә башчы да була белсен,
Туган илгә җанын да фида кылсын.

Сөйлә миңа шушы хакта сүзеңне,
Төгәл-дөрес әйтеп, син ач күземне».

Дәвамы бар ■

ГАЯЗ ИСХАКЫЙНЫҢ «СОЛДАТ» РОМАНЫ[1]

Мәсгуд Гайнетдин

«Солдат» романының хәзерге вакытлы матбугатта 1918 елгы басмасы (92 битлек) нигезендә[2] тулысынча дөнья күрүе – әдәбиятыбыз өчен бәяләп бетергесез зур табыш. Беренче, кыскартылган басмасы (46 бит) 1908 нче елда дөнья күргән[3]көннәрдә үк Фатих Әмирхан «Әл-Ислах» газетасында игълан-реклама планында язылган 18 юллык кыска гына рецензиясендә[4] романның әдәбиятыбыз тарихында һәм әдип иҗатында күренекле вакыйга булганын белдерә: «Шуны әйтеп китәргә кирәк ки, әсәр – Гаяз әфәнденең чын мәсләген күрсәтә алырлык әүвәлге әсәредер.

Шуңар күрә дә әдәбиятымыз вә фикри тәрәкъкыемызне аңларга вә үлчәргә теләгән затларның җөмләсенә [барчасына] укып чыгарга тәүсыя [тәкъдим] итәм». Рецензиядә әсәрнең структурасы, планы һәм басылу тарихына кагылышлы кайбер мәгълүматлар да теркәп калдырылган. Аның кыскалыгы җәмәгатьчелек һәм Ф.Әмирхан шуннан артыгын белмәгән, дигәнне аңлатмый. *«Гаяз әфәнденең бу соңгы әсәре хакында никадәр тәфсилле язарга теләсәм вә никадәр үзеннән килмәгән сәбәпләр белән мөхәрриренең тел очында әйтелми калдырылган сүзләрен әйтергә, язарга теләсәм дә, мин дә, үземнән килмәгән сәбәп белән аннан тыелырга мәҗбүрмен»*, — ди рецензия авторы[5]. Нәрсә булган? Ник Г.Исхакый да, Ф.Әмирхан да тел яшереш уены уйныйлар? Бу — бернинди сер түгел. Ул заманда әлеге ишарәләрнең мәгънәсен һәркем төгәл аңлаган. 1908 елгы басмасына сөргендә, төрмәдә язылган әлеге әсәрнең цензура бәйләнә (тыя) алмаслык бүлекләре генә китапка кертелә. Ф.Әмирхан: *«Хода насыйп итеп, бервакыт һавалар алмашынса, йөрәкләрне катырган, җансызландырган суыклар урынына ачык йөзле, җылысы белән бөтен нәрсәгә рух өрә торган «яз кояшы» чыкса, калганы да нәшер ителер вә мин дә тәнкыйдемне язармын»[6]*, — дип дәвам итә. 1918 елда гына — Казанда Болак арты республикасы тар-мар ителгән февраль-март айларында, ашыгыч рәвештә Муса Бигиевләр төркеме тарафыннан Петроград каласының «Әманәт» ширкәте матбагасында дөнья күргән «Солдат» китабының тәүге сәхифәсенә: *«Гаяз Исхакый мәҗмугаи әсәреннән 8 җильд [том] 1 нче китап. Языла башлады: Казан төрмәсендә. 1907 елда; Язылып бетте: 1908 елда, Пинега шәһәрендә, сөргендә»*, — дип күрсәтелгән.

1907 елның 3 июнендә патша хөкүмәте II Дәүләт Думасын куып тарата. Демократик сайлау хокукы патша исеменнән юкка чыгарыла. Карагруһ партияләрнең абсолют өстенлеген тәэмин итүгә юнәлтелгән яңа сайлау кануны кертелә. Бу көн тарихта «Дәүләт

[1] Мәкалә журнал вариантында бирелә.

[2] Исхакый Г. Солдат. 8 нче җилд. 1 нче китап. — Петроград: Нашире Г.Исхакый, Тип. Т-ва «Аманәт», 1918. — 92 б. Китап ТР Милли китапханәсе Кулъязмалар һүм сирәк китаплар бүлеге фондында саклана.

[3] Исхакый Г. Солдат. 1 нче җөзьә. — Казан: Нашире Хөсәен Әбүзәров, И.В. Ермолаев типолитографисе, 1908. — 46 б.

[4] Әмирхан Ф. Солдат // Әл-Ислах — 1908. — 26 октябрь.

[5] Әмирхан Ф. Әсәрләр: дүрт томда. III том. Публицистика. — Казан: Татар. кит. нәшр., 1989. — Б. 141.

Тоткын Гаяз Исхакый Казан төрмәсендә. 1907 ел, июнь

түнтәрелеше» — 1905 ел революциясе тәмамлануын рәсмиләштерү, илдә иң рәхимсез реакция урнаштырылуын раслау көне, дип атала. Иң актив хөррият көрәшчеләрен кулга алулар, ерак сөргеннәргә куулар башлана. Реакция режимы игълан ителүнең икенче көнендә үк Казанда Г.Исхакый да кулга алына. Хөкем ителеп, 1907 елның октябрь башларында Мәскәүгә, Петроградка, декабрь азакларында Архангель губернасындагы Пинега шәһәренә сөргенгә озатыла. Казан төрмәсендә утырган көннәрендә ул үзенең «Солдат» романын яза башлый.

Димәк, «Солдат» — әдипнең яңа, реакция режимы шартларында мәйданга китергән, реакция режимына җавап булган беренче әсәре. Әсәрнең эчтәлегендә көрәшче әдип яңа ярсуларын,

[6] Әлеге тәнкыйди мәкалә басылмаган. Октябрь инкыйлабыннан соң моңа ихтыяҗ да, мөмкинлек тә булмаган.

өметләрен һәм үз идеалына, көченә, киләчәгенә ышануларын чагылдыра, яңа югарылыктагы көрәшкә ташлана. Реакция башлану көннәренең бу беренче инстинктив, интуиция оптимизмы әсәргә үтәдән-үтә сеңгән. Шәфкатьсез реакция режимы җәмгатьчелекне һәм һәр шәхесне бик тиз өметсезлек, пессимизм ташкынына батыра. Г.Тукайның ошбу өметсезлек тулы көчкә кергән көннәр кәйфиятен чагылдырган «Яшьләр» (1910) шигырен хәтерлик:

Бара милләт, — зәгыйфь, абыныр-абынмас.
Сүнә яшьләрдә ут кабыныр-кабынмас.
Кичә, якты вә милли бер көңелдән
Бүген тычкан утыдай нур табылмас.
...Тотып милләт байрагын, юлга чыктык:
«Бу куллар мәңге, — дип, — җиргә салынмас!» —
Егылдык без, ике-өч чакрым да китми:
«Егетләр! Бездә көч юк, ахры, булмас...»

Тукайның бу шигыре күңел төшенкелеге халәтен төгәл чагылдырган кебек, Г.Исхакыйның «Солдат» романы да рәхимсез реакция һөҗүмнәре өскә ишелгән, кулга алыну, сөргенгә озатылу көннәре кичерешләрен, күренешләрен, Тукайча, шулай ук төгәл, сәнгатьле гәүдәләндереп калдырган... Соңрак Г.Исхакый да бу күңел төшенкелекләреннән, массакүләм өметсезләнүләрдән читтә калмаган. (Әдипнең «Тормышмы бу?» (1914) романын искә төшерик.)

«Солдат» әсәренең язылу, басылу хәлләренә дә искәрмә сорала. Әсәрне автор Казан төрмәсендә яза башлый. Казанда язылган өлешенең бер күчермәсен, сөрген юлындагы төрле кутузкаларда (төрмәләрдә), этапларда югалтмас өчен, әлбәттә, Хөсәен Әбүзәревкә дә биреп калдырган булуы мөмкин. Язып тәмамланган нөсхә, 1908 елның җәендә Петербургка качып кайткач, Казанга, Хөсәен Әбүзәревкә җибәрелә. Х.Әбүзәрев мәсьәләне кыска тота. Г.Исхакый җәй урталарына Петербургка кайтып җитә, дип фараз кылыйк. Кулъязма Казанга килеп ирешкәнче җәй азаклары җитә, дип уйласак, Х.Әбүзәрев аны иң үткен бүлекләрен төшереп, цензура туктата алмаслык татар яшәеше һәм этнографиясе, татар яшьләренең солдат хезмәте турындагы өлешләрен генә калдырып, шунда ук «курьер поезды» белән аерым китап итеп бастыра. Китапның «фуроры» Ф.Әмирханның «игъълан-реклама» характерындагы 18 юллык рецензиясе (1908 елның 26 октябре) белән генә чикләнә. Ә кара реакция үз эшен белә: әсәрне оныттыру гына түгел, әсәрен дә, авторын да татар әдәбиятыннан читләтеп юкка чыгару эзеннән бара. Совет режимында бу максатка ирешәләр дә. Г.Исхакый үзе дә, исеме дә, әсәрләре дә татар иленнән һәм татар халкы тормышыннан мәңгелеккә куыла...

Көрәш сафыннан тартып алынып, реакция тоткынлыгы һәм сөргененең беренче көннәрендә язылган «Солдат» романы әдип иҗатында аерым бер урын тота. Автор хокуксыз мескен татар кешесенең, аеруча хатын-кызларының, шәхси бәхетсезлекләре күренешләрен сурәтләп, гаҗизләнеп яшь сыгуыннан арынып, татар халкының социаль-тарихи яшәеш үзенчәлекләрен сурәтләү

Гаяз Исхакый – сөргендә. Сулда, ак болан янында. Пинега шәһәре, 1908 ел

югарылыгына күтәрелә. Польшаның Лодзь шәһәрендәге «патша дошманнары», «полякларның», «яврәйләрнең» реакциягә каршы киеренке көрәшләрен, бу көрәштә, солдатка алынган аңсыз татар крестьянының катнашын сюжет итеп ала. «Бетсен сугыш!» дигән лозунг астында кызыл флаглар күтәргән күп меңләгән эшчеләр демонстрацияләре... «Көрәш» — атка атланган, котырынган казакларның эшчеләрне рәхимсез камчылаулары, аттан таптатулары... Казакларга ярдәмгә чыгарылган хәрби көчләрнең, солдатларның демонстрантларны мылтык түтәсе белән сугып егулары... Бәрелешләрнең югары ноктасы: «Качырмагыз, бер читкә кысрыклап урап алыгыз», — дигән боерык буенча, татар солдатының, качарга теләгән бер карт эшчене, туктата алмаслыгын белгәч, карынына штык кадап үтерүе... Солдат моның өчен җавапка тартылмый, медаль крест-тәре ала һәм шуның белән чамасыз горурлана.

Әсәр тема, сюжет яңалыгы белән дә татар әдәбиятының иң югары казанышына әверелә. Г.Исхакыйның моңарчы язган әсәрләрендәге киңәш, сабак, дидактика, үгет-нәсыйхәтчелек, ясалма сентиментальлек чагылышын искәрткән бизәкләүләр юкка чыга. Әдәби сынландырулардан баш тарта кебек. Телеграмма стиле диярсең. Өзек-өзек кыска җөмләләр һәм шуңа яраклы, матурлаузиннәтләүләрсез төгәл мәгънәле күренешләр. Алар сынлы сурәтнең штрих элементларын хәтерләтәләр кебек. Экспрессияләндерелгән хикәяләвенә, бәяны рәвешенә генә игътибар юнәлтик. Бу хикәяләү — беллетристик әдәби сөйләм генә түгел. Биредә образларның, эпизод-күренешләрнең сурәтләре сынлы сәнгаттәге кебек күз алдына бастырыла... Сөйләм шигъри саф әдәби әсәрләрдәгедәй бер үк гыйбарәне, фразаны төрле аспектта кабатлап, эчтәлек-мәгънәне үткенәйтүләрдән гыйбарәт. Болар сөйләмгә аерым бер матурлык

бирә, чын сәнгатькә әйләндерә. Сентиментальлек — рәхәтләнеп, изрәп-таркалып хискә бирелүгә түгел, ә тирән яшерен эчке мәгънәләрне ачып, төпченеп, ваклап сүтеп-таркатып күрсәтелгән вакыйгаларның, эпизодларның эчке серләрен ачуга юнәлтелгән. Өр-яңа, мәгънәлелегенең колачлы булуы белән затлы бер әсәр…

«Солдат» романы Г.Исхакыйның «Ике йөз елдан соң инкыйраз», «Тормышмы бу?», «Сөннәтче бабай», «Зөләйха» кебек зур йөкләмәле, сәнгатьлелек эталоны саналырлык бөек җәүһәрләре арасында күренекле урын тота. Әсәр әдип иҗатының җитлеккән эстетик күренеше (феномены) дип тә билгеләп була. Биредә һәр катлам һәм һәр эпизод үзе бер этюд итеп, ювелирларча нечкәләп эшләнгән. Татар этнографиясен сәнгатьле гәүдәләндерүгә багышланган битләр… Революция көрәше күренешләренең бай традицияле, органик сәнгатьле дәрәҗәгә китереп, яңа татар прозасын хыялга килмәгән рәвештә киңәйтү… Ярым сентименталь, ярым дини-әхлакый татар әдәбияты гуманизмы чикләрен һәм шкаласын заман һәм яшәеш таләбенә җавап бирә алырлык алдынгы халыклар әдәбиятлары ирешкән югарылыкка якынайту… Әдәбиятта яңа герой образының яңа моделен тудыру… Кыскасы, санап бетергесез күп яңалыклар, казанышлар.

Реакция хакимияте урнашкан көндә кулга алынган Г.Исхакый үзенең «Таңчылык[7]» ялкынлану-өермәләнүләрен дә төрмә һәм сөрген капкасының тышкы ягында калдыра. Камера ишеге ябылу белән бөтенләй башка, яңа принциплар нигезендә, «Солдат» романын язарга утыра. Димәк, бу минутка инде аның өр-яңа принциплары формалашкан, өлгергән була. Дөресрәге, әлеге башка юнәлешле принциплар аның иҗтимагый хәрәкәт кочагына атылган, беренче каләм тибрәтә башлаган көннәрендә үк булган, «таңчы»лыгы белән бергә, кулга-кул тотынып яшәгән, үскән, формалашкан. «Таңчылык»ка комачауламаган, күләгә төшермәгән, аяк чалмаган хәлендә арка таянычы булып яшәгән. Шуңа күрә дә «таңчылык» ялкынланулары, өермәләре татар тормышының, татар әдәбияты һәм автор иҗатының кабатланмас бер күренеше буларак, романны яңача формалаштыруда катнаша алган. Реакция чорында «таңчылык» Г.Исхакый биографиясендәге кискен яңа борылышта яңалыкның тыйнак арка таянычы булып кына катнаша. Шулай итеп, Г.Исхакый беркайчан да рәсми рәвештә «таңчы»лыгыннан аерылмаган. Кабат-кабат аны әтәч кикриге итеп файдалануны истән чыгармаган. «Солдат» романының «чишмәсе» 3 июнь реакциясе төрмәсеннән түгел, ә әдип иҗатының «таңчылык» дәвереннән башлана.

Г.Исхакый төрмә каторгасында, богауланган хәлендә хөррият революциясе хәрәкәтенә тугрылыклы калып, шәхес яңаруы темасын үзәккә алып, оптимистик фаҗигаләр романын иҗат итә. Роман-фаҗига, роман-притча, бәләкәй роман-эпопея жанрына, Томас Мор, Компанеллалар утопиясенә тартым үлемсез хөррият социализмы роман-утопиясен мәйданга китерә.

[4] 1905-1907 елларда Г.Исхакый «таңчылык» лидерларыннан берсе була. Социаль-революционерлар йогынтысында булган әлеге төркем «Таң йолдызы» газетасы тирәсендә туплана.

СОЛДАТ

Гаяз Исхакый

(роман)

I

Садыйк ашыга-ашыга ат җигеп двордан чыкканда час сәгате өчне сукты. Ул артындагы энесенә әйләнеп карады да атына сугып чабарга тотынды. Күп йөрүдән казылган урамда арба әле бер якка, әле бер якка кагылганга, Садыйкның арбасында әйберләр төрлесе төрле якка сикерә, Садыйк үзе дә бер алга китеп, бер артка китеп, исерек кеше кебек селкенә башлады. Менә озак үтмәде, шәһәрне чыктылар. Садыйк, атын туктатып, яңадан арбасындагы әйберләрне рәтләп куйды. Янындагы карбызны алып, арбаның үрәчәсенә сугып ярды да бер кисәген арттагы арбадагы энесенә бирер өчен: «Закир! Закир! Уз! Уз!», — дип кычкыра башлады. Закир да килеп чыгып, атлатып кына узды, ул да арбасын рәтләргә туктады. Ул туктагач, Садыйк карбыз берлә калачны күрсәтеп: «Мә! Ал!» — дип кычкырды. Закир карбыз алырга килгәндә Садыйк: «Бик кызу кайтма, атыңны яктыда эчермә, мин йоклыйм», – дип, карбыз ашарга тотынды, атлар кузгалды. Ул яхшылап утырганның соңында кесәсен тотып карады. Кулы катыга тигәч, акчасы югалмаган икән дип, күңеле тынычлап, карбызны ашарга дәвам итте. Менә тагы күңеленә әллә нәрсәсе калган кебек булып китте. Базарда алган нәрсәләрен барысын да уйлады. Кулы берлә капчыкны капшап карарга тотынды, кулына зур такта чәй берлә шикәр тиде. Аның артыннан әллә нинди йомшак нәрсәгә кулы бәрелде, анысы сеңеленә алган күлмәк икәнлеге исенә төште. Аның артыннан каеш йөгән, чырабчак кулына тиде. Капчык төбендә балаларга дип алган алмалар тәгәри башлады. Ул: «Юк, болар берсе дә түгел! Боларга башка бер бик кирәкле әйберем бар иде», — дип, кирәкле әйберен эзләргә тотынды. Үзе, карбызны арчып бетереп, авызыны сөртер өчен тирәли чиккән ак яулыкны алырга кесәсенә тыгылды. Авызын сөрткәндә кулы яулыкның чиккән кырыйларына тиде, кылт итеп күңеленә Гайниҗамал килеп төште. Әйе, бу яулык Гайниҗамал яулыгы ич! «Гайниҗамал яулыгы, Гайниҗамал яулыгы!» — дип, шул уйдан үтә алмаенча, шул уйда катты. Аның авызында «Гайниҗамал» дигән сүз әвәләнә башлады. Ул үзенең югалган нәрсәсенең Гайниҗамал берлә ни мөнәсәбәте барлыгын хәтеренә китерү өчен үзенең башыннан әллә нәрсәләр эзләргә тотынды, аның күңеленә кичә сыер азбарында Гайниҗамал берлә күрешүе, Гайниҗамал берлә сөйләшүе, аларның сөйләшкәндә бертуктамаенча сыерның күшәве хәтеренә төште. Гайниҗамалның Садыйкны кысып кочаклавы, авызыннан үбүе күңеленә килде. Ләкин югалган нәрсәсенең Гайниҗамал берлә мөнәсәбәте һаман табылмады. Ул тагы тырышып уйларга тотынды. Шул ара да булмады, арба базга төшкән күк бик катылык итте. Садыйк урыныннан селкенеп китте, бу селкенү Садыйкның уйларын бөтенләй икенче тарафка агыза башлады. Кылт итеп аның күңеленә бүләк килеп төште. Садыйк әллә ничә ел эзләгән нәрсәсене тапкан кебек «бүләк, бүләк» дип үзеннән-үзе сөйләнергә тотынды. «Бүләк, бүләк! Гайниҗамалга бүләк!» — дип бик тиз кесәләрен актарырга тотынды. Озак үтмәде, ул кечкенә генә кәгазь савыт берлә кыныга салган сабынны кесәсеннән өстерәп чыгарды. Ул, үзенең суга батып үлә торган баласын судан тартып чыгарган кеше

кебек шатланып, кәгазь савыт берлә сабынны карарга тотынды. Икесен дә төрле яктан әйләндереп караганның соңында, әллә нинди әҗәл даруыны саклаган кеше кебек, күкрәк кесәсенә тыгып куйды.

Бу нәрсәләрне карау, аларны җыеп кую Садыйкка әллә нинди үзенә бертөсле шатлык бирде. Ул үзенең күкрәгендә әллә нинди бик кадерле, аңарга бик якын нәрсә барлыгын хис итте. Ул шул шатлык берлә шатланып, Гайниҗамалны уйларга тотынды. Үзенең Гайниҗамал берлә бер елдан бирле сөешүе, Гайниҗамал берлә әле азбарда, әле су юлында күрешүләре, Гайниҗамал берлә бер-берсеннән аерылышмаска вәгъдә кылышулары күңеленә төште. Ул Гайниҗамалдан аерылмаска үзенә-үзе вәгъдә кыла башлады. Гайниҗамал берлә тагы күрешүләрне, Гайниҗамал берлә кияүле-бикәчле булып йөрүләрен, Гайниҗамал берлә ирлехатынлы булып торуларын, Гайниҗамал берлә бала-чага атасы булып гомер итүләрен уйлый башлады.

Аның күзенә озын буйлы, кара күзле, кара сачле, тулы йөзле Гайниҗамал күренгән кебек булды. Аның күңеленә Гайниҗамалның шул кара күзләрен кызартып, кара керфекләрен юешләтеп яше аккан кебек булды. Ул Садыйкка карап: «Булмас, булмас!» — дип, башыны селеккән кебек булды. Садыйкның матур уйлары бердән югалды. Аның күңеленә әллә нинди ямьсез уйлар килә башлады. Күз алдын томан каплаган кебек булды. Гайниҗамал шул томан эчендә аз гына күренә башлады. Озак узмады, ул бөтенләй югалды. Менә шып итеп ат туктады.

Садыйк әллә ни булган кебек селкенеп китте. Күңеленә быел солдатка каралуы килеп төште. Ул, башын күтәреп, алга карарга өлгермәде, энесе: «На!» — дип кычкырып, атын куарга тотынды. Садыйкның да аты кузгалып китте. Аның уйлары бөтенләй башкада, ул үзенен солдатка каралуы тугрысында уйларга тотынды. Аңарга аны алырлар төсле күренә башлады, аны авылыннан аерып, йортларыннан аерып, бигрәк Гайниҗамалдан аерып, әллә кая еракка озатырлар кебек күренде. Ул үзен үзе солдат итеп уйлый башлады. Ул үзен-үзе зур казармада әллә никадәр соры шинельләр кигән егетләр арасында, әллә никадәр аталарыннан-аналарыннан, үзләренең сөйгән Гайниҗамалларыннан аерылган солдатлар арасында күргән кебек булды. Тагы аның күзенә Гайниҗамал күренә башлады. Тагы ул үзен аның кочагында кебек хис итте. Атның туктавы аны тагы уятты. Ул үзен су уртасында күреп, бакчага җиткәнлеген белде. Атына су эчермәс өчен «на!» дип кычкырды. Ат тагы кузгалып китте. Ул урынын рәтләп, дилбегәсен бәйләп, йокларга ятты. Бик озак аның күз алдында әллә нинди солдатлар, әфисәрләр күренгән кебек, бик озак аның янында, аның кочагында Гайниҗамал яткан кебек булды, бик озак аның берлә Гайниҗамал арасында әллә нинди җитә алмаслык җир бар кебек, үтә алмаслык су бар кебек күренде. Шул уйлар, шул исәпләр берлә Садыйк йокыга китте.

II

«Туу!!» дигән тавышка Садыйк уянып китте. Күзен ачу берлә үзенең кайтып җиткәнлеген белеп торып утырды. Ул уйларга да өлгерә алмады, майламаган капка шыгыр итеп бик көйләп ачылды. Садыйкның аты кузгалып йортка керде. Садыйкларга каршы бөтен өй җәмәгатьләре йөгереп чыкты. Әтисе атларны муеннарыннан тотып карап, кызу кайтуларын-кайтмауларын белгәннән соң: «Исән кайттыңызмы, оланнар (угланнар)?» — диде. Садыйк арбадан төшеп: «Аллага шөкер, сары алашада 26 пот булды, биядә 24 пот та 11 кадак, 52шәр тиеннән бушаттык», — диде. Шул арада кечкенә кызлар: «Абзый, алма! Абзый, алма!» — дип, әле Садыйк янында, әле Закир янында әйләнә башладылар. Миңлеҗамал абыстай угылларын күрү берлә тиз генә самавырга ут салды. Закир берлә Са-

дыйк атларны туарып, арбаларны лапас астына кертеп өйгә кергәндә, самавыр да кайнап өлгерде. Әхмәт абзый да, кызулана-кызулана тәһарәтен төзеп бетереп, ахшамга барырга хәзерләнә башлады. Садыйклар керү берлә ул чалмасын киеп: «Акчаны мин намаздан кайткач бирерсез», — дип, ашыга-ашыга чыгып китте. Садыйк берлә Закир чәй эчәргә утырдылар. Садыйк, ниләр алганны барысын да күңеленнән үткәреп, әтисенә хисап бирергә хәзерләнде. Тагы кершән берлә сабынга килеп җитте. Аларга киткән 45 тиен расхутны төрлесен төрле нәрсәгә бүлеп, үзенең бухгалтериясен тәмамлады. Ләкин кершән-сабын тагы моның күңелендә әллә нинди хисләр уяндырды. Ул тагы әллә нәрсәдән курыккан кебек булды. Әллә нинди өметеннән өзелгән [кебек] булды. Тагы аның күңеленә үзенең быел каралуы, үзенең бер-ике айдан солдатка алынып, әллә кая китүе, үзенең шул дөрләгән өйдән, шул самавырдан, шул йорттан, шул сары алашадан, шул сабыннар хуҗасы Гайниҗамалдан аерылуы хәтеренә килде. Ул бик озак ясаган чәйне эчмәенчә, күзен бер урыннан алмаенча уйларга тотынды. Ул төрле нәрсә тугрысында уйларга теләде, төрле юл берлә үзенең күңеленнән шул ямьсез солдатлык уен җибәрергә тырышты. Ләкин ни генә уйласа да, һәр уйның очы солдатка барып төртелә, ни генә исәпләсә дә, ул эшнең ахыры солдатка барып бәрелә иде.

Әнисе: «Улым (углым), чәең суына», — димәсә, Садыйк бәлки шул хәлдә, шул уйда тагы әллә никадәр катып торган булыр иде. Бер кеше дә аның шул тынычлыгын бозмаса, ул бәлки шул авыр мәсьәләнең очына да чыккан булыр иде. Ләкин һәрвакытта да ул шул мәсьәләне уйлый башласа, ул үзенең солдатка китүен-китмәвен исәпли башласа, үзенең уе шул мәсьәләнең иң ямьсез вакытында гына икенче якка борыла да, күңелендә һәрвакытта ямьсез җәрәхәт калдыра. Бу юлы да шул булды. Ул үзенең китмәү ихтималын уйларга өлгерә дә алмады, энесе аны бүлде. Ул тиз генә ясаган чынаягын эчеп бетереп, дога кылып, өйдән чыкты. Әнисе: «Ерак китмә, әтиең кайткач та аш салам», — дип калды. Бу сүз тагы аның күңеленә үзенә бертөрле тәэсир итте. Әти кайтса, әни аш сала, солдатта әти дә ахшамнан кайтмас, әни дә аш салмас дип, тагы иске уйга кайтты, тагы балык башын чәйнәргә тотынды. Ул келәткә эләргә уйлап яңа йөгәнне кулына алды. Йөгән дә аның күңеленә аның солдатка китүен, содатта мондый йөгәннәр булмавын хәтеренә китерде. Аның борынына яңа дегет исе керде. Бу ис тә аның шул фикерен беркетте. Ул йөгәнне келәттәге чөйгә элеп, капка төбенә чыгып, мичкә өстенә утырды. Элгәре бик озак кай төшеннән тотынып уйларга икәнлеген белмәенчә торганның соңында, тагы үзе тугрысында, тагы солдатка китү тугрысында уйларга тотынды. Менә сарык көтүе керде. Бөтен урамны шаулатып сарыклар кычкырыша башладылар. Өем-өем сарыклар Садыйкларга килә башладылар. Садыйк башын күтәреп карады. Алар да Садыйкка үзенең солдатка керүен, Садыйкның солдатка китүен хәтеренә китерде. Тагы бер-ике айдан сарык көтүе дә кермәс, сарыклар да кычкырмас кебек тоелды. Озак үтмәде, югары очтан әтисе дә күренде. Урам өсте өйнең ачык тәрәзәсеннән ит исе килә башлады. Әтисенең кайтуы, ит исенең борынына керүе дә Садыйкка һаман шул уйны уйлатты, һаман шул солдат мәсьәләсен күзе алдына китерде.

Аңарга, озакламаенча, әтисенең намаздан кайтуы күренмәс кебек, озакламаенча, ит исе чыкмас кебек, озакламаенча, шул мичкәгә утырып торырга мөмкин булмас кебек тоелды. Әхмәди абзый да кайтты. Өйдә дә: «Аш өлгерде», — дигән тавыш ишетелде. Садыйк та, авырлыгыннан башын күтәрә алмаган кеше кебек, башын иеп кенә өйгә керде. Кич үтте.

Дәвамы бар ■



ТУКАЙ ЭНЦИКЛОПЕДИЯСЕ

Сәхифәне филология фәннәре докторы, профессор ЗӨФӘР РӘМИЕВ алып бара.

ЯКУПОВ РИФ ХӘЙБРАХМАН УЛЫ (1940-2011), журналист, тукайчы, укытучы. Ул, Казан дәүләт университетын тәмамлап, ТРның Балтач районы газетасында эшли башлаганда, аеруча Тукайның тормыш юлы һәм иҗаты белән кызыксына башлый. 1973-1975 елларда Казан университетының татар теле һәм әдәбияты бүлегендә аспирантурада укый, профессор И.Нуруллин җитәкчелегендә «Габдулла Тукайның тормыш юлы» дигән темага кандидатлык диссертациясе яза, ләкин төрле сәбәпләр аркасында аны якламый кала. 1975 елның сентябрь ахырында кабул ителгән, Тукайның тууына 90 ел тулуны лаеклы каршылау турындагы карар нигезендә, Яңа Кырлай авылында Г.Тукай музееның яңа бинасын төзү бурыч итеп куела. 1976 елның октябрендә башланып киткән төзелеш эшләрен Риф Якупов дәвам иттерә. 1977 елда Р.Х.Якупов музейга директор итеп билгеләнә. Аңа кадәр бу вазифаны экскурсоводлар, соңрак авылның китапханә мөдире башкарган. 1977-1978 елларда Риф Якупов Кырлайдагы Тукай музеенда директор булып эшли. Авылда ул Тукайны тәрбиягә алган Сәгъди Салиховның энесе — Сәйфетдин абыйның кызы — Мифтахова Нәгыймә апада яшәгән.

1976 елда Р.Якупов И.Нуруллин белән берлектә «Тукай турында хатирәләр» китабы бастыра. Төзүчеләр, Тукайның тормыш юлын тагын да тулырак чагылдыру максатыннан, «Тукай турында замандашлары»нда (1960) урын алган күп кенә ышанычлы истәлекләрне яңа хатирәләр белән тулыландырып, яңа җыентык тәкъдим итә. Ул Г.Тукайның тормышын архив чыганакларыннан җентекләп өйрәнә, иҗатын бөртекләп җыя, күп фактларга ачыклык кертә. Бу яктан аның «Архивтагы язулар ни сөйли» исемле язмасы аеруча мөһим. Р.Якупов моңа кадәр игътибардан читтәрәк калган ышанычлы чыганакка — метрикә кенәгәләренә мөрәҗәгать итте. Аларны җентекле өйрәнү нәтиҗәсендә, ул Габдулла анасы Мәмдүдәнең (ире Мөхәммәтгариф үлгәннән соң) Сасна Пучинкәсенең указсыз мулласы Мөхәммәтшакир Фәйзуллинга кияүгә бирелү (никах укылу) көнен (1888 ел, 22 декабрь), егерме алты яшендә эч китү авыруыннан вафат булуын (1890 ел, 18 гыйнвар) ачыклады. Димәк, Тукай 3 яшь тә 9 айлык чагында тома ятим калган. Кыскасы, Р.Якуповның бу юнәлештәге эзләнүләре Тукайның Өчиледә, Сасна Пучинкәсендә уздырган гомер мизгелләрен конкретрак күзалларга мөмкинлек бирә. Тукай тормышы Сасна авылын һәм аны киләчәк буыннарга калдыруга да җитди өлеш кертә. Р.Якупов Зәкия Рәсүлеваның «Тукай эзләреннән» китабының (1985) фәнни редакторы булды, андагы текстларны бик мөһим эчтәлекле бит асты төшермәләре белән баетты. Аның барлык мәкаләләре дә өр-яңа һәм ышанычлы фактларга нигезләнеп язылган.

Фәния Фәйзуллина,
Г.Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты фәнни хезмәткәре ■

Әсәр

Тукай турында хатирәләр (төзүчеләр һәм текстларга аңлатма бирүчеләр: Ибраһим Нуруллин, Риф Якупов). — Казан: Тат.кит.нәшр., 1976. — 192 б.; Якупов Р. Архивтагы язулар ни сөйли // Казан утлары. — 1976. — №3. — Б.145-152.

Әдәбият

Нафигов Р.И. Наш Тукай. — Казань, 1998. — С.21; Шәфигуллин Р. Сәнгатебез күкләрендә — кояшыбыз, аебыз, бар җиһанга күренерлек кадерле Тукаебыз! // Шәһри Чаллы. — 2011. — 15 апрель; Хушлашу сүзе // Шәһри Чаллы. — 2011 ел. — 16 ноябрь.

ТАТАР КИТАБЫ = ТАТАРСКАЯ КНИГА: альбом / [төз.-авт.: Р.Ф.Мәрданов, И.Г.Һадиев; рәссамы Ш.К.Насыйров] — Казан: Татар. кит.нәшр., 2013. — 504 б.

Бу альбомда Урта гасырлардан алып хәзергәчә таралыш алган әдәби-нәфис, фәнни, дини-иҗтимагый әчтәлектәге һәм төрле тармакларга караган татар китапларының аерым үрнәкләре тупланды. Кереш мәкаләдә татар китабының бай һәм катлаулы тарихы турында киңкырлы мәгълүмат бирелде.

КИТАПТАН ЦИТАТА: «Татар кульязма китабының мең елдан артык тарихы бар, дип хаклы рәвештә әйтә алабыз. Чөнки Идел-Урал буйларына гарәп язуы үтеп кергәч тә, Коръән һәм башка дини китапларны күчереп язу, шул рәвешчә тарату, мәктәпләр өчен дәреслек-кулланмалар булдыру тормышка ашырыла башлаган. Гарәп язуы һәм гарәп теле мөселман төрки-татарларының рухи тормышында озак дәверләр мәртәбәле урын биләп килгән».

КАРӘХМӘТНЕҢ СОҢГЫ КӨННӘРЕ

2006 елның язында, халкыбызның сөекле улы бөек Тукаебызның тууына 120 ел тулуын билгеләп үткән көннәрдә, Татарстан радиосының әдәби-драматик тапшырулар редакциясенә Ленинград өлкәсеннән бер хат килеп төште. Хат авторы – Бикмурзин әфәнде (фамилиясе генә язылган иде) үз язмасында мәшһүр бер поэманың төп каһарманнарыннан берсе – атаклы Карәхмәтнең соңгы көннәре турында кызыклы гына мәгълүмат бирә. Аны сезнең игътибарга да тәкъдим итәм.

Рөстәм Акъегет

«Миңлебай! Бар, тиз, Карәхмәтне чакыр!» —
Чапты китте Миңлебай чатыр-чатыр.
Үтмәгәндер күз ачып йомган заман,
Килде дә җитте Карәхмәт — каһреман,
— ди Тукай үзенең поэмасында.

«Кем соң ул Карәхмәт? Ни өчен Миңлебай аның артыннан чаба? Укучы бу сорауларга җавапны тиз табар. Карәхмәт — сөекле Тукаебызның «Печән базары, яхуд Яңа Кисекбаш» (1908) әсәрендәге төп геройларның берсе, дияр ул. Күбрәк белгәннәре Карәхмәтнең Казанда бертуган Никитиннар циркында чыгыш ясап, агай-энене шаккаттырган төрек пәһлеваны икәнен дә чамалар. Тукай турында

«Печән базары, яхуд Яңа Кисекбаш» поэмасына иллюстрация. Рәсемнең авторы Габдулла Тукай үзе булу ихтималы да бар. 1908-1910 еллар

истәлекләрне, профессор Ибраһим Нуруллин китапларын укыганнар исә, бөек шагыйрьнең, бу мәшһүр поэмасын язгач, үзенең дә Карәхмәттән «шүрләп» йөргәнен өстәр. Шүрләрсең дә, «син аның йодрыкларын күргәнең юкмыни?» Җитмәсә, Карәхмәт «Болгар» кунакханәсендә Тукайдан берничә номер аша гына яшәгән.

Балачактан ук күңелгә сеңеп калган бу әсәр герое белән миңа күп еллардан соң тагын бер тапкыр «очрашырга» туры килде. Эш болай булды. Алтмышынчы елларда мин Новосибирск шәһәренең бер предприятиесендә эшли идем. Бервакыт безгә атлет гәүдәле бер карт эшкә урнашты. Көннәрдән беркөнне ул, минем кулда рус баһадиры Иван Поддубный турындагы китапны күргәч, болай диде: «Әгәр дә сез көрәшчеләр белән кызыксынасыз икән, миндә алар турында бер альбом бар, теләсәгез күрсәтә алам». Һәм, чыннан да, икенче көнне минем өстәлемдә бик пөхтә итеп ватман кәгазеннән эшләнгән альбом ята — ул вакыт узудан саргайган газета мәкаләләре, төрле фоторәсемнәр белән тулган иде. Анда кемнәр генә юк… Саргайган фоторәсемнәрдә — мәшһүр көрәшчеләр: И.Поддубный, И.Заикин, Чуркин, Али Борһан һ.б. Альбомның

Э.Гельмс. Тукай поэмасына иллюстрация.
Кәгазь, акварель, тушь, каләм

бер битенә атаклы көрәшче Карәхмәт турында нindидер бер газетадан кисеп алынган мәкалә урнаштырылган. Йотлыгып укырга керештем. Укырсың да — анда Карәхмәтнең соңгы көннәре хакында язылган. Мәкаләдән шул мәгълүм булды: Беренче бөтендөнья сугышы вакытында Көньяк фронтта авыр яраланган Карәхмәт рус гаскәрләренә әсир төшә. Озакламый ул авыр яралардан үлеп тә китә. Кем кулында диген?! Әле студент елларында ук берничә тапкыр Карәхмәт белән келәмдә бил алышкан һәм пәһлеван төрекне сыртына салган хәрби хирург, доктор Войцеховский кулында…»

Бикмурзин,
Ленинград өлкәсе

Б.Урманче. «Печән базары, яхуд Яңа Кисекбаш» поэмасына иллюстрация. 1966 ел.
Кәгазь, акварель, тушь, каләм

АВЫЛ ӨСТЕНДӘ ЙОЛДЫЗЛАР

1952 елның октябре

Татарстан Язучылар союзы (Бауман урамы, 19 нчы йорт) коридорындагы игъланнар тактасында мондыйрак эчтәлектә бер белдерү пәйда була: «21 октябрьдә, кич сәгать 7дә, прозаиклар секциясенең чираттагы утырышы була.

Көн тәртибендә:

1. Ф.Хөснинең «Авыл өстендәге йолдызлар» *(Соңыннан ул, бераз үзгәртелеп, «Авыл өстендә йолдызлар» исеме белән аерым китап булып басылып чыгачак. — Л.Л.)* исемле повестен укып тикшерү.

2. Ш.Маннурның секция исеменә биргән гаризасын карау.

Утырышка чакырылалар: Г.Бәширов, Г.Гобәй, Г.Иделле, А.Шамов, Ә.Еники, Ф.Хөсни, Г.Әпсәләмов, И.Гази *(утырышта катнашырга тиеш булган язучылар, әйтик, Г.Иделле, Ә.Еники, Ф.Хөсни, И.Гази һәм Х.Садри иптәшләр үзләренең фамилияләре турысына имзаларын сырлап куйган. — Л.Л.)*.

Секция бюросы».



Әйтелгән көнне, ягъни 1952 елның 21 октябрендә проза секциясенең чираттагы утырышына түбәндәге язучылар килә: Гомәр Бәширов, Афзал Шамов, Ибраһим Гази, Әмирхан Еники, Фатих Хөсни, Гариф Гобәй, Газиз Иделле, Халик Садри.

Мәгълүм көн тәртибе үзгәрү сәбәпле (урыннары алышына), әүвәл Шәйхи Маннурның нефть турындагы очеркларын русчага тәрҗемә итү мәсьәләсе карала һәм ул уңай хәл ителә. Икенче көн тәртибенә куелган мәсьәлә буенча секция рәисе *(ул чакта — председатель — Л.Л.)* Афзал Шамов сүз башлый.

Афзал Шамов:

— Фатих Хөсни кечкенә хикәяләре белән генә түгел, «Җәй башы» дигән

зур гына повесть та *(әлеге әсәр 1950 елда дөнья күрә. — Л.Л.)* биргән язучы. Бу повесть бездә әйбәт тәэсир калдырган иде. Шуннан соң язылган «Авыл өстендәге йолдызлар» повесте, нигездә, уңай тәэсир калдыра. Караңгыланып килүче авыл картиналары, киң кырлар күңелдә кала. Образлар күп. 20ләп бар. Шулардан Айдар, Гафиятулла, Тәскирә, Халидәләр күңелдә кала. Образларның эшләнешенә килгәндә, Айдар беркадәр «Йөзек кашы»ндагы Айдарны хәтерләтә. Айдар — партия члены. Характеры кискен. Тискәре ягына артыграк басым ясалган. Бу ягы белән килешеп бетә алмыйм. Производстводагы тормышлары сайрак. Портретлары бирелми. Бары бер Гафиятулланың портреты ачык. Гафиятулла гражданнар сугышында, Ватан сугышында булган, Донбасста эшләгән.

Колхозның урта бармагы. Ләкин аның тискәре яклары бар. Улын йорт салу өчен авылга чакыра.

Тәскирә — образ буларак, әйбәт тәэсир калдыра. Шулай да ул «Җәй башы»ндагы Мөнирәдән түбән. Аның Социалистик хезмәт герое булуы эшендә күрсәтелми. Үсүе автор теле белән бара.

Халидә — зәһәр кыз. Кашларын сикертеп, биеп тора. Кайчакта ырылдап та ала. Үзенекен үз итә.

Менә болар дүртесе — мөмкин кадәр тулырак эшләнгән кешеләр.

Александров белән Ихсанов ачылып бетмәгән.

Тел мәсьәләсендә оста әйтелгән образлар, сүзләр, бер-ике сүз белән генә образларны сызып җибәрү бар. Шулай да күңелне төшерә торган, эшләнүне таләп итә торган җөмләләр бар. Тәскирәнең хаты автор теле белән язылган. Детальләрдә кабатлау күп. Мәсәлән, «тишек баш».

Табигать күренешләре әйбәт бирелә. Игътибарсызлык бар. Кар бетмәгән, шомырт чәчәк аткан. Әсәр, нигездә әйбәт, басылырлык. Ләкин төзәтелергә тиешле.

Фатих Хөсни

Газиз Иделле сүз башлый:

— Әсәр әйбәт тәэсир калдыра. Вакыйга МТС тирәсендә бара. Ләкин МТСта түгел. Әсәрне укып бетергәч кенә повестьның идеясе ачыла. Шәхси як белән иҗтимагый якларның бирелеше. Бакчалар белән шашып йөри торгач, Гафиятулла үлеп китә. Аның юлына Айдар керә. Ләкин ул монда кинәт айнып китә. Тик бирелә кайбер очы очка ялганмаган нәрсәләр бар.

Айдар мәхәббәте, бытта *(көнкүрештә. — Л.Л.)* образ булып йөри, производствога чыктымы — тоныклана. Кайбер детальләр мәсьәләсендә. Сәгатьле график уенгарак әйләнеп китә. Бу нәрсә ачылмый.

Александров (парторг) — образ буларак, бик зәгыйфь. Партия вәкилен бирә алмау бездә традиция булып килә инде.

Бу әсәргә көч куелган, ләкин берьяклы эшләнгән.

Гариф Гобәй нотык тота:

— Әсәр нигездә әйбәт. Көнкүреш һәм производство мәсьәләләрен күтәрә. Бу ике як икесе дә тулы итеп ачылмаган. Фатих шәхси якка кырын карый. Җимерелгән өен төзәтергә

Гариф Гобәй

Гомәр Бәширов

йөргән Гафиятуллага кырын карый. Шәхси эшләрне катлауландыра. Бу дөрес түгел. Ил өчен күп көч куйган Гафиятуллага МТС өмә тәртибендә дә өй салып бирә алган булыр иде...

Айдар образы турында дөрес әйтеләр. Ул башта күз алдына саф мәхәббәтле, эшлекле кеше булып күз алдына килә, аннары түбән төшә башлый. Әтигә килен кирәккә өйләнә.

Гафиятулла образы шулай ук каршылыклы. Иҗтимагый эштә алдынгы булып йөргән кеше бөтенләй түбән тәгәри.

Теле, һичшиксез, әйбәт. Кайбер урыннарда тигезсезлекләр бар. Өченче бүлек газета теле белән башлана.

Ибраһим Газига сүз бирелә:

— Фатих авыл тормышын беләә. Ә МТСны белеп бетерми, теше үтми. Ике сызык аерылып тора. Вакыйгалар мәҗбүри ачылып бармыйлар, берсеннән-берсе чыкмыйлар производство тармагында. Шуңа күрә яз көне тагын бер МТСны өйрәнеп кайтсын иде. Бу повесть «Җәй башы»ннан ким булмасын иде.

Әмирхан Еникига чират җитә:

— Авторның ашыкканлыгы бик нык сизелә. Шуңа күрә вакыйгаларны бер җепкә табигый итеп тезә алмаган. Авторның әйтәсе фикере дә бик анык булмаган, ахры. Төп идеясе ачык түгел. Производстводан башлап, аны ташлап көнкүрешкә кереп китә.

Гафиятулла чынлап та гайрәтле карт. Тик ул повестьны бөтенләй бозып ташлый. Айдар белән Тәскирә арасындагы конфликтны хезмәт процессында алырга иде. Тәскирә белән Айдар арасын бозмаска иде.

Гомәр Бәширов сүз ала:

— Фатих механизаторларны алуы һәм семья мәсьәләсенең катлаулы ягын алуы белән дөрес эшләгән. Кешеләр арасындагы чатаклыклар әле соңга табарак та булыр ул. Шуны хәл итү мәсьәләсендә сүз булырга мөмкин. Гафиятулланың характеры соңга таба дөрес үсештә бармый.

Айдар «Йөзек кашы»ндагы Айдардан өстен булырга тиеш. Фатих менә шул ягын уйласа, дөрес булыр иде.

Мәхәббәт турысында да производствода «чәкәштерү» уңышлырак булыр.

Айдарның Тәскирәне ташлап, Халидәгә өйләнүе фаҗига булып калса, моның тәрбия ягыннан да файдасы булыр иде. Механизация мәсьәләсенә аз урын бирелмәгән, ләкин художество ягы сыек. Телендә кайбер нәрсәләр бик кабатлана. Бу әсәрнең теле күп урында

Ибраһим Гази

Әмирхан Еники

начар. Күпсүзлелек бар. Тургайлар, сандугачлар бик сайрый. Кайбер нәрсәләр белән бик мавыгу бар. Аксак алаша. Тәрҗемә теленә охшаган урыннар бар. Комментарийлар бирү кирәкми иде.

Иптәшләр бик әйбәт киңәшләр бирделәр. Мин иптәшләргә кушылам. Эшләгәндә әйбәт әсәр чыгачак. Өйрәнергә-чыгарга хәзер үк кирәк.

Ниһаять, автор — **Фатих Хөсни** үзе сүз дилбегәсен кулына ала:

— Иптәшләр әйбәт сөйләделәр. Ашыкканлыгымны үзем дә белдем. Иптәшләрнең чыгышларында уйландыра торган нәрсәләр бар. Берсүзсез кабул ителерлекләре бар. Барысын да язып алдым. Мин мөмкин кадәр шушы тормышта булган каршылыкларны ышандырырлык итеп бирергә тырышачакмын. Менә иптәш Бәширов Айдарның Тәскирә белән Халидәгә мөнәсәбәтендә уйландыра торган фикер әйтте.

Производство тормышын көчәйтергә кирәк. Көчтән килгән кадәр ул ягын эшләргә тырышырмын.

Гафиятулла образын аңлап җитмәделәр кебек тоела миңа. Ул комик планда хәл ителгән иде. Барсы да җитди, бар да эш белән йөриләр. Менә шулчакта Гафиятулла («Гайрәтулла») үз йорты, шәхси интереслары белән мавыгып йөри. Кешедә артка чигү бик була торган хәл.

Практик эшләү ягына ашыкмыйм әле. Бик нык эшлисе бар. Җентекләп эшләргә тырышырмын.

Гариф Гобәй кабат сөйли:

— Фатих Хөснинең соңгы сүзендә әсәрне бик нык эшләргә теләмәве сизелде. Производство темасына повесть та булгач, материал гына җитми. Производство белән көнкүреш бер-бөтен булып үсәргә тиеш. Конфликтлар мәсьәләсендә дә уйларга кирәк. Төп геройларның (Айдар, Гафиятулла) артка таба чигүләре урынсызрак. Мәхәббәт җимерелүдә дә ныклы дәлил кирәк.

Ибраһим Гази да янә сүз әйтергә була:

— Төп нигез — производство икән, менә шуңа басым ясарга кирәк. Төп конфликтны шуңа корырга кирәк.

Председатель
Секретарь

Искәрмә:

Фатих Хөснинең «Авыл өстендә йолдызлар» повесте китап булып, 1955 елда басылып чыга (Казан:Татар. кит. нәшр., 1955. — 198 б. — 10000 данә).

Беркетмәне Ләбиб Лерон укыды. ■

ҖЫРЫ КАЛДЫ

Марс Макаров

Чүмбәлинең иген кырларыннан башлап, Муса Җәлил исемендәге Татар дәүләт академия опера һәм балет театры сәхнәсенә кадәр юл узып һәм шул сәхнәдә 25 ел буе хезмәт куйган, инде «Халык артисты» дигән дәрәҗәле исемгә кадәр лаек булган Хәйдәр Бигичев иң матур, гөрләп чәчәк аткан вакытында кинәт китеп барды.

1998 ел. Ноябрьнең салкын көне китергән кайгылы хәбәр, яшен тизлегедәй республикабызның төрле почмакларына барып җитте…

Хәйдәр белән танышуым, бергә аралашкан елларым турында кайбер хатирәләр белән уртаклашасым килә.

Алтмышынчы еллар ахырында миңа, Муса Җәлил исемендәге опера һәм балет театры артистлары белән бергә, Нижгар өлкәсенең «Кызыл Октябрь» төбәгенә гастрольгә чыгарга туры килде.

Әле бүгенгедәй хәтеремдә; җәй аеның кызу көннәрендә, Чүмбәли авылының зур булмаган иске агач клубына безнең концертыбызны карарга бик күп мишәр милләтәшләребез җыелган иде. Җырчыларга кушылып баян тартып утырганда, ничектер, мин бөдрә чәчле башын кыңгыр салып, алдагы рәтләрнең берсендә утырган бер егеткә игътибар иттем. Ул үтә дә нурлы күзләрен опера җырчыбыз Зөләйха апа Хисмәтуллинага төбәп, онытылып, хискә бирелеп, аны тыңлап утыра иде. Бу егетнең башкалардан үзенең җитдилеге һәм моңсу йөзе белән аерылып торганы әле дә күз алдымда. Йөзе, ничектер, ятим баланың моңсу йөзен хәтерләткәндәй тоелды шулчак миңа.

Икенче елны безгә шул ук бригада белән Чүмбәлигә янә концерт белән килергә туры килде.

Концерт башлануга мин уйчан йөзле, бөдрә чәчле былтыргы егетне шунда ук танып алдым, Бу юлы да ул залның беренче рәтендә утыра иде.

Программабызның беренче бүлеге тәмамлангач, бу егет сәхнә артына керде, чәй йотып утырган артистларга күз ташлап, нидер әйтергә теләгән сыман бераз басып торды да, аннан соң тиз генә тамаша залына кире төшеп китте,

Концертның икенче бүлеге беткәч, сәхнә артына кабат менде. Бу юлы ул инде үзен бераз кыюырак тотты кебек. Минем янга килеп, кеше юк микән, дигәндәй як-ягына каранганнан соң: «Марс абый, мин сездән тавышымны тикшертмәкче идем, мөмкин булса «Карурман» көен җырлап күрсәтер идем, — диде. — Бәлки, берәр киңәш бирерсез?» Риза булдым. Ул минем баян клавиатурасының кайсыдыр төймәсенә басып, җырлаячак җырының нинди тонда булырга тиешлеген искәртте.

Илһам Шакировның тавышына карата да «борынга җибәрә», дигән фикерләрен ишетергә туры килгәләде. «Тавышы болай ярыйсы, әмма операга бик үк ярап бетмәс, моңлы тавыш белән опера сәхнәсенә килеп, ул әллә ни майтара алмас», — дип, Зөләйха апага каршы төште. Ә аннары, бераз йомшара төшеп: «Филармониягә барырга кирәк, анда белем сорамыйлар», — дип тә әйтеп куйды.

Сораштыра торгач, Хәйдәрнең Рәшит Ваһаповның нәсел тамырыннан икәне ачыкланды. Ул әтисе белән бергә комбайнчы булып эшли икән. Хәйдәрдән кала, кече сеңелләренең дә җырлау буенча авылда дан тотулары турында мәгълүмат алдык.

Икенче көнне Хәйдәр безне клуб янында озатып калды...

Җырның беренче куплетыннан ук мин аның күкрәк, тын басымының көчле булуына төшендем (консерватория бетергән диярсең!). Шулчак бу һәвәскәр җырчының үзенчәлекле тавышына әһәмият биреп булса кирәк, безнең янга Зөләйха апа белән опера җырчысы Идеал Ишбүләков тә килеп басты. Зөләйха Хисмәтуллина Казан консерваториясенең вокал классы буенча укытучысы (соңрак профессор), җырчы һөнәрен сайларга теләгән яшьләрнең һәрвакытта да күңелен үстерә белә торган шәхес иде. Бу юлы да ул, гадәтенчә, яшь җырчының тавышын үтереп мактарга кереште:

— Син, энем, укымыйча, болай да җырчы була аласың, ләкин консерваториягә кереп, музыкаль белем дә алсаң, тагын да әйбәтрәк булыр!

Ә менә Ишбүләков исә, Зөләйха апага капма-каршы шәхес буларак, авылның үзешчән җырчыларына бераз кырысрак мөнәсәбәттә иде. Заманында безгә, аның яшь җырчыларга гына түгел, хәтта

Чүмбәлидә булганга дүртбиш ел узганнан соң, мин Казан консерваториясенең 4 нче курс студенты булып өлгергән Хәйдәр Бигичев белән икенче мәртәбә Казанда очраштым.

Җилле-яңгырлы көз айларының бер кичендә, көтмәгәндә, урта буйлы, аксыл чәчле, сылу гәүдәле бер кыз белән Хәйдәр минем фатирыма килеп керде. Ул чәчләрен шәһәрчә бераз үстереп җибәргән, киемнәре, бик үк затлы булмаса да, чиста, пөхтә, сөйләшүендә мишәр акценты бераз кимегән кебек. Мин җитди йөзле, авызын матур гына турсайтып янында басып торган яшь туташның кем булуын сорадым. Бу кыз, Хәйдәргә сүз әйтергә дә ирек бирмичә, үзе сөйләп китте: «Марс абый, Сез минем тавышымны радио аша ишеткәнегез дә бардыр, мин Зөһрә Сәхәбиева дигән җырчы. Без — Хәйдәр белән консерваториядә бергә укыйбыз».

Чәй янында озак кына сөйләшеп утыра торгач, миңа яшьләрнең өйләнешү планнары белән йөрүләре мәгълүм бул-

«Өйләнешеп башлы-күзле булган Хәйдәр һәм Зөһрә белән миңа күп мәртәбәләр кичәләрдә катнашырга туры килде...»

ды. Тик бу хыялларына фатир мәсьәләсе киртә булып тора икән. Зөһрә Казан консерваториясенең күптән түгел генә ачылган халыкча җырлау бүлегендә, Зөләйха Хисмәтуллина классында, Хәйдәр кебек үк, 4 нче курста укый икән.

Консерватория ректоры Нәҗип Җиһанов Хәйдәргә: «Бернинди филармониягә дә бармыйсың, диплом алуга сине опера театрына җибәрәбез», — дип әйткән.

Чәйдән соң без пианино янына елыштык һәм Хәйдәр җырлап җибәрде. Тавышының яхшы якка үзгәрүенә минем һушым китте. Ул югары ноталар белән җырлаганда бөтен бүлмә дерелдәп торган сыман тоела иде. Итальянча көчле күкрәк, тын басымы белән җырлау, гомумән, Хәйдәргә хас сыйфат иде һәм бу аңа тумыштан ук бирелгәндер, күрәмсең. Консерватория тәмамлаган, тенор тавышлы җырчылар өчен авыр булып саналган югары — «ля», «си», хәтта — «до» ноталарын җиңел алуы истә калган. «Алтынчәч» операсыннан Җикмәргән ариясен җанлы итеп җырлавына күңелем күтәрелгәч, чыннан да, Хәйдәр безнең милли җырчыларыбыз арасында иң асылларыннан берсе ахры, дигән уй чагылып киткән иде.

Вакыт бик соң булу сәбәпле һәм минем өйдә ялгызым гына икәнне дә исәпкә алыпмы, студентлар миндә кунып китәргә булдылар һәм без яңадан чәй өстәле артында озак кына сөйләшеп утырдык. Акча проблемасы хакында сүз чыккач, Хәйдәр миңа җәй көне туган ягы — Нижгар өлкәсенә концерт белән гастрольгә чыгарга тәкъдим ясады. Шуннан соң, инде өйләнешеп башлы-күзле булган Хәйдәр һәм Зөһрә белән миңа күп мәртәбәләр кичәләрдә катнашырга туры килде.

Хәйдәрнең кан басымы гел югары булуы истә калган. Зөһрә үзе белән гел кирәкле дарулар йөртә иде. Авылда иген кырларында эшләп чыныккан әвен кебек ир-атның исәнлегеннән зарлануы, ничектер, күңелгә шом сала иде. Гастроль вакытында концертны икенче көнгә күчерү очраклары да аз булмады. Ләкин Хәйдәр моңа тешетырнагы белән каршы тора иде.

Инде ул консерваторияне тәмамлап, опера театрында эшләгән вакытта мин театрның баянчы-концертмейстеры идем. Хәйдәр Бигичев, Зилә Сөнгатуллина, Рафаэль Сәхабиев, Мөнир Якупов, Галина Казанцева һәм башка театр артистлары белән Советлар Союзының төрле почмакларында һәм үзебезнең республика төбәкләрендә концертлар белән йөрергә туры килде.

Опера театрындагы хезмәттәшләренең әйтүенчә, ул, авыруына да карамастан, һәрвакыт үзен-үзе бетереп эшләгән. Оркестр тавышын басып, операда көчәнеп җырлау исәнлегенә зыян китергәнен белсә дә, опера жанрыннан китүне куркаклык дип санаган.

Нәҗип Җиһановның «Муса Җәлил» операсында Муса партиясен башкарып, спектакль тәмамлангач, Зөһрә ханым ире өчен борчылудан йөзләре киткән хәлдә, укол шприцлары белән сәхнә артында еш көтеп тора иде.

«Искусство требует жертв» — дигән гыйбарәнең мәгънәсе бу очракта сәхнә артистының үлем фаҗигасында тагын да тирәнрәк ачыла кебек. Муса Җәлилнең Моабит төрмәсендә көчле рух халәтендә иҗат ителгән түбәндәге шигъри сүзләре, минемчә, Хәйдәрнең иҗат язмышына да тәңгәл килә кебек:

Сездә минем бөтен тойгыларым.
Сездә минем керсез яшьләрем,
Сез үлсәгез, мин дә онытылырмын,
Яшәсәгез, мин дә яшәрмен. ■

«ТЫҢЛАР ИДЕМ ТАВЫШЫҢНЫ...»

Хәбир Ибраһим
Хикәя



Х.Латыйф рәсеме

Якты кояш сине күрә,
Чәчләреңнән назлый җилләр генә.
Кояш, җилләр, юл күрсәтеп,
Очраштырмый безне җирдә нигә?

Ул җырлый да, җырлый. Юк, ул җырламый, аңардан иксез-чиксез моң агыла. Моң дәрьясы аның күңел түреннән ургылып чыга да, тыңлаучының йөрәген өзгәләп, бар булган җиһанга тарала. Кая гына барса да, кайда гына чыгыш ясаса да, аңардан гел шуны җырлавын сорадылар. Яратты халык шул җырны. Ләкин ул һәрвакытта да тамашачының соравын үтәргә ашыкмады. Андый да тирән сагыш тулы моңлы җырны башкарыр өчен җырчыдан аерым бер күңел халәте, дәрт һәм илаһи көч таләп ителә иде. Залда утырган тамашачылар арасында: «Җырласа ни була инде?!» – дип канәгатьсезлек белдерүчеләр дә табыла иде. Җырчы, олуг җырчы юк-бар сүзләргә игътибар бирми, программага кергән чираттагы җырын башкара. Яңа җыр яңгырый, халык гөрләтеп кул чаба. Ләкин концерт беткәнче, шул җырны җырлар дип өметләнеп утырган тамашачының өмете акланмый, җыр башкарылмый һәм матур гына узган җырлы тамашага нидер җитмәгән кебек кала…

Хәл начар. Йөрәк, урыныннан купкандай, үлеп-бетеп сызлана. Йөрәк тузган. Табиблар аңа берничә мәртәбә

хастаханәгә ятарга кушты. Тыңламады. Рәхәтләнеп йөгереп йөргән илле яшьлек ир кеше бит әле ул! Илле яшьтә әле тормыш башлана гына, диләр. Юк шул, табибларның сүзенә дә колак салу кирәк икән. Ул, хәле бетеп, пәрдәсе аз гына ачык торган тәрәзә каршына килеп сөялде. Ул шулай җырларга чыгар алдыннан, сәхнә пәрдәсен аз гына ачып, тамашачы җыйналган зал ягына карап алырга ярата иде. Залда кемнең утыруына карап, ул нинди җыр һәм аны ничек башкарачагын уйлап куя.

Ул кышкы урамга, ишегалдына күз салды. Тын. Ябалак-ябалак кар ява. Балалар мәйданчыгында берничә нәнүс бала, чырык-чырык көлеп, шугалакта чана шуып (балалар бәхетле булмыйча, кем бәхетле булсын ди инде!) йөри, ә подъездан затлы тун кигән бер гүзәл ханым чыкты. Байбичә, вәкарь генә пультка басып, ялтырап торган кара иномаркага кереп утырды. «Тойота», бик зур тизлек алып, кисәк кенә урыныннан кузгалды. Йөрәк кабат аның күкрәген китереп кысты. «Ашыгыч ярдәм» машинасы чакырылган (аны хатыны чакыртты). Тиздән килеп җитәр инде...

Кайчан гына очрашырбыз?
Онытыр идем сагышымны,
Күкрәгемә кочып, елый-елый,
Тыңлар идем назлы тавышыңны...

Назлы дигән сүзне ул «назлый» дип җырлый һәм шуның белән ул бу җырга яңа төрле музыкаль чагылыш, яңа төсмерләр биреп ала торган иде. «Тавышыңны...» – ахырдан ул аны берничә нотага югары күтәреп җибәрә (тавыш диапозоны киң!), шуның белән ул тыңлаучыны тетрәндерә һәм инде соңыннан, «синең назлы тавышыңны» дип җырлап, тавышын түбән төшергәндә дулкынланудан тәннәр чымырдап китә, күзгә яшь тула...

Ул беркайчан да ялгызлыктан интекмәде. Ул һәрвакыт игътибар үзәгендә булды. Сабыр, тыйнак авыл баласы кала тормышына ансат кына ничек ияләшсә, дан вә шөһрәткә дә бик тиз күнекте. Кая барса да, кая гына йөрсә дә аны таныйлар, аның белән күрешеп, сөйләшергә тырышалар иде. Баштарак күңелле булып тоелган мондый күрешүләр, аралашулар соңыннан аны туйдырды һәм ул чит кешеләрдән кача башлады. Җырчының гомере кыска, диләр. Билгеле, моны туры мәгънәдә аңларга ярамый, җырчы кеше яше белән туксанга да, йөзгә дә җитәргә мөмкин. Популярлык чоры кыска. Моңа ул күп тапкырлар инанды. Кеше, тормышны аңлап өлгергәнче, сукырларча яши икән. Аның күзен бервакыт урам чатында симәнке сатып торган кеше ачты. Ул башта аны танымады. Ябыккан, суырылган. Таныгач, күзләре маңгаена менде. Һай! Татарның атаклы җырчысы түгелме соң бу?! Ул бит яшьтән үк аның моңлы җырларын тыңлап үсте, аңар сокланды, әгәр дә җырчы була калса, бары тик аның кебек җырлый белергә кирәк, дигән уй белән яшәде. Халык оныткан үзен... Халык кына түгел, дәүләт тә! Гастрольләрдә тиен акчага җырлап, кар-буран дип тормыйча, эт типкесендә йөреп, филармония начальствосын баеткан бөек җырчы, ни кызганыч, урам чатында симәнке сатып утыра. Ирексездән, аның йөрәге кысылып куйды һәм беренче тапкыр ул үзен бу дөньяда ялгыз итеп тойды. Ул аның янына барып, җилкәсеннән кочып, аңа кул бирергә теләде. Тик ни өчендер туктап калды. Танышлар иде бит, югыйсә. Күңелендә кыенсыну һәм читенсенү хисе өстенлек итте. Аннан ул вакытта алар икесе ике төрле орбитада очалар иде: берсе дөнья тирәли, ә икенчесе урам буйлап...

Зал ягына хатыны атылып керде. Мескеннең коты чыккан. Иренең йөзе, мәрмәр сыман, ап-ак булган... «Хәзер килә!» Йөрәгенең сызлавына, авыртуына түзәрлек түгел – йодрыгын кысып кына түзде. «Карчык! – дип пышылдады ул төсе качып (бу хәлнең ахыры яхшылык белән бетмәячәген сизенә иде булса кирәк!). – Врачларга ышанып бетмим, ташлама мине, яме...» Хатыны аның акрын гына җилкәсеннән кочты... «Ташлыйммы соң!»...

Ул ире өчен җан атып яшәде. Иҗат кешесе белән яшәү бигүк җиңел булмаса да, иренең танылган җырчы булуы хатынның күңелендә һәрчак горурлык хисе яшәтте. Төрле чаклары булды – үпкәләшкән, көнләшкән вакытлар да. Нишлисең, публичный кеше шул ире! Ләкин башкаларның шундый танылган кеше белән яшәвенә көнләшеп караулары әнә шул тормыш ямьсезлекләрен тигезли дә куя иде. Ире аны өйләнгәннән соң озак эшләтмәде, өйдә генә утыртты. Иренең дусларын, танышларын каршылап, аларны кунак итү, табын әзерләү һәрчак хатын өстендә булды. Ул бу вазифаны бик теләп, сөенеп, җиренә җиткереп үтәде. Башта ир бала туды, ул инде хәзер зур, өйләнеп, башка шәһәрдә яши. Ә менә абыйсыннан соң туган кечкенә кызлары ел да алты ай яшендә кинәт кенә вафат булды…

Кемнәр генә сине белә,
Нурлы йөзләреңне көн дә күрә?
Эзләп тапсам сине ал таңнарда,
Уятырмын назлап үбә-үбә…

Каян гына килеп керде соң бу җыр аңа? «Баламишкин»нарны тыңлап үскән авыл халкына гына түгел, аны бөтен дөньяга чыгарырлык һәм яңгыратырлык җыр түгелме соң бу? Ире җырлаган һәр җырны үз һәм якын иткән хәләл җефете дә бу җырны башкалардан аерып куя торган иде. «Нәрсәсе белән ошый соң ул сиңа?» – дигән сорауга, җырны җырдан аера белгән хатыны: «Җылылык бар анда ниндидер!» – дия иде…

Каян килеп керде һәм ничек туды соң бу җыр? Җавабы да тормыш кебек гади: шагыйрь сүзләрен язган, композитор көен чыгарган, ә җырчы шул җырны башкарган. Җыр авторы белән бер күрешкәч, ул шагыйрьгә күптән яшереп килгән бер серен ачты. «Бу җырны берәр сөяркәсенә багышлап җырлый торгандыр, дип уйлый инде халык, – диде ул. – Юк, алар шулай уйлап ялгышалар, аның сере башкада. Шушы җырымны җырлый башлауга ук, минем күз алдыма дөньядан бик тә, бик тә иртә киткән нәни кызым килеп баса, аңлыйсыңмы, Алиям минем… бөтерчегем… Сөт тешләре чыгып кына килә иде әле матурымның, кап-кара көдрә чәчле, курчак сымак матур бер җан иясе иде ул, бәгърем… Концерттан кайтсам: «Әтәй, тайтты, әтәй тайтты, ерлап тайтты!» – дип, сөенә-сөенә, каршы ала торган иде мине сабыем. Бик тере иде ул бала, артык живуй, аңлыйсыңмы… ә тавышы…чыркылдап торган яңгыравыклы тавышы әле дә менә колак төбемдә яңгырап тора кебек. Җырлый гына башлыйм, име… күз алдыма шул нәнием килә дә баса. «Әтәй!» дип эндәшкән сабый тавышы шушы җырыма килә дә керә, килә дә керә… «Гафу ит! – дип шаклар катты шагыйрь, – кызың барлыгын белмәдем, ни булды аңа, нәрсәдән үлде?!» «Кем белә, авыруын да тапмадылар, күз тигән, диделәр…» – диде ул. Күзләре дымланган иде.

Ябалак-ябалак кар яуган кышкы көн җырчының соңгы көне булып чыкты. Табиблар аны коткарып кала алмады. Сабыен сагынып җырлаган бөек җырчы шул төнне кызы артыннан мәңгелеккә китеп барды. Бер кешелек палатада авыр үлем газаплары кичергән җырчының: «Үләсем килми минем! Үләсем килми бит!» – дип өзгәләнеп кычкыруы әле дә яңгырап торадыр кебек. Ул китте, ә җыры калды. Ул киткәннән соң, аны башкалар да җырлап карады һәм ул радиодан да, телевидениедән дә яңгырады, ләкин аның кебек моңлы итеп, йөрәкне өзәрлек итеп бу җырны бер кем дә башкара алмады. Ул җыр аныкы, бары тик аныкы гына булып калды. Чөнки аны җырлаганда, дөньядан бик иртә киткән нәни кызын сагынып һәм чыркылдап көлеп торган сабыен күз алдына китереп җырлаучы бер ул гына булды бит! Нинди җыр соң бу? Җыр гынамы соң… тетрәнү бу!

Тыңлар идем тавышыңны,
синең назлы тавышыңны… ■

Хөрмәтле укучыларыбыз! Ошбу саннан «ТАБИГЫЙ МИРАС» дигән өр-яңа сәхифә башлап җибәрәбез. Үз районыгыздагы, шәһәрегездәге, авылыгыздагы Татарстан Республикасының табигать истәлеге буларак теркәлгән яки теркәлергә лаек елга-күлләрне, чишмәләрне, урманнарны, тауларны һ.б. фоторәсемгә төшереп, алар турындагы мәгълүматны, истәлекләрне, риваятьләрне язып, безгә юллый аласыз.

Редакция

КАРА КҮЛ

Л.Гобәйдуллин фотосы

КАРА КҮЛ — Балтач районының Ярак-Чурма авылыннан 12 км көньяк-көнчыгыштарак, Шушма елгасы үзәненең сул як яры буенда. Су өслегенең мәйданы 1,6 га. Күләме 130 мең м ^{3}. Озынлыгы 200 м, иң зур киңлеге 130 м, уртача тирәнлеге 8 м, иң зур тирәнлеге 18 м. Узган гасырның 50 елларында күлнең тирәнлеге 27-29 м булган. Күлнең барлыкка килүе карст күренеше белән бәйле. Озынча түгәрәк формада, суы уртача минеральләшкән (340 мг/л), йомшак, гидрокарбонат-сульфат-кальцийлы типта. Үтә күренмәлелеге 100 см. Җир асты сулары белән туенуы тотрыклы. Ял итү максатларыннан файдаланыла. Кара күл ТАССР Министрлар Советының 1978 елгы 15 гыйнвар карары нигезендә табигать истәлеге буларак теркәлә.

Чыганак: Татар энциклопедиясе. Т.3 — Казан: Татар энциклопедиясе институты, 2012. — Б.262.; http://redbookbaltasi.ucoz.ru/index/0-11.

МИЛЛИЯТ СҮЗЛЕГЕ

Адлер Тимергалин

АЛТЫН УРДА ЧОРЫ МӘЧЕТЕ *тар.* — Бу дәвер мәчетләрен без фәкать археологик тикшеренүләргә карап кына беләбез. 1971-1973 елларда археологлар Волгоград өлкәсе Дубовка шәһәре тирәсендәге Белҗәмин шәһәрлегендә XIV гасырның беренче яртысында төзелгән мәчет хәрабәләрен казып тикшерделәр.

Мәчет, 26 метрга 35 метрлы турыпочмаклык рәвешендә булып, төньяктан көньякка таба сузылган һәм михрабы белән көньяк-көньяк көнчыгышка таба юнәлгән. Бинаның диварлары таштан балчык измәсе белән өелгән булган. Идәненә такта түшәлгән, ә төньяк-көнчыгыш почмагындагы түгәрәк манарасы яндырылмаган бөкре кирпечләрдән төзелгән. Аның тышкы өслеге фирүзә төсле ялтыравык плиткалар белән бизәлгән була. Мәчет Алтын Урданы Аксак Тимер чирүе килеп җимергәнгә кадәр эшләп килгән.

Бинаның эчендә һәм аннан читтә 50 каберне казып тикшергәннәр. Бу каберләр мәчет эшләп килгән вакытка һәм, башлыча, аны җимергәннән соңгы чорга карыйлар. Аерым каберләр яндырылган кирпечтән төзелгән төрбә кебек. Мәетне такта табутка салып күмгәннәр. Кабер чокыры көнчыгыштан-көнбатышка таба юнәлдерелгән. Гүр әһелләре баш ягы белән көнбатышка куелган, йөзләре исә көньякка каратылган. Каберләрдә әйбер-мазар табылмаган диярлек. Каберләр өстендә таштан һәм кирпечтән төрле кабер ташлары калкып торган.

АЛТЫНЧӘЧ — Тарихи легендаларда Болгар ханы кызының исеме. Бу исемнең мариларда киң кулланылган булуы игътибарга лаек, — ихтимал моның нигезле сәбәбе бардыр. Алтынчәч исеме юктан гына барлыкка килмәгән, аның элгәрләре, мәсәлән, фарсы телендә күзәтелә: *Зәрбану* — Алтынчәч(ле кыз), *Зәррингис* — Алтынчәч, *Зәргису* — Алтынтолым(лы кыз), ир-атка карата — Алтынайдар.

АМЕРИКА ҺИНДИЛӘРЕ — Америка һиндуслары, индеецлар яки индианнар (соңгысын Р.Әхмәтьянов тәкъдим итә). «Америка һиндиләре» термины, мәсәлән, Гаяз Исхакыйда очрый. Европа телләрендә — һиндуслар. Терминологиядәге буталчыклык Христофор Колумб ачкан Американың баштарак Индия (Һиндстан) һәм аннары Вест-Индия (Көнбатыш Һиндстан) дип йөртелүеннән үк килә. Латинча Һиндус атамасы испанча in dios — «Алладан», «Алла белән» мәгънәсендә. Бу сүз Американы ачкан Колумб язмаларында очрый. Хәзерге заман ысуллары белән

* Дәвамы. 2014 елның 3 нче санында басылып килә. Автор искәрткәнчә, «...бу сүзлекнең чирек өлеше 2007 елда «Мәгариф» нәшрияты тарафыннан 1000 данәлек тираж белән бастырып чыгарылган иде».

генетик тикшеренүләр (ДНК анализлары) Америка индианнары белән Тува һәм алтайлы халыклар арасында охшашлык таба. Моннан 15-20 мең еллар элек Азиядән бу халык Берингия буенча Америка җиренә барып чыгып, бөтен континентка таралган, дип уйлыйлар.

АМУЛЕТ — Авырулардан, афәттән, сихердән саклый торган, халык исламына хас бөти (битек), талисман. Аны гадәттә тагып йөргәннәр. Исеме дә гарәпчә *хәмайүләт* сүзеннән дигән фикер нигезле (*«әмайли», «әмәйлек»* сүзләрен искә төшерик). Дөрес, бүгенге русча чыганакларның күбесе «амулет» сүзен Европа телләреннән чыгарырга тырыша.

Русча чыганакта амулет мәгънәсендә гарәби «тамаим» сүзе очраганы бар.

АНА — Балага карата — әни, әнкәй, инә. Гомумән, тудыручы, дөньяга китерүче, хөрмәтле җитәкче (чын мәгънәсендә җитәкләп йөртүче), авторитет (болары матриархат чорыннан ук килә). Телдә *анакай* (русча — «матушка») сүзе дә бар. «Дастан Бабахан»да *анака* — тәрбияче ана (Таһирны анакалар тәрбияли), шушы ук дастаннан Зөһрәне тәрбияләү өчен йөз *инәкә* тәгаенләнгән булуын беләбез. *Анака һәм инәкә* — бер үк төшенчәне белдерә, әлбәттә.

Җир-Ана (Хәсән Туфанда — «әнкәй җир»), Мәрьям-ана, Тәңре анасы (*Матерь божья* — XIII гасырда яшәгән төрки телле әрмән авторы Ованнеста очрый), *Өммел-кора, Өммел-Китаб, Өммел мөәминин, Сөт анасы, Йорт анасы, Мунча анасы, Су анасы, Кое анасы* (мишәрләрдә теркәлгән), *Җил анасы (инәсе), Басу анасы, Арыш анасы, Чәчәк анасы, Идел-ана* кебек сүзләр — аналар культының эзләре. Мәҗүси татарларда күзәтелгән «оло җараткан ана» — «великая сотворившая мать», «кече җараткан ана» — «малая (младшая) сотворившая мать» кебек терминнар да борынгы тотемистик мифологиягә барып тоташа.

Борондык инәй — диалектта егетнең әти-әниләре тарафыннан киленгә туй вакытында әни итеп билгеләнгән якын туганы. Мондый гадәт русларда да бар («посаженая мать»).

//Йорт анасы илә корт анасы бер мисалдадыр. Р.Фәхреддин.

АНА ТЕЛЕ — Асылда матриархат чорыннан калган термин. Ана теле дигән сүз, ничек кенә матур һәм газиз булмасын, туган тел термины мәгънәви яктан төгәлрәк.

Ана теле фарсыча — *зәбани мадәри*. Шунысы кызык, идиш телен яһүдләрнең бер төркеме *маме лошен* («әнкәй теле», ягъни ана теле) дип атый.

//«Үз арамызда ана телемездән башка һичбер телдә сөйләшмәскә вә ана телемезне онытмаска». Фатих Кәриминең 1908 елда басылып чыккан «Хыялмы? Хакыйкатьме?» әсәреннән. Петербургта мөселман кызлары оештырган милли түгәрәкнең бер кануны.

Ана теле турында Марсель Галиев Тукай көнләшерлек шигъри юллар яза:

Минем өчен шушы телдә —
кояш чыга, җир әйләнә, йолдыз калка.
Минем өчен шушы телдә —
кошлар сайрый, җилләр исә,
дөнья гүли.
Минем өчен шушы телдә —
Идел ага, иген үсә, илем ныгый.
Минем өчен шушы телдә —
тормыш гаме, бәхет тәме, дөнья яме.

Гомумән, ана телебезгә гашыйк авторның сүзләрне *баба сүзләр, әнкә сүзләр, әткә сүзләр, мосафир сүзләр, дини сүзләр, тылсымлы сүзләр, алынма сүзләр* кебек төркемнәргә бүлеп каравы, фәнни кысаларга сыймасалар да, кызыклы гына.

//Тукай бәгырь! /Сискәнерлек сорау: туфрагыңда /Әткәң-әнкәң теле исәнме? Рим Идиятуллин.

Ат арбасы. XIX гасыр азагы — XX йөз башы

Уфалла арбасы

Үрелгән тарантас

Үрелгән бала арбасы

Л.Гобәйдуллин фотолары

АРБА — Көнбатыш Азиядә дүрт яки ике тәгәрмәчле арбалар таралган була. Гарәп телендә — *гарабат/гарәбә.* Мәс., Муса Акъегетзадә *«Нә гарәбә, нә чана»* дип язган әле. *Арба* варианты угыз һәм монгол телләрендә очрый (Р.Әхмәтьянов). Уйгыр телендә, шулай ук Нократ һәм тау ягы керәшеннәре сөйләшләрендә дә — *араба.* Фатих Кәрими «араба» сүзен тимер юл вагоны мәгънәсендә дә куллана (төрек телендә *араба* сүзе автомобиль, автомашина, мотоцикл, мотороллер мәгънәләренә дә ия, мәсәлән, *спорт арабасы* — спорт автомобиле).

Рус теленә *арба* һәм *араба* рәвешендә кергән. Чуваш, мари, удмурт телләрендә дә бу алынма сүзнең уртасында *а/о* сузыгы катнаша.

Чыганакларга караганда, рус телендәге *телега* — арба сүзе дә төрки телләрдән алынган (борынгы *тилгән* — тәгәрмәч сүзе белән бәйле). *Тарантас* сүзе шулай ук төрки телләрдән.

Электә тәгәрмәч тугымнарын бөгеп түгел, бәлки аерым агач борысларын бергә теркәп ясаганнар.

//Ниһаять, «дүрт яшьлек дисәң, олыларча моңсу күзле, алты дисәң, бик кечкенә һәм арык гәүдәле» бу малайны, кабык арбага утыртып, Печән базарына алып чыгалар. Г.Бәширов (Габдулла Тукай турында сүз бара). *Машина артка чигенгәндә, тагылган*

арба алга чыга. Марс Ахунов. *Арба боты (ботлыгы). Арба киштәсе, арба билдәге. Арбачөй (чәкүшкә). Көймәле арба — өсте ябулы арба, карета. Татар арбасы* — Әстерхан якларында зур ике тәгәрмәчле арбаны шулай атап йөрткәннәр. Ләкин ул бездә башкачарак —*тартай арбасы* дип аталган. *Көлтә арбасы* — сноповозка, рыдван (русча). «Идегәй» дастанында *кузалак арба, тәрәкле арба* терминнары очрый. *Тимер үзәкле арба* — тимер күчәрле арба. *Тимер юл арбасы* — тимер юл вагоны (бу сүзне Р.Фәхреддин куллана).

Рус телендәге *колесница* һәм *двуколка* арбаларын «сугыш арбасы» һәм «ике тәгәрле арба» яки «бер күчәрле арба» дип терминлаштырып булыр иде. Хәер, диалектларда ике тәгәрмәчле ат арбасы *кузалак арба* дип атала. *Ике йөгертмәле арба* атамасы да билгеле. Башкорт теле сөйләшендә ике зур тәгәрмәчле арбаны *куян күт, аю күт* дип атаганнар. Ханнар һәм түрәләр утырып йөри торган ике тәгәрмәчле арба монгол телендә *мөгер тәрг* дип атала икән (*мөгер* – тәгәрмәч, *тәрг* – арба).

Борынгы чорда ике тәгәрле арбага бер рәт итеп җигелгән дүрт атны квадрига дип атаганнар (латинчадан). Йөкче (кучер) квадриганы үрә баскан көенчә идарә иткән.

Тагын кара: ***Бирлин арбасы. Маҗар. Мәгәлдәк. Калимак. Кулазак. Күтәрмә.***

АСЛАН ТАВЫ — Башкача — *Ослан тавы, Ослан.* Русча чыганакларда — *Соколиная гора.* Иделнең Казанга (элек Казан суы тамагына) каршы ягындагы тау. Биеклеге 223 м га җитә. Документларда 1594 елда телгә алына. Ихтимал, элек куе урман белән капланган булгандыр, хәзер исә ул ялантаудан гыйбарәт. Андагы Югары Ослан (Верхний Услон) авылында Себергә сөргенгә барышлый Петр патшаның яраны Александр Меншиков тукталган һәм юлда вакытта вафат булган хатыны Дария Михайловнаны шунда җирләгән. 1873 елда Александр Сергеевич Меншиков үзенең ерак әбисе истәлегенә биредә бер башлы таш часовня рәвешендә һәйкәл төзетә. Түбән Ослан авылында (шулай ук рус авылы) борынгы агач йортлар сакланган. М.Глухов биредәге *Услон* авылларының атамасын русча *заслон* сүзе белән янәшә куя, ләкин моны дәлилләп тормый («Казанский ретролексикон», 2001). Афанасий Никитин сәяхәтнамәсендә «Услан» дигән атама телгә алына. Гипотеза тәртибендә бу атама «арыслан» сүзеннән түгелме икән, дип фараз итәргә мөмкин (госманлы төрек телендә *аслан* —арыслан; рус телендәге «слон» сүзе дә «арыслан»нан килеп чыккан, дигән караш билгеле). Өстәвенә чуаш телендә *услан* дигән сүз бар (кыпчак телләреннән алынма, *арыслан* мәгънәсендә). Ослан тавының «Соколиная гора» дип аталуы да гаҗәп түгел, чөнки борынгыда Казанда шоңкарчылар урамы да булган, ә шоңкар биек тауларга оялый… Электә шоңкарчыларның татардан булуы расланган факт, димәк, әлеге тауның Казан ханлыгы чорында чыннан да Шоңкар (Бөркет) тавы дип аталган булуы бик ихтимал.

Ослан (Соколиная гора) тавыннан бөтен Казан күренә. 1918 елның көзендә Кызыл гаскәр артиллериясе аклар кулында калган Казанны шушы таудан утка тота. Тупка тотканда Ульянов-Ленин күрсәтмәсе нигезендә эш итәләр, ә аның исеменнән сугылган яшерен телеграммада «Шәһәрне кызганмаска» («Город не жалеть») дип язылган була.

АСЛЕ-ГӨНАҺ *г.* — Тәүге (беренче, әүвәлге) гөнаһ. Адәм белән Һаваның җәннәттә тыелган җимештән авыз итүләре аркасында гөнаһлы булуы (*«первородный грех»*). ■

«Кояш» газетасында «Казан хәбәрләре»: 1914 елның август ае

Текстны һәм искәрмәләрне басмага Ленар Гобәйдуллин әзерләде.

Ваткан

Усиягә[1] бара торган 123 нче номерлы трамвай вагоны 1178 нче номерлы Вәлиуллин дигән ломовой арбасын бәрдереп, арткы күчәрен ваткан. Ат белән хуҗасына зарар тимәгән.

Үтәмешевләр заводында

Үтәмешевләр заводындагы[2] бер ат хезмәтче Гатаулла Хәбибуллинны тешләп бик каты имгәткән. Гатаулла шифаханәгә җибәрелгән.

Кояш. — 1914. - №480. — 8 август.

Казан 9 август

Изге гает көнендә хәтерегезгә төшерегез

Бу гаеттән алдагы гаетемезне Балкан христианнары вә төрек сугышлары[3] вә ул сугышларның чыгарган нәтиҗәләре каралтса, бу гаетемезне инде Русия башына килгән авыр сугыш каралтадыр. Киңлеге вә дәһшәтлеге белән бөтен дөньяны каплап алган бу сугышның бер сафында безнең кардәшләремез, шимал төрекләре дә мөшарәкәт итәләр [катнашалар], тәкъдирнең Русия башына сөргән имтиханын руслар белән бергә кулга кул тотынышып, күкрәкләре белән каршы алалар. Безнең ага-энеләремез, безнең кардәшләремез, безнең яшь буынымызның аталары, безнең дустларымыз менә бу гает көнендә дәһшәтле дошманның уты астында, падишаһ әгъзамымыз вә Ватан юлында җаннарын бирәләр.

Без гает итәмез, без азмы-күпме рәхәт итәмез, истирахәт итәмез, әмма падишаһ вә Ватан юлына киткән бу кардәшләремезнең бала-чагалары, кардәш угыллары, карт ата-аналары, күңелләре җәрәхәтле хәлдә, үзләре мохтаҗлык чигеп мәхрүм утыралар. Ватанымыз вә шул аркада безнең дә тынычлыгымызны саклар өчен ут астына кергән бу кардәшләремезнең үзләре чиккән мәшәкатьләре генә аз булган шикелле, якыннары да кайгы-хәсрәт вә мохтаҗлык чигәләр.

Мәрхәмәт кирәк!

Тәкъдирнең язмышы белән сугыш сафлары мәшәкатеннән котылган кешеләр, андагы кешеләрнең якыннары күрә торган кайгы-хәсрәт вә мохтаҗлыкларны бүлешергә кирәк! Хәлдән килгән кадәр аларга ярдәм итәргә кирәк. Изге гает көннәрендә генә булса да, алар үз хәлләренең аз булса да җиңеләйгәнлеген хис итсеннәр вә шуның белән җуансыннар. Ирсез калган хатыннарны, атасыз

---

* Даталар иске стиль белән бирелә.

[1] Усиягә — Казансуның Иделгә коя торган урынында булган Дальнее Устье пристане. 1958 елдан — су астында.

[2] Үтәмешевләр заводы — «Казанская мануфактура Утямышев и К°» — 1 гильдия сәүдәгәр Мөхәммәтгариф Үтәмешев, 2 гильдия сәүдәгәрләр Гомәр Якупов һәм Мөхәммәдйосыф Усмановлар катнашында оештырылган бәз, вата һ.б. җитештерә торган мануфактура.

[3] Сүз 1913 елның 29 июне-29 июлендә булган Икенче Балкан сугышлары турында бара.

калган балаларны, баласыз калган карт вә карчыкларны изге гает көнендә хәтерегезгә төшерегез, сугышка киткәннәрнең гаиләләренә кулыгыздан килгән ярдәмнәрегезне кызганмагыз!

Гает шәриф һәр мөселманга котлы булсын!

Кояш. — 1914. — №481. — 9 август.

Бәйрәм көннәре

Бәйрәмнең һәр өч көнендә иртәдән кичкә кадәр яңгыр явып торды, юллар былчырак, көннәр күңелсез булдылар. Шунлыктан бәйрәм рухсыз үтеп китте. Клубларның бинасы буш булмау, «Сәйяр» труппасының Мәкәрҗәдә булуы сәбәпле, бәйрәм хөрмәтенә спектакльләр дә куела алмадылар.

Мозаффарият [җиңү] теләп дога

Гает көнне, гает намазыннан соң, мәсҗедләрнең һәммәсендә падишаһ әгъзамымыз вә аның гаиләсенең сәламәтлеген һәм Русия гаскәренең дошманга галәбәсен [өстенлеген] теләп догалар әйтелде.

Кояш. — 1914. — №482. — 13 август.

Мөселманча концерт

22 августта Новый клуб[4] залында Фәттах әфәнде Латыйпов[5] тарафыннан мөселманча концерт бирелергә хәзерләнәдер. Фәттәх әфәнденең концертына мәшһүр скрипач Козлов[6] иштиракь итәчәктер [катнашачак].

Кояш. — 1914. — №486. — 18август.

Иганә көне

«Ак чәчәк» көне ясалган шикелле, гаскәргә алынганнар гаиләләренә һәм дә мәҗрүхләргә [яралыларга] ярдәм өчен иганә көне ясалырга хәзерләнмәктә. Иганә көне 21 сентябрьдә иртәнге 11 сәгатьтән башланып, 22 сентябрьнең иртәнге 11 сәгатенә кадәр дәвам итәчәк вә җыелган иганәнең яртысы мәҗрүх вә авыру гаскәриләр файдасына, калган яртысы гаскәргә алынганнар гаиләләре файдасына аерылачактыр.

«Нота мегаллиме»

Бу исемдә мандолинада нота белән уйнарга өйрәтү өчен тәртип ителгән әсәр идарәгә тапшырылды. Бу әсәрнең мөрәттибе [төзүчесе] — моннан мөкаддәм [алда] халкымыз моңнарын, көйләрен саклау юлында чын төзек рәвештә тәртип итеп байтак көйләремезне җыеп нәшер иткән Гыйләҗетдин әфәнде Сәйфуллиндыр. Бу әсәрдә цифр һәм нота ысуллы сызыклар буенча (ике ысулда) өйрәнерә тәртип ителгәнлеге өстенә, басылган чагында дөрестлегенә, хаталы китмәвенә зур игътинаэ [игътибар] кылынганлыгы күренәдер. Моның кирәк цифр ысулында, кирәк нота язуы ысулындагы дөрестлеккә игътинаэ [игътибары] өстенә, ачыклыгына ригая кылынганлыгы да [әһәмият

---

[4] Новый клуб — хәзерге К.Тинчурин исемендәге драма һәм комедия театры урнашкан бина.

[5] Фәттах Латыйпов (1884-1973) — җырчы, үзешчән композитор. «Нур» труппасын оештыруда катнаша, 1920 еллардан соң Урта Азиядә, Ташкент каласында иҗат итә.

[6] Козлов Илларион Александрович (1878-1933) — Мәскәү консерваториясен тәмамлаган сукыр музыкант, татар халык көйләрен скрипкада зур осталык белән башкарып, дан казанган.

биргәнлеге] яңа өйрәнүчеләр өчен әһәмиятледер. Әсәрдә кулны өйрәтү өчен бик күп үрнәкләр һәм егермедән артык көйләр дәрҗ ителгән [тупланган].

Нота өйрәнергә һәвәс итүчеләргә иң файдалы әсәр булачагын игътираф итү [тану] белән бәрабәр, алганда вә соратканда, шушы әсәрне сорауны мәслихәт күрәмез. Бу нота мөгаллиме гүзәл вә игъля [югары сыйфатлы] кәгазьгә басылганына карамыйча, бәһасе барлыгы бер сумдыр. Әсәр һәммә китапханәләрдә табылса кирәк.

Нота мөгаллиме нәфис вә пөхтә рәвештә борадарән Кәримовларның Казандагы матбагаларында басылган.

Кояш. — 1914. - №488. — 20 август.

Шагыйремез солдатка алынган

Шагыйремез Сәгыйть Сүнчәләй[7] 19 августта гына Эстәрле өязеннән истирахәттән кайткан иде. 21 нче августта призывка куелып (Сәгыйть әфәнде учитель иде), солдатка алынды.

Кояш. — 1914. — №490. — 22 август.

Эт көтүе

Шәһәр утилизационный заводының мөдире М.П.Колосов дигән ветеринар шәһәр көтүләре көтелә торган болыннарда 35 кадәрдән гыйбарәт эт көтүе пәйда булганын хәбәр иткән. Этләр вак хайваннарга, бигрәк тә кәҗәләргә куркыныч икән. Вокзал артындагы пыяла заводы якынында ике кәҗәне буганлыклары мәгълүм булган инде. Шәһәрнең эт аулаучылары боларны тота алудан гаҗиз калганнар. Шунлыктан эт ату өчен ике мылтык алырга полицмейстердан рөхсәт алырга карар кылганнар.

Мәҗрүхләргә ярдәм

Гәҗит вә китаплар сатучы Волжская артель 19 августта булган сатудан килгән варидәтләрен [керемнәрен] мәҗрүхләр файдасына бирергә карар биргән һәм шул көндә килгән 110 сум 60 тиен варидәтне 3209 нчы номер квитанция буенча земстволар союзы комитетына тапшырган.

11 нче мәхәлләдә

11 нче мәхәлләдәге Тәрҗемани[8] мәктәбенә ошбу август 25ендә шәкертләр кабул итү башланып, 27сендә чәршәмбе ибтидаи һәм рөшди сыйныфларда дәресләр башланачактыр. Мәктәп идарәсе.

Кояш. — 1914. - №491. — 24 август.

Печән базары мәсҗедендә шатлык догасы

Кичә Казан шәһәре флаглар илә зиннәтләнгән иде. Һәммә гыйбадәтханәләрдә падишаһ әгъзам хәзрәтләре вә гаиләи мөхтәрәмәләре сәламәтлегенә, Львовның шәүкәтле гаскәремез тарафыннан алынуы[9] сәбәпле, гаскәремезгә галәбә [җиңү] вә дошманга мәгълүбият [җиңелү] теләп, шатлык

---

[7] Сәгыйть Сүнчәләй (1889-1937) — шагыйрь, мөгаллим. 1915 елның язынна Уфада яшәве мәгълүм.

[8] Кәшшаф Тәрҗемани (1877-1943) — дин һәм җәмәгать эшлеклесе, дин галиме. 11 нче мәчет (хәзерге Кызыл Татарстан урамында булган) имам-хатибы, мәчет каршындагы мәдрәсә мөдәррисе.

[9] Россия гаскәриләре 21 августта (3 сентябрь) Львовны, 22 августта (4 сентябрь) Галичны ала.

догалары әйтелде. Шул җөмләдән мөселманнар да ахун хәзрәтнең[10] чакыруы илә Печән базары мәсҗеденә җыелып, падишаһ әгъзәм хәзрәтләре вә гаиләи мөхтәрәмәләре сәламәтлегенә, безнең гаскәргә галәбә, ватанымызның һәммә дошманнарына, хосусан Германия вә Австриягә мәгълүбият вә мәкъһүрият теләп дога әйтелде. Дога мәҗлесенә бик күп мөселманнар һәм Казанның һәммә имамнары килгән иделәр.

r Казанда флаг көне

Казанның главное начальство зәүҗәсе [хатыны] Боярская ханым[11] тарафыннан 28 августта флаг көне ясалу мөнәсәбәте илә кич шул тугрыда комитетның җыелышы булды. Җыелышта флаг сату 27 августта кич сәгать 7дән 29 август көндезге сәгать бергә кадәр дәвам иттерергә карар бирелде. 27сендә кич сәгать 7дән соң сату сатучыларның ихтиярында булып, халык йөри торган урыннарда төнге сәгать 11ләргә кадәр дәвам иттерергә мөмкин булачактыр. Соңрак флаг сатылган көннәрдә чыккан телеграммалар флаг сатучылар тарафыннан сатылачактыр. Флаг сату эшендә 15, 16, 18 нче районнар (Печән базары[12], Екатеринская урам[13] вә аңа мөтәгалликъ [караган] урамнар, Яңа бистә) мөселманнар кулында булып, 15 нче районны Садыйк хәзрәт Иманколов[14] Болгар номерларында, 16 нчы районны Әминә ханым Терегулова[15] үз квартирасында (Захарьевская урам[16], Кушаев йортында[17]), Яңа бистә районын (18 районны) Кәшшаф хәзрәт Тәрҗемани идарә итәчәкләрдер. 27 августта иртән сәгать 9дан кич 8гә кадәр кружка вә флаглар бирелә башлаячак. Флаг сатарга теләүчеләрне «Кызыл хач» җәмгыятенең үз йортында (Большая Красная урамында) һәр көнне иртә уннан кич 8гә кадәр кабул итәләр.

Флаг көнендә сатар өчен биш йөз мең флаг хәзерләнгән. Бу флаглар Русия, Франция, Англия, Бельгия, Сербия, Каратаг[18] дәүләтләре флагларыннан гыйбарәттер[19].

q Спектакль

Казандагы мөселман театр һәвәскәрләре тарафыннан, Гайшә ханым Терегулова[20] тәхте риясәтендә [җитәкчелегендә], 27 нче августта, мәҗрүхләр һәм аларның гаиләләре файдасына Новый клубта спектакль биреләчәк. Тамашага 5 пәрдәлек «Морат Сәлимов»[21] дигән драма илә «Безнең шәһәр серләре»нең[22] соңгы пәрдәсе куелачактыр. Тәнәфес вакытларында милли оркестр уйнаячак.

Кояш. — 1914. — №492. — 25 август. ■

---

[10] Печән базарының имамы, ахун Хисаметдин Гаффаров.

[11] Боярская ханым — Казан губернаторы Н.П.Боярскийның хатыны.

[12] Печән базары урамы — хәзерге Париж коммунасы һәм аңа перпендикуляр Мәскәү урамының бер өлеше.

[13] Екатеринская урам — хәзерге Г.Тукай урамы.

[14] Садыйк Иманколов (1870-1932) — Иске Таш, ягъни 9нчы мәхәллә мәчетенең (хәзерге М.Гафури урамында) 1893 елда сайланган имамы.

[15] Әминә Терегулова (1887-1975) — «Яшьләр» труппасы артисткасы, танылган врач Әбүбәкер Терегуловның хатыны.

[16] Захарьевская урам — хәзерге Каюм Насыйри урамы.

[17] Кушаев йортында — танылган сәүдәгәр һәм иганәче Кушаевлар утарындагы бер йорт.

[18] Каратаг — Балкан ярымутравындагы Черногория дәүләте.

[19] Флаг сатылганнан кергән акча яралыларны дәваларга һәм сугышка алынганнарның гаиләләренә матди ярдәм буларак тотылган.

[20] Гайшә Терегулова (1868-1940) — тәрҗемәче, концерт-кичәләр оештыручы.

[21] «Морат Сәлимов» — Ф.Халидинең 5 пәрдәлек драмасы.

[22] «Безнең шәһәр серләре» — Г.Камалның 5 пәрдәлек комедиясе.

«ТЫНГЫСЫЗ КАЛӘМ» БИТЛӘРЕННӘН...

Әл-Болгари*

УТЫРЫШ

Аксакал яшь шагыйрьне тотып алып арбага салдылар да шагыйрьләр секциясенең операция өстәленә китереп салдылар. Бөтен коридор аксакал яшь язучының киләчәк язмышы һәм гомере турында кайгыртудан ут йотып калды.

Барысының да кичке кәефе аксакал яшь шагыйрьнең кәефен көйләүгә бәйле иде. Коридорны билгесезлек томаны һәм тәмәке төтене басып китте. Ул болыт һәм төтен аксакал яшь язучы шигырьләрендәге тарау болыт һәм төтенгә бик ятышып тора иде.

Баш сүзне утырыш председателе әйтте. Һәр сүзе ахырында күп мәгънәле озын-озын тынлык саклап, ул:

— Яшь... ак сакалыбыз... турындагы... шәхсән... фикеремне... мин... ахырдан... әйтермен әле! — диде. Аннары тиз генә сүзен:

— Яшь... ак сакалыбыз турындагы сүзне аның кан дошманы һәм кхм... кхм... Фәләновка бирәбез, — дип тәмамлады.

Яшь аксакалның яшь дусты да һәр сүзенең тәмен теле һәм ирене белән татыпта-тып ашыкмый гына сөйләде. Ашыкмау һәм кабаланмау, күп мәгънәле тынлык яшь аксакалның иҗат үзенчәлеген тәшкил итә икән, чыгыш ясаучы шуңа яраклаштырып сөйли.

— Хикмәт нидә, җәмәгать?.. Укыдыгыз бит инде, әме? Укыдыгыз... Урыны-урыны белән, чыннан да, яшерен-батырын түгел, ни бит! Эш андамыни? Хикмәт бүтәндә. Нидә соң? Әйдәгез, карап карыйк. Ничек? Ни бит, бар! Кайбер нәрсәләре юктыр, тик бит мәсьәләнең төбенәрәк карау... ни әле... фарыз. Фарыз! Ни җитми соң? Болай, җитми дип, нәфес зур инде ул. Җитмәгән нәрсә күп инде ул. Менә бу хакта уйлану комачауламас иде. Мондый мөмкинлекне кулдан ычкындыру безнең зур хилафлыгыбыз булыр иде. Мәсьәләне кабыргасы белән кую шарт. Ачыктан-ачык әйткәндә, монда икеләнү булырга тиеш тә түгел шикелле. Бу хакта мин бөтен җаваплылыгы белән кистереп әйтергә дә курыкмыйм. Кирәкме безгә яшь аксакалның шигырьләре, юкмы? Җавабыбызда өч мәгънәлелек булма-

* Язманың авторы билгесез. Фаил Шәфигуллин булуы ихтимал. — *Ред. искәрмәсе.*

сын иде. Шигырьнең нindiлеге шигырь язучыга гына бәйлеме? Юк инде, иптәшләр. Сорауны кабыргасы белән китереп куйгач, кистереп җавап та бирик инде. Кемнең кем булуына карамастан. Билгеле, бу минем үземенең эчке, шәхси фикерем генә, көчләп такмыйм...

Әйе, кереш сүз белән чыккан Фәләнов үзенең принципиальлеге һәм туры сүзлелеге белән аерылып торган хөрмәтле, бер мәҗлестән калмый торган кадерле кеше иде шул.

Ораторның теоретик нигезе бик нык һәм тирән булган бу чыгышыннан соң фикер алышу кул һәм баш җитмәс дәрәҗәдәге биеклеккә менеп китте. Бер кавым «ФТР», «ФТР» дип гөрләшеп алдылар. Шуннан соң сүз яшь аксакалның энлектик экспрессив интеллектуаль шигырьләре тирәсендәрәк куера башлады.

Таныла башлаган карт бер яшь шагыйрь сүз алып, утырган җиреннән генә ялгап китте:

— Шиксез ки, бүгенге безнең тикшерү объектыбызның үзенчәлекле суммар җыелмаларда күзгә ташланып торган конруэнтлык басымы тиешле гектокаскаль югарылыгында тирбәлә. Тик бу пробаль констелляция таләпләренә никадәр детерминировать итә соң? Әлбәттә, шигырьләргә ахроматик жинарметлылык хисе ят түгел. Аларның бөтен космоэвивалент апперценциясенә крепитация гармониротепциясе хас. Димәк, шул юнәлештә алга, гел алга! Без шуңа сусадык. Хәтта фермаларда да сәнәк белән эшләмиләр инде хәзер. Ә сәнәк заводлары гел эшләп тора. Вакыт, вакыт инде, коллегалар, вакыт...

Беравык елашып алдылар.

Председатель янә сүз алды.

— Менә шулай, иптәшләр! — диде ул секретарьның ни язып баруына кырын күз ташлый-ташлый. — Югыйсә, Балык Бистәләре артыграк үрчеп китте түгелме? Сан ягыннан Арча якларын уздырмаска дигән разнарядка да бар бит әле, әйе! Гомумән, мин каршы түгеллегемне алдан ук сиздереп куйган идем инде.

Тәмам булды. Таралыштылар. Юк, җыйналыштылар. Коридордагы тәмәке төтене болытына яшен булып каклаган каз исе кереп таралды.

(«Тынгысыз каләм», 1974)

Зөлфәт

ЭПИГРАММАЛАР

Зөлфәт

РИНАТ МӨХӘММӘДИЕВКӘ

(Р.Мөхәммәдиевкә охшаган берәүнең бер кыз янәшәсендә уйга батып төшкән сурәтенә карап)

Моны күргәч, шаклар каттым, малай:
«Чыннан да бу Ринат микән?» — дип.
...Шундый усал тәнкыйтьче дә кайчак
Хискә бирелгәли икән бит?!

ГӘРӘЙ РӘХИМГӘ

(Г.Рәхимгә охшаган поп кыяфәтле, кулына күсәк сыман бер нәмәрсә тоткан берәүнең рәсеменә карап)

Ниләр генә әйтим, мине бөек
Итеп танымаган заманга? —
Каләм тотып китәм Мәскәүгә һәм
Күсәк тотып кайтам Казанга.

РОБЕРТ МИҢНУЛЛИНГА

(Р.Миңнуллинга охшаган бер биюче егет белән кыз рәсеменә карап)



Роберт Миңнуллин

Гаҗәпләнмәгез сез
Сөн һәм Болак
Буталышып акса моңымда —
Сөн суында тапкан безне әнкәй,
Никтер юган...
Болак суында.

РАЗИЛ ВӘЛИЕВКӘ

(Сакаллы Р.Вәлиевкә охшаган, җыр тәлинкәсен берет иткән берәүнең сурәтенә карап)

Бик яратам мин бу беретканы,
Шуңа күрә аны ташламыйм да:
«Дан алганчы гына биреп тор!» —
дип,
Прокатка алдым
Ошаниннан...
(«Тынгысыз каләм», 1981)

М.Әпкәли
(Фаил Шәфигуллин)

МӨДӘРРИС ВӘЛИЕВ МАНСУР

Бакъ, хәтер — тишек иләк, пыцак кергере! Бар иде бит дөньяда андый кеше. Критикмы, шаирмы — истә калмаган хәзер. Выт син хәтерне, ә! Изменять итә, цукынцык. Озын буйлы, зәңгәр бәбәкле, таз маңгайлы бер адәм иде ул. Лебяжьеда дача алып торды. Хәсән Туфан Миңнуллиннардан ерак түгел, статьяларны күп язды. Мактыйлар иде үзен. Такьмакьлар да язды. Особенно «Мишәр карцыгы» дигәне истә калган. Бик зурлаган иде ул анда карцыкларны. Безнең Ахметшиннар авылына статья язарга кайткач, трибуна артына басып сүләгән. Ахметшин сүләп торды аннан суң. «Мишәр карцыгы» өчен байтак акча каерып китте деп. Безнең Сергач егете Вергазовны да критиковать итеп цыкты бервакытны Мөдәррис Вәлиев Мансур. Статьялар яза белми, деп әйткән иде. Идәнгә ятып, патолокка багып, чут кенә катмаган Вергазов шуннан суң. Цын сүлим, ялганламыйм, Абдулдан сорагыз әнә, ышанмасагыз. Абдул әйтеп бирер. Умер бакый редакциядә эшләде Мөдәррис Вәлиев Мансур. Кеше белән ацылып китеп сүләшмәс иде үзе, скромный иде егет. Күзлек киеп укыр, аска карап ашар, алга карап атлар иде. «Идел» дигән брошюраны да шул егет бастырып цыгарды. Минем сурәтне бастырмады. Мин яшь идем, матур идем ул цагында. Кызлар

Вәлиев Мансур

карый иде миңа ул цагында. Шылай да Мөдәррис Вәлиев Мансур миңа внимание ясамады. Мин болай гына айтам, мин атаклы писатель тегел идем ул цагында. Хәзер генә атаклы шаир булдым мин. Тел белгече булдым, кандидат булдым.

Мансур Вәлиев Мөдәррис турында сөйләгәндә тагын шул искә төшә: Мансур Вәлиев Мөдәррис белән бер өстәл артына утырып ашаганыбыз бар, кайнар кәбестә ашы, поджарка ашаган идек критик белән бер өстәл артына утырып, кайнар кәбестә ашы ашау не каждому туры килә безнең заманда.

Нинди статьяларны хәтерлимме? Ну «Мишәр карцыгы», Вергазовны цукындырып язган статья, аннан килеп парцалар. Парцаларны да бик оста сочинять итә иде Мөдәррис Мансур Вәлиев. Борцак турындагы парцасы бик истә калган. Ә-ә, ыспирва китабын әйтмәгәнмен. Ыспирва китап бастырып цыгарды бит әле Мансур Вәлиев Мөдәррис. Сары тышлы иде китабы. Артык кыйммәт тә түгел. Эцендә ниләр булгандыр, гөнаһысына кермим — эцен ацып карарга җай цыкмады, эт тырнагы белән җәфаланган елларым иде.

Күп сүләдем. Җыеп кына әйткәндә, үзе әмәлле, үзе жут, үзе ыңгайлы, үзе пырдымлы, үзе кырыс, үзе агылҗым, үзе кулкабат, үзе имәнлекле, үзе цыкмыр, үзе ыцык, үзе күнгер, үзе тыҗы гына бер алим иде Мөдәррис Вәлиев Мансур.

Сүлпән, акрын, цаман, үрчемсез, шылбак, ырамай, ләх-ләкәс, иренчәк, пошымсыз, эшләмице гүләйт итүце кешеләрне бер дә яратмас иде ул.

Байгыш, йоваш, мокыт, ян күеге адәмнәрне кызганыр иде.

Аның характерындагы әрләшү, цобалышу, әрепләшү, цәпкәләшү, юлдан саптыру, дүндерү кебек сыйфатларның эзе дә булмады.

Редакциягә килгән писательләрнең картына-яшенә (Вергазовтан башкаларга) кәбәм, наныем, иркә таем, күкелдәгем, бавыр итем, җофарым, ардаклым дип кенә эндәшер иде үзе. Кыз-хатыннарны өрмәгән урындыкка да утыртмас иде.

Милли ашлардан бигрәк тә кәлҗемәне, мөгезне, тәкәне, бөккәнне, мәнгәне, дурыцмакны, дуцмакны, әпәцәне, цецмәрне, шырбүрәкне, бүрәкне, кәбәцне, көл күмәцен, фытыр ашын, шишаранцы, умер бакый ац торгандай, тонцыга-тонцыга сыпыртыр иде әдип.

Ну, энде кием-салымга килгәндә, дуптун, картуз, пима, бармакча киеп билен кушак белән урап йөрергә яратыр иде. Дуп тунны ата каптырма белән сәдәпләп йөрер иде. Мияли-бияли кебек нәрсәләргә дә исе китмәс иде, мәгәр күн калуш, агач башмак, цөлкә киеп, чалбарын ыцкыр белән ыцкырлап йөргән чакларын еш күргәләдем критик-шаирны.

Аның эш кабинетындагы диван, мендәрцек, валик, кара савыты, көллек, китап тоткыч кебек әсбаплар әле дә әдәбият музеенда саклана.

Мунца яккан көннәрдә пар салу, себерке пешерү, арка ышку, төннек ябу кебек вак-төяк эшләрне тәм табып үзенә бер ләззәт вә теләк белән башкара иде Мөдәррис Вәлиев Мансур.

Арт бакцада яшелчә утырту, түтәл ясау, су сибү, келәттә ярма ярдыру, ярма төю кебек эшләр дә аның җилкәсендә иде.

Иң мөһиме: шпион-диверсантларга, ацыг-авызлыкка каршы көрәштә актив иде егет.

Үзешцән түгәрәкләр, кицәләр, туристлык походлары — берсе дә калмады аннан.

Тел арды, җәмәгать, кызганыгыз!

Сүләгәннәремне раслап, култамгамны куям: М.Әпкәли. 81 нче сәнә, үктәбер ае.

(«Тынгысыз каләм», 1981)

Зөлфәт Хәйруллин һәм Рөстәм Нуриев шаржлары

Мәзәкләр

«Шура» журналы, 1909 ел

Басмага **Рәйсә Шәрәфиева** әзерләде

Хәйләсен тапкан...

Кыйсса сөйләүчеләрдән бере, Йосыф пәйгамбәр кыйссасын сөйләдеге вакыт: «Йосыф пәйгамбәрне ашаган бүре Хушәб исемле иде», — димеш. Арадан бере торып: «Әфәндем, Йосыф пәйгамбәрне бүре ашамамыш, хата сөйләрсез!», — дидекендә, вәгазь сөйләүче: «Ялгыш әйтәм, Йосыф пәйгамбәрне ашамаган бүренең исеме Хушәб димәкче идем», — димештер.

«Өлгермәгән»

Бер шәһәрдә иҗарә илә торучы бер мөселманга мосафирлар кереп, намаз укырга хәзерләндекләре соң, хуҗаны чакырып: «Безгә кыйбланы күрсәт, кайсы тарафта?» — димешләр. Хуҗа исә: «Безнең бу фатирга күчкәнемезгә алты гына ай», — дип җавап вирмештер.

Кемгә ни шарт?

«Дини журнал чыгарыр идем, буның өчен нә кеби шәйләр белергә кирәк?» — дигәнгә, мәшвәрәт итүчеләрдән берен Мисырның олуг адәмнәреннән бере: «Бу көндә ислам диненә гаид журнал чыгарыр өчен Коръән илә хәдис гыйлемнәрен тәмам белергә кирәк вә аның өстенә дә дәрелфөнүн дәресләреннән шәһадәтнамә алырга кирәк, әмма урам уртасында анадан туган рәвештә йөрерлек дәрәҗәдә тинтәк улган адәм өчен һичнәрсә шарт түгел», — дип җавап вирмештер.

Ләтаиф // Шура. — 1909. — №22. — Б.700.

Ике чабата – бер кием...

Мәшһүр Хуҗа Насретдин әфәндедән бер мәҗлестә мулла илә мирза арасында улган аерманы сорашалар иде. Хуҗа әфәнде дә: «Мирза низам сатып, мулла да шәригать сатып көн кичерүчеләр!», — дия җавап вирмештер.

Зирәк чагыштыру

Бер вакыт солтан Габделхәмиткә: «Истанбулымызга гаҗәеп бер адәм килмештер, пычаклар-санчәкилар йотадыр ди, һич зарар улмыйдыр», — димешләр. Солтан Габделхәмид исә бу сүзгә каршы һичбер фикер әйтеп тормай: «Буның нә җиренә тәгаҗҗеб итәсез? Безем Бәхрия вәзиремез бөтен флотымызны йотты да, бер шәһ улмады!», — димештер.

Ләтаиф // Шура. — 1909. — №24. — Б.767.

Мирасворд

30,48 см. га тигез озынлык үлчәве

Кадыйр… (башкорт шагыйре)

Россия кинопремиясе

Шимбә, якшәмбе

Кызыл эремчек

… Торгильссон (Исландия тарихчысы)

Өндәү, чакыру авазы (иск.)

Ходай, Тәңре

Серкә кислотасы тозы

Шагыйрь Рәдиф …

Үзән (диал.)

Җәлилчеләр … Булатов, Сәйфелмөлеков

Кигәвен корты

… янына куш

Ашлык, кибәк ташу өчен зур әрҗә

Җәлилчеләр җәзалап үтерелгән төрмә

… кузгалагы

Мисыр мифологиясендә җил Алласы

Төрек кылычы



Ике башы беркетелгән аркылы агач

Мускус (иск.)

Француз композиторы

Истәлек, ядкяр

Ярым ефәк чуар тукыма

Җәлилче … Симаев

Аз санлы төрки халык

Манара, башня (иск.)

Геометрик җисем

Татарстандагы район

Чыңгыз ханның законнар җыелмасы

Себер шаманы

XIII-XVIII йөзләрдә Россиядә почта станциясе

Эндре … (мажар шагыйре)

Гарәп хәрефе

Аудару

Элекке заманда җан башына тигән җир

Нота

Идел буе Болгары шәһәре

Рус рәссамы

… Нәҗми

… Гумилёв

Рәис Габдулла төзеде.

7 нче санда дөнья күргән мирасвордның җаваплары

Сулдан уңга: Җүчи, фәрд, карыш, ханә, Үле, «Ант», терпе, Азак, Таити, даим, ат, Ширин, банан, Ян, атна, Нәвои, инк, Евлах, Рәмиев, ду, ро, фланг, ген, Камай.

Өстән аска: Җүкәтау, даир, чирү, антоним, ылак, Ани, «Яшен», керфек, шан, «Волга», Алинә, ти, Равелин, Фәхретдинов, Гай, Риан, илд, рун, ау, Әбелмәних.

«БЕЗНЕҢ МИРАС» ЕЛЪЯЗМАСЫ / АВГУСТ

945 ел элек (1069)

● Йосыф Баласагуни (Йосыф Хасс-Хаҗиб) Кутадгу Билик (Котайткыч белем) әсәрен яза.

465 ел элек (1549)

● Бөек шагыйрь Мөхәммәдъяр (1497-1549) Муром (Карачар) янында Явыз Иван гаскәрләре тарафыннан вәхшиләрчә үтерелә.

125 ел элек (1889)

● 14 августта шагыйрь, публицист, тәрҗемәче, дәүләт һәм җәмәгать эшлеклесе Сәгыйть Сүнчәләй (1889-1937), 30 августта скрипкачы, драматург, җәмәгать эшлеклесе Вәли (Мөхәммәтвәли) Закир (Мөхәммәтзакир) улы Апанаев (1889-1922) дөньяга килә.

95 ел элек (1919)

● 8 августта Үзәк мөселман хәрби коллегиясенең сәяси бүлеге карамагындагы татар драма артистлары труппасы Шәриф Камалның «Хаҗи әфәнде өйләнә» исемле комедиясен куя. Режиссёры — Кәрим Тинчурин.

85 ел элек (1929)

● 10 августта Татар пролетариат язучылары ассоциациясе, татар язучылар җәмгыяте әгъзалары һәм сәнгать көчләре (Г.Нигъмәти, Ш.Камал, К.Тинчурин, Гомәр Гали, Г.Толымбай, М.Гали, З.Гали, Һ.Такташ, Г.Кутуй, К.Нәҗми, С.Сәйдәшев, М.Әмир, Д.Фәтхи, Ш.Шамильский, И.Рәми, З.Бәшири, Г.Иделле, Г.Беляев) СССРның көнчыгыш, көньяк җөмһүриятләренә иҗади сәфәргә чыгып китә.

● Мәскәүдә «Октябрь баласы» исемле журнал чыга башлый. Җаваплы редакторы — Муса Җәлил.

70 ел элек (1944)

● 25 августта Берлинның Плетцензее төрмәсендә күренекле татар совет шагыйре Муса Җәлил (1906-1944) һәм аның көрәштәшләре фашистлар тарафыннан җәзалап үтерелә.

55 ел элек (1959)

● 25 августта Казанда Абдулла Алиш сугышка кадәр яшәгән йортка (Кави Нәҗми урамы, 19) истәлек тактасы куела.

50 ел элек (1964)

● «Совет әдәбияты» журналында Габделҗаббар Кандалыйның яңа табылган шигырьләре дөньяга чыга.

«Хәйбул бабай». 1986.
Киндер, майлы буяу

МИДӘТ МӨХӘММӘТОВ

Мидәт Мингали улы Мөхәммәтов 1955 елда Оренбург өлкәсенең Шарлык районы Мостафа авылында дөньяга килә.

1979 елда Уфа сәнгать училищесының сәнгать бүлеген тәмамлый. 1987 елдан бирле республика, төбәкара, бөтенроссия һәм халыкара күргәзмәләрдә катнашып килә. 1995 елдан — Россия Рәссамнар берлегенең, 1997 елдан — «Чыңгызхан» дип аталган иҗади сәнгать берләшмәсенең даими әгъзасы.

Мидәт Мөхәммәтов реализм һәм авангард алымнарында яза. Аның әсәрләре Россиянең төрле калаларындагы шәхси вә дәүләти тупланмаларда саклана.

«Фатыйма түтәй». 1986.
Киндер, майлы буяу

«Ташлар моңы». 2007. Киндер, майлы буяу

АЛДАГЫ САННАРДА:

Кытайларга кытай теле һәм әдәбиятын укытучы Гыйззәтулла Хәсән белән Марат Закир әңгәмәсе

«Без плиндә ятамыз
Читлектәге кош кебек...» – Беренче бөтендөнья сугышы бәетләре. Текстолог – Раиф Мәрданов

Казан татарларында агач архитектурасы. Михаил Худяков

«Бәяләнмәгән талант». Марс Макаровның композитор, музыкант, курай ясау остасы Ифрат Хисамовка багышланган язмасы

Индекс:
Татарстанда – 54132
Чит төбәкләрдә – 70275

Ярты еллыкка язылу бәясе – 420 сум
Редакциядә язылу бәясе – 319 сум

4 612750 670172